Татар әдәбияты

9



Татар әдәбияты 9

Җәй уртасы. З. *Бәширов фотосы*

З. Н. ХӘБИБУЛЛИНА, Х. Г. ФӘРДИЕВА,
Ә. Н. ХУҖИӘХМӘТОВ

Татар әдәбияты

Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең
9 нчы сыйныфы өчен дәреслек

(*татар балалары өчен*)

*Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан
тәкъдим ителгән*

Яңартылган өченче басма

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 373.167.1:821.512.145*09
ББК 83.3(2Рос=Тат)я721
Х82

Фәнни редакторы филология фәннәре докторы
Ф. Г. Галимуллин

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Хәбибуллина З. Н.

Х82 Татар әдәбияты: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 9 нчы с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен) / З. Н. Хәбибуллина, Х. Г. Фәрдиева, Ә. Н. Хуҗиәхмәтов.— Яңартылган 3 нче басма.— Казан: Мәгариф, 2005.— 239 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1487-Х

ISBN 5-7761-1487-Х

© «Мәгариф» нәшрияты, 1999, үзгәрешләр белән
© «Мәгариф» нәшрияты, 2005, үзгәрешләр белән
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2005

И телем, сансыз гасырны
Исән-сау кичкән телем!
Сыкраулар теле түгел син,
Күкрәүләр теле бүген...

Син — минем тере тарихым,
Син — минем киләчәгем,
Тик синдә, газиз туган тел,
Бәхеткә җитәчәгем...

Хәсән Туфан

РИВАЯТЬЛӘР ҺӘМ ЛЕГЕНДАЛАР

Татар халык авыз иҗаты әсәрләре төрле жанрларга бүленеп йөртелә. Алар арасында, мәкаль, әйтем, табышмак, җыр, әкият, бәет, дастаннар белән бергә, риваятьләр, легендалар да аерым урын алып тора.

Риваять сүзе төрки телләрдә төрле мәгънәләр белдерә. Ул легенда, тарих, истәлек, сөйләм, повесть, хикәят, әкият, уйдырма, мәсәл кебек атамаларның синонимы рәвешендә дә кулланыла. Риваятьләрдә элеккедән килгән яисә буыннан буынга сөйләнгән вакыйга-хәлләр хикәяләнә. Кайбер риваятьләр тулысы белән уйдырма эчтәлеккә корылган була. Шул яклары белән алар бераз әкияткә дә тартым.

Риваятьләрдә күп очракта тарих түгел, ә тарихи вакыйгаларга, тарихи шәхесләр эшчәнлегенә халыкның мөнәсәбәте чагыла (Сөембикә, Батырша, Колшәриф, Утыз Имәни, Акмулла һ. б. турындагы риваятьләр).

Борынгы һәм урта гасырларга караган риваятьләрнең күпчелеге дини-мифологик характерда. Пәйгамбәрләр, изгеләр тормышы турындагы риваятьләр шулар рәтеннән.

Татар тарихын өйрәнүдә риваятьләрнең әһәмиятен аңлап, мәгърифәтче Каюм Насыйри күп кенә риваятьләрне халык теленнән язып алган. «Халык арасында бик күп риваятьләр бар. Ләкин аларны халык авызыннан җыйнау бик читен. Кайсы вакыйганың ахырын, кайсы вакыйганың башын гына беләләр»,— ди ул. К. Насыйри риваятьләрне үзе чыгарган календарь битләрендә файдаланган һәм аерым җыентыклар итеп тә бастырган. Язучылардан Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Һади Такташ, Муса Җәлил һәм башка күп әдипләр үз иҗатларында риваятьләрдән мул файдаланганнар.

Хәзерге көндә дә халык авыз иҗатының бу өлкәсенә караган әсәрләрне җыю һәм өйрәнү дәвам итә. 1987 елда басылып чыккан «Риваятьләр һәм легендалар» җыентыгы бу

юлда зур казаныш булды. Әлеге җыентыкта риваятьләр эчтәлекләре буенча тарихи, топонимик (ягъни авыл, урман, кыр, елга һ. б. атамалары турындагы) һәм тормыш-көнкүреш риваятьләренә бүлеп өйрәнеләләр.

Легенда сүзе исә — латин теленнән кергән сүз, *укылырга тиеш* дигән мәгънәне аңлата. Ул — халык иҗатындагы проза жанрларының берсе. Легенда, риваятьләрдән аермалы буларак, могҗизалылыкка, фантастикага нигезләнә.

Легендаларның тематикасы бай һәм эчтәлеге төрле.

Аларның күбесе күк җисемнәре, үсемлекләр, хайваннар турында. Моннан тыш кешеләрне, көнкүреш вакыйгаларын тасвирлый, хәзинәләр, тарихи шәхесләр хакында сөйли торган легендалар да байтак.

Риваятьләр һәм легендалар халык авыз иҗатының күп өйрәнүне таләп итә торган төрләренә керә.

Риваятьләрдән үрнәкләр

УТСЫЗ КАЙНЫЙ ТОРГАН КАЗАН

Аксак Тимер хан Бүләрне алма келәгән. Шул максаттан Бүләр өчен бик озак сугышып йөргән. Ләкин нихәтле сугышса да ала алмаган. Шуннан соң ул, хәерче киеменә киенеп, Бүләргә бер карчыкка фатирга кергән. Кыз-хатын күп сөйләүчән була бит. Теге хатын Аксак Тимер ханның кем икәнен белмичә әйткән:

— Менә,— дигән,— Аксак Тимер хан безнең шәһәрне алма кели, ул аны күгәрчен аягына ут төртеп җибәрсә генә алыр,— дигән.

Аксак Тимергә шул гына кирәк — моны ишеткәч, бик кинәнгән. Ул карчыкка, бөтен әйберләрен алып, Бүләрдән китәргә кушкан һәм әйткән:

— Кай төштә, астына ут якмыйча, казан астында ут янып китә, шунда туктап урнашып кал,— дигән.

Карчык, шулай итеп, бер казан һәм бөтен әйберләрен алып, Бүләрдән чыгып киткән. Бер җиргә барып, казанны куйган, казан астына ут якмыйча ут янып киткән. Карчык шул урында утырып калган. Аның янына башка кешеләр дә килеп утырган, шуның белән Казан шәһәре «Казан» исеме белән аталган.

алма кели — алырга тели
кай төштә — кайда

ХЫЯНӘТЧЕГӘ «БҮЛӘК»

Казанны алуда Иван Грозный гаскәрләренә ярдәм иткән бер хыянәтчене, бүләкләү өчен, Иван Грозный каршына китергәннәр.

Аның турында патшага: «Бу кеше безгә, Казан каласының серләрен җиткереп, эшебездә ярдәм итте»,—дигәннәр.

Патша: «Бу кеше үз халкына хыянәт иткән, ул безгә дә яхшылык итмәс. Аңа бүләк шул булыр: авызына күп итеп көмеш эретеп салыгыз!» — дип боерган.

Легендалардан үрнәкләр

КӘККҮК НИЧЕК БАРЛЫККА КИЛГӘН?

Ике кызның әниләре чирләп ята икән. Әтиләре намазга киткәч, бу кызлар кычкырышып, шау-гөр килеп уйнаганнар да уйнаганнар. Әниләре:

— Кызым, су бирегезче,— дип тилмереп су сораса да, бу балалар ишетмәгәннәр икән. Шулай итеп ята торгач, әниләре: «И Ходаем, кәккүк булсамчы»,— диюе булган, кәккүккә әверелеп, очып та йөри башлаган. Балалар, әниләренең кошка әверелеп очып йөрүләрен күреп:

— Әнкәем, мә, су бирәбез,— дип елаша башлаганнар. Әтиләре намаздан кайтып ишек ачуга, әниләре очып чыгып та киткән. Ике кыз аның артыннан су тотып йөгергәннәр. Чытырманлыклар, таулар үткәннәр. Елый-елый йөгергәннәр. Боларның күз яше тамган җирдән чылтырап чишмәләр агып киткән, аяк табаннары канап, үләннәргә тамган. Яланда кызыл яфраклар очратканыгыз бармы? Менә шул яфраклар аларның каннары тамганлыктан шулай кызарып калганнар, ди.

Шуңа күрә кәккүк балаларын карамый, йомыркасын чит кош оясына салып китә икән.

ҖИР НИЧЕК ЯРАЛГАН?

Элек заманнарда дөнья тоташ судан гына торган. Кешеләр әле булмаган. Суда балыклар һәм су кошлары гына яшәгәннәр. Шунда бер үрдәк, су төбенә чумып, борыны белән бер кисәк балчык алып чыккан. Бу зурайган һәм шуннан җир хасил булган, ди.

ЗӨҺРӘ КЫЗ

Булган, ди, бер карт белән карчык. Аларның Зөһрә исемле бик матур, бик уңган бердәнбер кызлары булган. Бервакыт карчык үлеп киткән. Үлгән вакытында кызына: «Синең үз гомереңдә бер үтенечең үтәлер»,— дип әйткән, ди. Карчыкны җирләгәннәр. Күпмедер вакыт үткәч, карт икенче карчыкка өйләнгән. Бик усал булган ул карчык. Кызга бер дә көн күрсәтмәгән. Кызның әтисе өйдә булса, бер сүз дә әйтми икән, ә чыгып китсә, җәфалый башлый икән. Барлык авыр эшләрне кыздан эшләткән бу. Шулай бервакыт, эш булмагач, теге карчык иләк белән су ташырга кушкан кызга. Айлы төн икән. Күк йөзе аяз, ди. Йолдызлар җемелдәшеп торалар, ди. Кыз шулхәтле интеккән су ташып, һич түзәр әмәле калмаган. Айга караган да: «Әй Ходаем, җирдә болай интегеп яшәгәнче, айга ашырыр идең мине»,— дигән. Һәм айга ашкан. Җәбердән котылган. Әтисен сагынуын басалмый, гел җиргә карап тора икән ул хәзер тулган ай вакытында.

әмәле — чамасы
җәбер — гнет, угнетение

Сораулар һәм биремнәр

1. Риваятьләр халык авыз иҗатының башка жанрларыннан нәрсә белән аерыла? Аларда нәрсә турында сөйләнелә?
2. Казан турында һәм үзегез яшәгән яки сезгә таныш шәһәрнең, авылның тарихына бәйле нинди риваятьләр беләсез?
3. Легендалар риваятьләрдән нәрсә белән аерыла?
4. Әти-әниләрегездән, олы буын кешеләреннән легендалар һәм риваятьләр язып алыгыз. Әдәбият түгәрәге әгъзалары белән легендаларга һәм риваятьләргә багышланган әдәби кичә үткәрегез.

Шәриф Камал
(1884—1942)

Шәриф Камал (Шәриф Камалетдин улы Байгилдиев) 1884 елның 27 февралендә элеккеге Пенза губернасы Инсар өязе (хәзерге Мордва Республикасының Рузаевка районы) Татар Пешләсе авылында мулла гаиләсендә туа. 1901 елда, бер сәүдәгәргә ялланып, Рига шәһәренә китә. Анда берникадәр вакыт торгач, белемен күтәрү нияте белән, башта Төркиягә, аннары Мисырга юл тота. Ике елдан Россиягә әйләнеп кайта һәм 1903—1904 елларда Украина күмер шахталарында, Каспий диңгезендә балык тотуда эшли.

1905 елны Шәриф Камал Петербургта татар мәдрәсәсендә мөгаллим буларак карщылый. Шул ук вакытта ул «Нур» исемле беренче татар газетасы редакциясендә корректор булып та эшли һәм шушы газета битләрендә шигырьләрен, мәкаләләрен бастыра. 1906 елда яшь авторның «Сада» («Аваз») исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

1907 елда Шәриф Камал туган авылына кайта һәм 1910 елга кадәр мәдрәсәдә балалар укыта. Белемен күтәрү белән дә даими шөгыльләнә. Шушы чорда ул беренче хикәясен — «Уяну» исемле әсәрен яза һәм аны Оренбургта чыга торган «Шура» журналына җибәрә. Озакламый хикәя басылып та чыга.

1910 елда гаиләсе белән Оренбург шәһәренә күчеп килә. Монда ул «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналының үз кешесе булып китә. Бу чорда Шәриф Камал утыздан артык хикәя, дистәләрчә фельетон, мәкалә, атаклы «Акчарлаклар» (1914) повестен һәм «Хаҗи әфәнде өйләнә» (1915) исемле

сатирик комедиясен иҗат итә. Шул чор татар җәмгыятенең төрле якларын, бигрәк тә хезмәт кешеләренең (сезонлы эшчеләр, балыкчылар, шахтерлар), интеллигенция вәкилләре тормышын чынбарлыктагыча һәм үзенчәлекле образларда тасвирлаган «Акчарлаклар» повесте һәм күп кенә хикәяләре белән Ш. Камал татар әдәбиятының үсешенә һәм камилләшүенә сизелерлек өлеш кертә.

Егерменче-утызынчы елларда Шәриф Камал зур күләмле проза әсәрләре һәм драмалары белән таныла. 1927 елда әдипнең «Таң атканда» исемле романы басылып чыга. Анда без «Акчарлаклар» повестендагы Шәрәфи, Газизә, Гариф образлары белән кабат очрашабыз.

1928—1934 елларда Шәриф Камал игътибарын драматургия жанрына юнәлтә. Бу чорда ул бер-бер артлы «Ут» (1928), «Козгыннар оясында» (1929), «Таулар» (1931), «Томан арты» («Габбас Галин», 1934) исемле әсәрләрен яза, һәм алар Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уңыш белән бара.

1937 елда әдипнең «Матур туганда» романы басылып чыга.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, Шәриф Камал каләмен фашист илбасарларына каршы юнәлтә: матбугат битләрендә публицистик мәкаләләр белән чыгышлар ясый, «Марат» хикәясен иҗат итә, «Сафура» пьесасын яза башлый. Ләкин 1942 елның 22 декабрендә әдип кинәт вафат була.

Шәриф Камал — бөтен иҗади таланты һәм иҗтимагый эшчәнлеге белән татар халкының рухи үсешенә армый-талмый хезмәт иткән язучы. Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен ул хөкүмәт бүләкләренә лаек була, аңа шулай ук Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә.

БУРАНДА

1

Яшь бала елый иде...

Тышта җил, буран дөньяның астын өскә китерерлек булып кузгалган, дулый, лапас һәм морҗаларда әллә нинди моңлы җырлар җырлана иде...

Ярты төн узган, эшле, эшсез йоклый, ял итә, әмма бала һаман елый иде. Биш-ун минут туктап тора, тагын башлый... Бишеге янында зыр катып, юатыр өчен газапланган анасы

биграк тә ире белән кунак тынычланып йоклый алмый торганнардыр дип борчыла иде.

Вакыйган, кунак йокламый иде.

Инде авылның төрле ягында этәч тавышлары ишетелә, мөәзин, манарадан азан кычкырып, мөселманнарны йокыларыннан уята... Шул чагында гына бала йоклады...

Хөсәен кунагы белән иртәнге чәй янына утырган иде.

— Буран азрак басылган, ахры...— диде кунак.

Хөсәен, аның сүзен шаяруга юрап, сүзнең киресен аңлата торган тавыш белән:

— Әйе... басылган! — диде.

Һаваның начарлыгы чиктән тыш иде. Тыкрык һәм читән буйларында кар әскертләре тау-тау өелеп, өй һәм сарайлар белән тигезләнә, унбиш-егерме сажиннан читтә бернәрсә күренми, туктаусыз буран улый иде.

Алар бик тәкәллефсез кылана иделәр; чөнки ике ел бергә солдатта булганнар иде. Хөсәен үткән ел ук кайткан иде. Иптәшенең хәзерге кунаклыгы — солдаттан кайтышы иде.

Хөсәен бүген иптәшендә кызык кына бер алышыну күрә һәм гаҗәпләнә иде. Чөнки иптәшенең хәрәкәт һәм кыланышында әллә нинди бер аптырау һәм тыгызлану күрә иде.

Һәрнәрсәгә мыскыл күзе белән карый, бер сүзгә дә инанмый, кеше сөйләгәнне тыңламый, үзе сөйләсә, кешедән көлә торган бер кешенең аптырау һәм оялуы чынлап кызык иде.

Хөсәен чыдамады:

— Мостафа, син әллә ни бүген!..— диде.

— Иптәш, ат әзерләп куй. Миңа тизрәк китәргә кирәк.

— Китәргә? Мондый һавада? «Тизрәге» дә бар тагын.

— Әйе, мөмкин кадәр тиз.

— Мондый буранда, иптәш... барыбер илтүче табып булмас... Бүген кунарсың! Иртәгә!..

— Табылмаса, җәяү китәм!

Бу җавап катгый иде. Ике иптәш бераз эндәшми тордылар. Хөсәен әллә ни генә әйтмәкче иде, Мостафа тагын:

— Әйе, китәм,— диде.

2

Хөсәеннең хатыны Гайшә өстәл җыештырып маташа. Мостафа идән буенча йөри иде. Хөсәен чыгып китте.

Тышта буранның сызгыруы белән стенадагы сәгать тыкылдавыннан башка, өй эчендәге тынлыкны бернәрсә дә боз-

мый, тик бишектә йоклаган баланың ара-тирә көрсенеп ыңгырашулары гына ишетелгәли иде.

— Көн бик начар,— диде Гайшә.— Соравыбызны кабул итмисең инде... бик мазаң китте, ахры; балабыз елаграк шул...

— Сез, аналар... һәммәгез дә шулай!

— Ничек?

— Бала өчен газапланасыз...

— Һәммәбез булмый соң. Йөрәктән төшкән булгач, бар дөнья шул бала өчен...

— Әмма бала усал! — диде Мостафа һәм үзе, бизгәкле кеше кебек, ашыгып-ашыгып киенә иде.

Ике тәрәзә арасындагы көзге турысына килде; башлыгының очларын алдан әйләндереп, артка бәйләп маташа иде. Аның картузы кызыл тирәле булып, шинель погоннарына сары буяу белән Германия императорының вензеле төшерелгән иде: Вильгельм икенче — Калуга полкының шефы, имеш.

Ул тагын:

— Бала усал...— диде.

Бу юлы ул шул сүзләре белән Гайшәгә нидер сөйләмәкче иде, ишектән Хөсәен керде һәм:

— Иптәш, ат әзер! — диде.

3

Һаваның бозыклыгына карамый, хәят, хәрәкәт үз юлы белән бара иде. Бер якта шыгырдап урам капкасы ачыла, кемдер һәм ни өчендер чыгып бара, икенче якта тагын берсе кар астыннан әллә ниләр чыгарып маташа...

Әнә алма кебек кып-кызыл яңаклы бер яшь хатын урам коесыннан су чыгара, өй түбәсендә «карр-каррр» итеп карга карылдый иде.

Шомланучы бичара хатын, кечкенә генә кара ат җигелгән чанага утырып ике кешенең урам буйлап барганын күргәч, сулышын бераз иркенләп алды: гүя карга аларга карап карылдаган, имеш... Кайда карерләр дип бераз карап та торды; аларның кая да кермичә авылны чыгып киткәннәрен күргәч, әллә ни генә уйлап үз-үзенә: «Берсе солдат»,— дип мырылдады һәм чиләген күтәреп китте...

Вакыйган, аларның берсе солдат һәм безгә таныш солдат Мостафа иде.

вакыйган — чыннан да
азан — намазга чакыру өчен манарадан кычкырып укыла торган дога
катгый — кискен, нык карарлы
көрсенеп — авыр һәм тирән итеп сулап
мазаң — тынычлыгың

Сораулар

1. Хикәя башында табигать күренешләре ничек сурәтләнгән? Автор ни өчен бу алымнан файдаланган?
2. Мостафа белән Гайшәнең сөйләшүеннән сез нәрсә аңладыгыз? «Сез, аналар... һәммәгез дә шулай» сүзләре белән автор ни әйтергә теләгән дип уйлыйсыз?
3. Мостафаның «Әмма бала усал!» дигән сүзләренә нинди мәгънә салынган?

4

— Юлны яхшы беләсеңдер бит? — диде Мостафа.

— Белергә беләм дә бит...

Мостафаны авылына илтүче кеше алтмыш яшьлек бер бабай иде. Дөрес, ул юлны белә иде. Алай да җавапны кистереп әйтә алмады: чөнки хәзерендә кырда юл диярлек бернәрсәне югалтмый бару шактый читен иде.

Бабай, тынычсызланып, як-якка карана. Читләрдә бернәрсә дә күренми, тик кар диңгезе генә кайный. Ара-тирә күрелгән сызыклар, чана эзләре — менә бабайның бар ышанычы һәм өметләре иде...

— Менә шул коега бездән дүрт чакрым,— диде бабай,— егерме чакрымлап әле артыгы белән барырга...

Мостафа чикмәннән борынын чыгарып карады, унбиш сажиннар читтә, буран эчендә, кое сиртмәсе салынып чайкалып тора иде.

— Әле дә ерак...— диде Мостафа.

Бераз эндәшми баргач:

— Хода сакласын! Адашмыйк кына,— диде карт.— Хода сакласын... Кайтмыйкмы, дим? Буран артык тилерә бит...

— Барыйк әкертен генә. Анам карчыкны бик күрәсем килә, барыйк. Әйдә әкренләп...

Бу соңгы сүзләр гүя әллә нинди җазибәле бер нәфес белән сөйләнде. Карт моңар сихерләнгән кебек бирелде... Каршысында җәһәннәм яисә кайнап котырып торган диңгез булса да керәчәк иде.

Алар сөйләшми баралар.

Мостафа чикмәнгә чорналган, уйлый: ул кечкенә бала... Төш күрә: әллә нинди, канатлы һәм бик матур балалар белән уйный. Алар аны тарткалыйлар... этәләр... уяна — анасы аны үбеп-үбеп елый.

— Күзем нуры! Атаң мине сөрә... Каласың, бәгърем!— ди.

Атасы читтәрәк кәтеп тора:

— Күрещтең,— кулы белән күрсәтеп,— юлыңны кара!— ди.

. . . .

Ул вакытта Мостафа алты гына яшьтә булса да, шул вакыт күргәннәрен бик вак тәфсыйлатына кадәр хәтерли иде.

Мәсәлән, ул вакытта, йокысыннан уянган чакта, битенә тамган күз яшьләренең кайнарлыгын һәм шул кайнар күз яшьләрен чыланып беткән яулык белән анасының сөртеп маташуын, хәтта яулыкның төсе зәңгәр булып, читләре ак икәнлеген ул хәзер дә ачык хәтерли. Узган төннән бирле гүя шул кайнар тамчылар тагын аның битенә тама һәм пешерәләр... Анасы, куркынган һәм аптыранган хәлдә, чыланган яулыгы белән аларны сөртә...

— Анаң безне сөймәде, иргә китте... Ул сине кыйнарга әйтә икән... Яшь әнкәң безне сөя...

Менә ул вакытларда анасы белән кечкенә кардәше Фатыйманы юксынганда, атасының аңар әйтә торган шул сүзләре аның күңелендә анасына нинди салкынлык һәм нәфрәт хисләре уяндырганлыгын һәм, ниһаять, анасыннан бөтенләй бизгәнлеген уйлап, ул хәзер газап чигә иде.

Ул анасыннан бизгәнмени инде? Әйе, ул үзен тудырган һәм бишеге янында катып, караңгы, тын һәм күңелсез төннәрне «балам» дип йокысыз уздырган анасыннан бизгән иде!

Ул яшьрәк вакытында:

— Син минем анам түгел! — ди иде.

Хәтта бервакыт аның битенә көл сипкән иде. Аны котырттылар.

— Мокай килгән, битенә көл бәр!

— Әйдә!..

Болар һәммәсе яшь вакытында... Әмма зур булгач? Менә хәзер аның беренче мәртәбә бармагын тешләп аптыраганы да — үзенең анасына каршы атасы барында күрсәткән тәрбиясезлекләреннән тыш, атасы үлгәч тә, анасыннан гафу сорамавы, һаман аңар илтифатсыз һәм салкын мөгамәләсе өчен иде...

Төш вакыты узган, буран һаман дулый... Карт бик дикъкатьле һәм җанлы күренә иде.

— Ярты юлны килгәнбездер? — диде Мостафа.

— Артык булыр... Ясту вакытларында җитәрбез,—диде карт һәм янә өстәде: —Хәзер анаң бик сөенеп көтә булыр... Сагынган булыр... Дүрт ел бит!

— Егерме ел... Ләкин... бүген кайтасымны белми ул...

Карт бераз уйга калды.

— Аналар белә... алар сизәләр; алар һаман баланы төзәп торалар...— диде.

Мостафа эндәшмәде. Ул бабайның «төзәп торалар» дигән сүзен аңларга тырыша иде: күңелләре һәрвакыт балада дигән сүздер... Юк! Гаепне «сизәргә» ул гына җитмәс. Юкса җаннары баланы күзәтәме икән?

. . . .

Ахшам вакыты. Авырлык һәм әкренлек белән генә караңгылык пәрдәсе төшә иде.

Мостафаның хыяллары күзенә күренгән кебек була, гүя сөйли дә иделәр.

Ул чикмәнгә бөркәнгән, анасы аның күзенә карап әкрен генә сөйли:

— Мостафа! Күзем нуры, анаң булам... Ник килмисең? Кил, үбим, бәгърем... ачуланмыйм, битемә көл бәрүеңә дә ачуланмыйм... Кил, үбим дә, бер генә мәртәбә анам дип әйт!..

Мостафа, анасының аягына ташланырга дип, чикмәнне ача... Күз алдында очсыз-кырыйсыз караңгылык кына... Бураннан каплана, тагын шул таныш чырай, шул тавышлар...

Ул Мостафага чана янында җәяүләп килгән шикелле күренә... Куәтле һәм кискен җилдән аерылып та, Мостафаның колагы яныннан искән әллә нинди йомшак, шәфкатьле бер җил агымы киңәшеп кенә: «Әйт! Анам дип әйт... Егерме ел инде... ишетәсеңме!..» — ди иде.

Алда, әллә кайларда, диңгез аркылы күренгән төсле, тымызык һәм төмсә ут шәүләләре чагылып тора; Мостафаның колагына, ерактан, кичәнең караңгылыгына кушылып, үзалдына бер моң һәм зар көйли торган тавышлар килә башлады... Этләр өрә иде...

җазибәле бер нәфес — үзенә тартта торган көч
тәфсыйлатына — нечкәлекләренә
бизгән — яратмый башлаган, гайрәте чиккән
илтифатсыз — игътибарсыз, әһәмият бирмәүчән
мөгамәлә — мөнәсәбәт
дикъкать — игътибар
ахшам — *монда:* кичке караңгылык төшә башлаган вакыт
төмсә — томанлы

Сораулар

1. Мостафаның шундый буранлы көндә кайтырга ашкынуы нәрсә белән бәйләнгән?
2. Мостафаның кайсы сүзләре карт өчен аеруча тәэсирле була? Ни өчен?
3. Бу бүлектән Мостафаның бала чагы турында ниләр белдегез? Аның әтисе һәм әнисе турында сездә нинди фикер туды?

5

Ахшам үтте. Буранның котыруына карамыйча, капкадан йөри иделәр... Хатыннар берсе килеп кергәндә, икенчесе бик кайгылы кыяфәттә чыгып бара һәм күңелсез генә берәр сүз катыша иделәр...

Тәрәзә алдына яткан сары эт, зур һәм кара күзләрен сөзеп, килгәнне каршы ала, киткәнне моңлы күзләре белән озата иде. Ул гүя кайгылы иде... Аның сөйгән тәрбиячесе, хуҗа хатын, бу кич инде үлемнең куркынычлы тырнаклары арасында сугыла иде...

Аның яме киткән, төсе балавыз кебек саргайган, күзләре төпкә баткан, кул һәм аягы салкын, күкрәге бер кабарып, бер төшеп, авыр-авыр сулый. Бичара хатынның хәяттән өлеше бетеп килә иде...

Илле ел тәнен, уен идарә иткән җан үзенең иске тонык тәрәзә кебек күзләреннән кемгәдер актык мәртәбә карап тынычланып китәсе килә иде. Бичара хатын, кызганыч ана күзләре белән нидер эзли, нидер юксына, кемнедер күрмичә үләсе килми; торып-торып:

— Килмәдеме?— дип сорый иде.

Кызы Фатыйма бертуктамый елый.

Анасының бер тәүлектән бирле тәкрар иткән шушы «килмәдеме» сөальләре аның күңелендә әллә нинди тирән һәм иске җәрәхәтләрен яңадан ача иде...

Өч атнадан бирле авырып яткан анасы узган кич беренче мәртәбә төн уртасында:

— Фатыйма! Тор. Тизрәк чыгып кара... Килмәдеме? — дип, аны куркыткан иде.

Менә шуннан бирле һаман көтә...

Көн уртасында инде сабырсызлык күрсәтә һәм саташа башлады.

Икенде белән ахшам арасында тартышып-тартышып елады: гүя аның бер дә тиңсез сөекле баласы бар, имеш, алар гомер буена күрешә алмыйлар, кемнәрдер күрештермиләр, имеш. Хәзерендә дә ул анасының актык сулышында актык бурычын түләргә, анасы белән күз-күздән мәхәббәт яшьләре түгешергә килгән, имеш. Ләкин... бичараны кертмиләр, әллә кайларга кайтарып җибәрәләр, имеш...

Ахшам вакытында аның тавышы беткән иде инде. Шулай да һаман әлеге «килмәдеме» дигән сүзне батык күзләре, күгәргән иреннәренең хәрәкәте белән аңлатырга тырыша иде...

Бичара ана! Биш-ун сулыш, һәрбере бер газап, һәрбере бер җәһәннәм ялкыны... сулаган саен йөрәге урыныннан куба, сулаган саен үпкәләре ерткалана, күз алдына каралы-яшелле пәрдәләр корыла, үзе төпсез-кырыйсыз юклыкка китә бара... Шуның өстенә, бала хәсрәте белән дә изелә, газаплана иде.

Шәфкатьле ана! Кашки, бу кадәр вакыт хәсрәт чикмәгән булса иде. Әй мәрхәмәтле ана! Кашки, соңгы сәгатьләреңдә генә аз гына булса да, «аны» онытса иде... бәлки, биш-ун дәкыйка — күрешү дәкыйкаләре белән файдаланырга да мөмкин булыр иде...

Аның инде кул һәм аяклары сизми, кузгалмый, салкын һәм авыр ташлар шикелле түбән тарталар... Ул бик әкрен генә төпсез һәм салкын диңгез төбенә төшеп бара... Хәзер инде күз алдында ул каралы-яшелле пәрдәләр дә юк, ул бик ерак күрә, гомердә күрмәгәнен күрә... бик югары күрә, бик якты күрә, кояштан әллә ничә мәртәбә артык яктылык күрә... Менә шул яктылыкның сузылып килгән нечкә бер тармагы гына аны күкрәгеннән асып тота... Ул нечкә тармак та авырлыкка чыдамый: бушый, җибәрелә бара... Бу һаман төпсезлеккә китә, түбән киткән саен, диңгез салкынлана бара... Зарарлы түгел... Ләкин... аһ, ялгызы гына... Кашки, «ул» да бергә булса иде... Әллә кайларда адашып кала торгандыр.

Тармак өзелергә күп калмый, нечкәрә...

Чү! Ишегалдында кемнәр?

Ишек ачылды. Керделәр... Ике кеше.

Берсе катып калды... тезләнде... Елаган тавыш белән:

— Анам! — дип кычкырып җибәрде дә карчыкның күкрәгенә йөзен куеп елый башлады... Бу Мостафа иде.

— Килдем... Шәфкатьле анам! Бер генә йөземә кара. Анам, җаным, күзем... Анам!..— дип, акырып-акырып елый, әмма анасы илтифат итми иде... Ул гүя үпкәләгән иде. Аh!.. Кашки, ул бер генә карасын!..

Ләкин ул инде карый алмый иде... Чөнки әлеге нечкә тармакның чыганакларына карап торган көенчә, очыннан ычкынып киткән иде...

Тышта буран һаман дулый иде.

балавыз — воск
тәкрар иткән — кабатлаган
сөаль — сорау
дәкыйка — минут

Сораулар һәм биремнәр

1. Үлем хәлендә яткан ананың кичерешләре турында сөйләгез. Аларны сурәтләү өчен автор нинди алымнардан файдаланган?
2. Хикәядә сурәтләнгән ана образы сездә нинди хисләр уятты? Автор бу образ ярдәмендә укучыларга нәрсә әйтергә теләгән дип уйлыйсыз?
3. Ни өчен әсәр «Тышта буран һаман дулый иде» дип тәмамлана? Үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.
4. Табигать күренешен тасвирлаган урыннарны табыгыз. Ул кеше күңеленә ничек тәэсир итә?

Хикәя

Хикәя — артык катлаулы булмаган хәлләрне, тормышкөнкүрешнең бер вакыйгасын, кеше холкының һәм эчке дөньясының аерым сыйфатларын сурәтләгән кечкенә күләмле әдәби жанр.

Хикәя әдәбиятның эпик төренә карый. Ул җыйнак һәм шактый күләмле булырга мөмкин. Шуңа күрә кайбер очракта бер үк әсәрне хикәя дип тә, повесть дип тә әйтәләр. Мәсәлән, Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» әсәрен шулай ике төрле атап йөртәләр.

Хикәянең ерак гасырлардан килгән традицияләре бар. Ул халык иҗаты әсәрләреннән (миф, легенда, әкият, мәзәк жанрларыннан) үсеп чыга.

Хөснул Вәлиуллин
(1914—1993)

Композитор, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хөснул Вәлиуллин (Хөснулла Вәлиулла улы Вәлиуллин) 1914 елның 28 февралендә Саба районының Байлар Сабасы авылында дөньяга килә. Аның бала чагы һәм үсмерлек еллары шушы авылда үтә. Татар халык җырларын, моңнарын кечкенәдән үк ишетеп үскән бу балада музыкаль сәләт бик иртә ачыла. Авыл клубы каршындагы үзешчән сәнгать көчләреннән торган тынлы оркестрда скрипка һәм кларнетта уйнарга өйрәнеп, уналты яшьлек тимерче егет Хөснулла үзе дә көйләр чыгара башлый.

1935 елда Казан музыка училищесы укытучылары Татарстан районнарында, авылларында булалар һәм, музыкага талантлы яшь көчләрне укырга тарту максаты белән, үзешчән сәнгатьтә катнашучылар чыгышларын карыйлар. Хөснулла, шул укытучыларның чакыруы буенча, Казанга килеп, махсус музыкаль белем ала башлый.

1940 елга кадәр ул Казан музыка училищесының теоретик-композиторлык бүлегендә укый. Биредә укыган елларында ук җырлар, тынлы оркестр өчен әсәрләр, фортепиано һәм виолончель өчен пьесалар яза. Хөснул Вәлиуллинның киң танылган «Яз» (Хәй Вахит шигыре), «Тракторчы кыз», «Онытырга мөмкин түгел» (Әхмәт Ерикәй шигырьләре) кебек җырлары бүгенге көндә дә халык арасында яши. Ул җырларда композитор, авыл тормышына бәйләнешле күренешләрне музыкаль образларда гәүдәләндерә.

Музыка училищесын тәмамлагач, сугыш башлана, һәм Х. Вәлиуллин фронтка китә. Казанга сугыш беткәч кенә кайта.

1945—1950 елларда Хөснул Вәлиуллин Казан консерваториясендә укый. Бу елларда ул җиңү шатлыгы белән сугарылган «Яз айлары», «Ватаным» (Хәй Вахит шигырьләре) һ. б. җырлар иҗат итә. Бу әсәрләрдә аның иҗатына хас сыйфатлар — музыкаль формаларны оста тою, образлылык, фикер һәм хисне белдерүдә җыйнаклык һәм төгәллек, халык моңнарын яхшы белү нык сизелә. Аның Сибгат Хәким сүзләренә язылган «Урал суы буенда» балладасы, «Тын Иделкәй», «Тынычлык турында» исемле әсәрләренә язылган җырлары үзенчәлекле яңгыраш белән аерылып тора.

«Самат» операсы — Х. Вәлиуллинның беренче зур әсәре. Ул Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында, шулай ук Мәскәүдә 1957 елда уздырылган татар сәнгате һәм әдәбияты көннәрендә куелды. Тамашачылар аны бик җылы каршылады.

Хөснул Вәлиуллинның 1965 елда С. Җәләл әсәре буенча иҗат ителгән «Дим буенда» операсы да татар опера сәнгате өлкәсендә аерым урын алып тора.

Композиторның иҗаты бик бай. Ул Г. Тукай, М. Җәлил, Н. Исәнбәт, Х. Вахит, С. Хәким, Г. Зәйнашева һәм башкаларның шигырьләренә бик матур җырлар, романслар иҗат итте.

Күренекле язучыбыз Гариф Ахунов Шәриф Камалның «Акчарлаклар» повесте буенча сценарий язган иде, музыкасын Х. Вәлиуллин иҗат итте. Шушы сценарийдагы «Акчарлаклар» (Рәшит Әхмәтҗанов шигыре) җыры бүгенге көндә дә сәхнәдән төшми җырлана.

Х. Вәлиуллинның татар музыка сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медаленә лаек була, аңа Татарстанның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә.

1989 елда Хөснул Вәлиуллинга Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

Ул 1993 елның 24 сентябрендә Казан шәһәрендә вафат була.

Зәйнәп Хәйруллинадан

АКЧАРЛАКЛАР

Рәшит Әхмәтҗанов шигыре — *Хөснул Вәлиуллин музыкасы*

Кораб китте еракларга зур юлларга,
Карыйм күздән югалганчы шул якларга.
Сез китмәгез, акчарлаклар, акчарлаклар,
Чит җирләрдә каерыла пар канатлар.

Мәхәббәтне ала алмый бер упкын да,
Хыянәтне күтәрә алмый бер дулкын да.
Сау булыгыз, акчарлаклар, акчарлаклар,
Кавышуны вәгъдә итә пар канатлар.

Сөйгән ярым китеп барды кулын болгап,
Кайтыр микән тагын миңа, юллар урап.
Сау булыгыз, акчарлаклар, акчарлаклар,
Мәхәббәткә кирәк икән пар канатлар.

Сораулар һәм бирем

1. Хөснул Вәлиуллинның музыка дөньясына килү сәбәпләре нәрсәдә?
2. Ул нинди жанрларда эшли? Аның иҗатына нинди үзенчәлекләр хас?
3. Х. Вәлиуллин көй язган «Акчарлаклар» җырын сыйныфыгызда тыңлаганнан соң, бу җырның көе һәм сүзләре арасындагы бәйләнеш турында фикер алышыгыз.

Гаяз Исхакый

(1878—1954)

ҖАН БАЕВИЧ

Көлке дүрт пәрдәдә

(Комедиядән өзекләр)

УЙНАУЧЫЛАР:

Шакирҗан — авылдан килгән сәүдәгәр.
Сәхипҗамал — аның хатыны, авыл кызы.
Миңлебай — авыл карты, Шакирҗанның атасы.
Миңлекамал — Шакирҗанның анасы.
Әнвәр — Шакирҗанның угылы, ун-унбер яшьләрендә.
Халидә — кызлары, тугыз-ун яшьләрдә.
Асрау.
Федосия — Шакирҗанның марҗасы.
Закир — хезмәтче.
Тегүче — урыс.
Нечкә марҗа.
Музыкантлар — урыслар.
Сатучылар.
Тегүче кыз.
Хаим Соломонович — яһүди сәүдәгәре.
Полиция түрәләре.

Беренче пәрдәнең кыскача эчтәлеге[1]:

Вакыйга Шакирҗан гаиләсендә бара. Ул, авылдан шәһәргә килеп, сәүдә эше белән шөгыльләнә, бераз байый, ә хатыны Сәхипҗамал йорт эшләре белән мәшгуль, 2 баласын тәрбияли. Бу гаилә бик тыныч, тату яши; хатыны да, балалары да Шакирҗанны хөрмәт итәләр, аны олылыйлар. Шулай матур гына яшәп ятканда, кинәт Шакирҗанның башына уй төшә. Ничек итеп культуралы кеше булырга?

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зур бер зал. Бер почмагында зәңгәр вә яшел төсле урындыклар. Бер почмагында ак буяулы хатын-кыз шкафы. Бер почмагында озын рояль. Аның өстенә әллә никадәр кылычлар, мылтыклар асылынган, көзгеләренең башларына кош гәүдәләре эленгән. Урта бер җирендә ябыла торган биек язу өстәле. Диварда алтын рамда Шакирҗанның зур иттереп эшләнгән үз рәсеме, аның бер ягында солтан рәсеме, бер ягында бер урядник рәсеме. Диварларда әллә ничә төрле сәгатьләр, кайсыберсе уйный торган, кайсыберсе уята торган. Зал уртасында биек өстәл янында әйләнә торган биек урындыкка менеп Шакирҗан утырган. Аның өстендә фрак, муен бавы ачык кызылдан, жилеты яшел төстә. Аягына ак туфли берлә сары гетр кигән. Өстәл өстендә төрле-төрле кыңгыраулар.

Шакирҗан. Авыр бу безнең надан халык берлә эш итү, һичбер тәрәккый пәрвәрлек юк. *(Бер шалтырата.)*

Асрау килеп керә.

Асрау. Абзый, нәрсә кирәк?

Шакирҗан *(кулы берлә өстәлгә сугып)*. Мин сиңа нинди абзый? Абзый! Татар төсле авызын тутырып әйтергә өйрәнгән. Мин сиңа ничек әйттем, мине һәрвакыт «господин Җан Баевич» дип дәшәргә. Икенче: мин сине чакырмадым. Кил бире! *(Асрау килә.)* Йә, менә бу шалтыравыклар берлә кемне чакырам?

Асрау. Кемне теләсәң — шуны.

Шакирҗан. Теләсәңез, кемне теләсәң түгел, ул «необразованныйлык» була. Тәрәккый пәрвәр кешенең һәрвакыт эше юллы булыр. Менә кара! *(Бер шалтыравык күрсәтә.)* Менә бусыны шалтыратсам, Захарны чакырган булам. Менә

---

[1] Әсәрләрдәге кыскартылган өлешләрнең эчтәлеге дәреслек авторлары тарафыннан бирелде.

бусыны шалтыратсам — кучерны, менә бусыны шалтыратсам — госпожаны. *(Һәммәсен шалтыратып күрсәтә.)* Йә, хәзер мин кемне чакырган булам?

Асрау. Закир абыйны...

Шакирҗан. Әйттем мин сиңа, Закир түгел, Захар дип. Бу нинди бу тәрәккый пәрвәр түгеллек. *(Асрау чыга башлый.)*

Шакирҗан. Тукта, чыкканда ни эшләргә кирәк?

Асрау. Ә! Белдем! *(Реверанс ясамакчы була, булдыра алмый.)*

Шакирҗан. Алай түгел! *(Үзе ясап күрсәтә. Үзе дә бик көлке ясый... Асрау чыга.)* Менә болар берлә эш ит, ә! Бу нинди необразованныйлык. Өйрәтәм, өйрәтәм, һич юлга салып булмый!..

Тагын шалтыравык шалтырый. Закир килеп керә: билендә кара алъяпкыч, башында чуклы кәләпүш, өстендә билле камзул.

Закир. Ни йомыш, абзый?!

Шакирҗан. Элгәре сөйләргә өйрән! Аннан минем яныма кер. Мин сиңа ничә мәртәбә әйттем: господин Җан Баевич дип дәшергә. Йә, бире кил!

Закир. Мин монда гына торам, абзый!

Шакирҗан. Монда, монда. Ярамый алай әйтергә — монда. Ул необразованныйлык! Тәрәккый пәрвәр булырга кирәк. Боярлар алдында әйтсәң оятлы булырсың: «монда», имеш!

Закир. Безне кечкенәдән шулай өйрәткәннәр инде. Ни йомыш бар соң, абзый?

Шакирҗан. Абзый түгел, господин Җан Баевич!

Закир. Йә, шулай булсын. Әле мин самовар агарта идем, ни йомышың бар?

Шакирҗан. Менә шул төенне ал. *(Закир килеп ала. Шакирҗан чишәргә куша, Закир чишә. Аның эченнән лакейлар кия торган, укалап теккән кием чыга.)* Менә бу сиңа! Моннан соң син һәрвакыт шуны киеп йөр, тәрәккый пәрвәр бул, йә, киеп кара!

Закир *(киемне карап)*. Бу, абзый, урыс киеме икән. Аллам сакласын аны кияргә!

Шакирҗан. Әй утын, утын! Үзеңнең файдаңны үзең белмисең. Мин сине кеше итәргә телим, син һаман үзеңнең татарлыгыңда. Йә, ки!

Закир көчләнеп кенә кия. Кара алъяпкычы, зәңгәр чуклы кәләпүше берлә аның кыяфәте бик көлке була. Ул көзге каршында кычкырып көлә.

Ш а к и р җ а н. Менә син һәрвакыт шул киемдә булырсың, син ишек төбендә килгән кунакны каршы алып, озатып кына торырсың. *(Шалтыравыкны күрсәтеп.)* Шуны шалтыратсам, минем яныма керерсең!

З а к и р *(үзенә үзе сөйләнеп)*. Казаки тектерергә яхшы нәрсә икән.

Ш а к и р җ а н. Бар, чык! Аннан миңа һәрвакыт господин Җан Баевич дип кенә эндәшерсең, мин сиңа Захар дип эндәшермен.

З а к и р *(башын кашып)*. Ник алай әйтик, абзый? Миңа да Закир гына димисеңме? Мулла кушкан исемем бит! Сиңа да Шакирҗан... абзый гына диим инде?!

Ш а к и р җ а н. Бар, бар! Син аңламыйсың, син аз гына да тәрәккый пәрвәр түгел. *(Торып йөрергә тотына. Зур залда җиһазларга барып бәрелә, тулгана. Йөрергә бик уңайсыз була, ул анда бәрелә, монда бәрелә.)*

З а к и р *(килеп керә)*. Абзый, бер әллә нинди урыс килде. Бик мәхәббәтсез, әллә нәрсә сөйли. Шакирҗан Миңлебаевич өйдәме, ди.

Ш а к и р җ а н. Җан Баевич, диң.

З а к и р. Мин әйтмим, ул әйтә.

Ш а к и р җ а н. Керсен. *(Үзе урынына менеп утыра.)*

У р ы с *(кереп)*. Исәнмесез, Шакирҗан Миңлебаевич?

Ш а к и р җ а н *(үз-үзенә)*. Бусы да затсыз: Җан Баевич!

У р ы с. А-а, Җан Баевич, Шакирҗан Миңлебаевич! Менә мин сезнең балаларга дигән киемнәрне китердем. Первый сорт булды.

Шакирҗан акыртын гына бер шалтыравыкны шалтырата.

А с р а у *(килеп керә)*. Нәрсә, абзый?

Ш а к и р җ а н. Тагы «абзый», мин синең авызыңны бәреп сындырырмын. Мин сине чакырмадым. Мин госпожаны чакырдым.

А с р а у. Әле абыстай пилмәнгә камыр баса иде.

Ш а к и р җ а н. Соңра басар. *(Асрау чыга башлый. Тегүче киемнәрне чишә.)*

Ш а к и р җ а н. Чыкканда нишлиләр?

А с р а у. Әй, оныттым инде, абзый. *(Реверанс ясый.)*

Ш а к и р җ а н *(тегүчегә)*. Менә бу затсызлар берлә дөнья көт. Необразованный безнең татар халкы.

Т е г ү ч е. Да, да, Шакирҗан Миңлебаевич!

Ш а к и р җ а н *(чыраен сытып).* Җан Баевич!

Т е г ү ч е. Да, да, Җан Баевич. Шакирҗан Миңлебаевич!..

С ә х и п җ а м а л *(килеп керә, кулы камырлы).* Нәрсә, карт? Мин бүген салма пешерермен дип камыр ясап тора идем.

Ш а к и р җ а н. Ничек дисең?

С ә х и п җ а м а л. Нәрсәгә чакырдың дим, карт!

Ш а к и р җ а н. Карт... Карт! Син, госпожа, саташасыңмы әллә?! Карт?! Ничек әле синең образованный исемең, ә, Софичка, госпожа Софичка! Менә бу тегүче безнең газиз балаларымызга киемнәр тегеп китергән.

С ә х и п җ а м а л *(аптыраган кеше төсле).* Син әллә инде гакылдан яздыңмы? Әллә сине җиде ясин чыгарып өшкертикме?..

Ш а к и р җ а н. Затсыз, образованныйлыкны аңламый.

Тегүче киемнәрне Сәхипҗамалга китереп күрсәтә.

С ә х и п җ а м а л. Әбәү! Нигә бик ямьсез, карт? Теге курчак кәмитендәге малайныкы төсле.

Ш а к и р җ а н. Затсыз...

Т е г ү ч е. Первый сорт.

Шакирҗан бик дикъкать берлә генә, урынына утырган көенчә, ике шалтыравыкны бердән шалтырата. Бер ишектән З а к и р килеп керә, бер ишектән — а с р а у.

И к е с е д ә. Нәрсә йомыш, абзый?! *(Сәхипҗамал аптырап тора.)*

Ш а к и р җ а н *(өстәлгә кулын сугып).* Абзый түгел, господин Җан Баевич!

З а к и р. Әйе, әйе, господин Шакирҗан абзый!..

А с р а у. Госпожа... Җан абзый.

Ш а к и р җ а н. Затсызлар, необразованныйлар, господин Җан Баевич...

С ә х и п җ а м а л. Нигә соң аларга ул кирәк? Кеше төсле генә сөйләсәң ни була?..

Ш а к и р җ а н. Ә, ничек әле, Захар?..

С ә х и п җ а м а л. Әстәгъфирулла диең! Ничек, мөселман исемен урысча бозып әйтергә ярыймыни? Тәүбә, тәүбә! Тфу, тфу...

Ш а к и р җ а н. Необразованныйлар. Бар әле, Захар... Мөхәммәд Әнвәретдин мирзаны бирегә алып кил!..

З а к и р. Мондамы?..

Ш а к и р җ а н. Монда түгел, бирегә.

Закир *(башын кашып)*. Бирегә, дисең. Ярый, сезнең ихтыяр, аны да урыс итәсезмени?..

Сәхипҗамал. Авызыңнан җил алсын, әстәгъфирулла диең!..

Закир. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, тфү, тфү!..

Шакирҗан *(асраугa)*. Тукта әле. *(Кәгазьгә карап.)* Әйе, фрулэен Халидәне бирегә тәшриф җәнаб иттер!..

Асрау. Халидәне, абзый, нишлим? Безнеңчә генә әйт әле, абзый! Валлаһи, ул бик матур курчак уйный иде. Ник ул фәриле булсын!

Шакирҗан. Необразованный! *(Урыныннан торып, йөрергә тотына. Әле анда бәрелә, әле монда бәрелә.)*

Сәхипҗамал *(янына килеп)*. Сиңа ни булды, карт, әллә үзеңне пәри алмаштырдымы? Хәзрәтләр чакыртып, Коръән чыгарыйкмы әллә, карт?

Шакирҗан. Кит, кит, затсыз, необразованный. *(Бердән өч шалтыравыкны да алып шалтырата.)*

Бер агач ат өстерәп — Әнвәр, курчаклар күтәреп, Халидә килеп керәләр.

Алар *(куркынып)*. Әти, ни булды? Әни, ни булды?!.

Шакирҗан. «Әти», «әни», ул ни дигән сүз? «Маман» диең, «маман»!

Балалар *(әниләрен килеп кочаклыйлар)*. Кирәкми, әти бәгърем, кирәкми, әни, дим, әни... Кирәкми, әти бәгърем...

Шакирҗан *(аяк тибеп)*. «Әти» түгел, «папа» диең.

Балалар. Кирәкми. *(Халидә еглаpгa тотына.)*

Шакирҗан *(балаларның өстенә килеп)*. «Папа» диең...

Халидә *(яшь арасында)*. Папа, папа! Мәхәббәтсез әти... *(Әнвәр дә еглаpгa тотына.)*

Шакирҗан. Менә боларны образованныйлыкка өйрәт! *(Тегүчегә.)* Китер киемнәрне! *(Балалар әниләре янына сырылыша.)*

Тегүче. Кием первый сорт. *(Әнвәргә гаскәри бер кием кигезә. Бер ягына кылыч тактыра. Бер ягына револьвер астыра. Башында кәләпүш, аякта читек, малай кызарып тора. Асраулар пырх-пырх көләргә тотыналар.)*

Сәхипҗамал. Бу нинди мәсхәрә?! Син әллә угылымны кәмитче ясамакчы буласыңмы?

Шакирҗан. Син белмисең, син бояр халкыны күрмәгән!

Тегүче. Первый сорт. Менә бусы барышняга. *(Канатлы-канатлы әллә нинди төстәге киемне Халидәнең өстенә сала.)*

Асраулар. Пәрәмәч, борчак куркынычы булды! *(Кычкырып көлә башлыйлар. Халидә еглый. Шул арада уйный торган сәгать шалтырый.)*

Шакирҗан *(кәнәфигә барып утыра).* Беләмсез бу нидән хәбәр бирә? Господин Җан Баевичның уйларга вакыты җитә, тирән, зур уйлар уйларга вакыты җитә дигән сүз... Мин, сезнең кебек, камыр басу, самовар куюларны гына уйламыйм. Дөньяның йөреше, дөньяны образованныйлаштыру хакында төшенәм. *(Тагы бер күкеле сәгать күкесе кычкыра.)* Менә монысы икенче хәбәрне бирә!.. Господин Җан Баевич, уеңны җәй, әзер бул дигән сүз!..

Тегүче. Хисабы, господин Шакирҗан Миңлебаевич...

Шакирҗан. Башка чакта, башка чакта! Мин хәзер мәшгуль, зур эшләр берлә мәшгуль.

Тегеләр аптырап карап торалар... Шуннан өченче сәгать «Во саду ли в огороде» көен уйный башлый.

Шакирҗан. Вон, барыгыз да вон, хәзер господин Җан Баевич уйга чума!

Тегүче чыга. Асраулар да көлә-көлә чыгалар. Шакирҗан, кулы берлә башын тотып, уйга чума.

Сәхипҗамал *(янына килеп).* Ни булды сиңа, җаным, әллә урыс шаукымы кагылдымы? Нинди һәйбәт тора идек. Әллә күз тидеме? Әллә бер-бер дошман боздырдымы? *(Шакирҗан, кит дип, кулы берлә ишарә итә. Сәхипҗамал Шакирҗанны кочаклап.)* Әллә, җаным, Камчылы ишанны чакырып өшкертикме?..

Шакирҗан *(торып бәреп җибәрә).* Мин сиңа әйттем, мин тирән уйлар, бик тирән уйлар уйлыйм дип. Син үзеңнең вак, кечкенә өшкертүләрең берлә чуаласың, син кайчан образованный булырсың? Без хәзер андый вак татар эшләреннән, татарның необразованный гадәтләреннән үскән. Мин хәзер собственный дом Горчичный улица имею, мин хәзер Җан Баевич, образованныйлыкка сезне өйрәтәм!..

Сәхипҗамал. Ни гөнаһ шомлыгы булды икән? *(Егларга тотына.)* Кемнең генә күз яше төште икән?!

Шакирҗан *(килеп).* Менә сиңа, матушка, образованный булырга тырышырга кирәк!

Сәхипҗамал. Мин ни диеп Матушка булыйм, ди. Мин, Аллага шөкер, Сәхипҗамал, син үзең Матушка!..

Шакирҗан. Мин сиңа образованныйларча гына дәшәм!

Сәхипҗамал. Дәшмә миңа.

Бер сәгать барабанлы көй уйный башлый.

Шакирҗан *(тыңлап торып)*. Менә бу ни дигән сүз икәнен белмисең? Бу — господин Җан Баевичның уйлау вакыты үтте. Ул — үзенең тирән, зур, олуг-бөек уйларыны үзенең зур башында уйлап бетерде дигән сүз. Менә бу көн син, затсыз, комачауладың, господин Җан Баевич бу дөньяның хәле хакында рәтләп уйлый алмады. Ни булыр бу дөньяга? Кызганыч бу дөньяның зәгыйфь адәм балалары!..

Закир *(килеп керә)*. Абзый! Ике урыс килде, бер маржа, эте дә бар...

Шакирҗан. Ә, ул музыкантлар. Балаларны чакырыңыз!

Ишектән ике урыс, бер маржа килеп керәләр. Алар бик үтә үк киенгәннәр.

Килүчеләр. Исәннәрмесез, Җан Баевич!

Шакирҗан. Аллага шөкер, Аллага шөкер! *(Хатынына карап.)* Менә образованныйлык ничек була!

Тегеләрнең берсе кәманын чыгара, берсе гармунын. Хатын рояльгә утыра. Балалар керәләр.

Шакирҗан. Менә музыка башлана. Аны бик ихлас берлә тыңлаңыз. Ул күңелеңне нечкәртә. Тирән уйлар уйлата. Менә шулай кулны куеп тыңлаңыз. *(Үзе өстәлене менеп утыра да кулына таяна; бер кыска гына таяк берлә селкеп җибәрә. Тегеләр «Камаринский»ны уйныйлар. Шакирҗан башын селкеп.)* Мин тирән уйларга чумдым. Бик татлы эшләр уйладым.

Тегеләр урысның икенче бер урам көен уйныйлар. Шуннан соң:

Бер урыс. Господин Җан Баевич, мадмуазель Мариның авызы кибеп китте. Берәр нәрсә эшләргә булмасмы икән?

Шакирҗан *(шалтыравык шалтырата. Закир керә)*. Ә, Захар! Господаларга поднос берлә коньяк керт. Капкаларга да булсын.

Бераздан Закир коньяк, шуның янына чәкчәк куеп кертә.

Урыслар. Бик рәхмәт, сезнең исәнлеккә! *(Эчәләр.)*

Шакирҗан *(хатынына).* Менә образованныйлар ничек! Захар, госпожа берлә миңа да кадәх китер...

. . . .

тәрәккый пәрвәр — алдынгы карашлы кеше
затсыз — әдәпсез, тәртипсез
салма — шулпага салып пешерелә торган ашамлык, токмач камырыннан ясала
тәшриф җәнаб итү — рәхим итү (килү)
кәман — скрипка
кадәх — савыт (бокал)

Сораулар

1. Шакирҗан «образованный»лыкны ничек күз алдына китерә? Сез аның бу фикере белән килешәсезме?
2. Сәхипҗамал кем ул? Аңа нинди сыйфатлар хас?
3. Шакирҗан йортына килгән музыкантлар турында сездә нинди фикер туды? Ни өчен?

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шакирҗан. Унике...

Хаим. Аннан, менә шул китап шкафы, тәрәзәдәге пәрдәләр, ишектәге асмалар — барысы биш йөз сум.

Пристав. Тагы?

Хаим. Минем дәртем почмакланды. Бетте, господин пристав. Сезне шуның өчен өшәндердек, гафу итеңез! Гафу итеңез, господин Җан Баевич! Гафу итеңез, графиня! Мин бит сатарга түгел, әле күңел тыныч булсын дип кенә!.. Мин бит кечкенә кеше, мин бит сезнең берлә низагка кермим. Акчамны бирдеңез, хәзер бетте!.. *(Пристав шул арада шәм яндырып, мөһерләр сугып йөри.)* Минем бит өч балам бар, беләсезме? Өч балам!.. Алар ашарга сорыйлар, киенергә сорыйлар!.. Гафу итеңез!..

Итче *(приставка).* Минем дә алачагым бар!

Аның артыннан башкалар. Господин пристав, минем дә менә алачагым бар, минем өчен дә яз!.. Минеке дә бар, минем өчен дә яз!

Тегүче кыз. Господин пристав! Мин хезмәтче кыз, тегүче кыз, зинһар, минем акчамны алып бир! Хуҗа хатыны: «Акча алып кайтмасаң, куып чыгарам»,— диде... Минем

әнием карчык, сеңлем яшь... Мин ни эшләрмен, господин пристав? *(Үзе еглый.)*

Пристав *(бер кәгазь күрсәтеп)*. Менә шундый мәхкәмәдән чыккан кәгазь китерегез, мин хәзер! Болай мин яза алмыйм!

Ишек ачыла. Аннан авыл киемендә, кулына таяк тоткан Миңлебай карт һәм дә аның карчыгы килеп керәләр.

Миңлебай. Ә, шундамыни бу бәддога төшкән, Алланың каһәре суккан? Сөяк сындырып, илне, көнне мәсхәрә итеп йөрергә ничек оялмадың?.. *(Шакирҗан янына барып басып.)* Тфү, мәлгунь!

Карчык. Ник соң, балакай, болай булдың? Изгеләр бәддогасыдыр шул! *(Еглый.)* Киртә үк сикердеңме?

Шакирҗан *(каушанып)*. Әти, әни!.. Әти, әни! Валлаһи, юк! Валлаһи, юк!

Миңлебай. Нәрсә ялганлыйсың?.. Болар нәрсә? Оятсыз! *(Шакирҗанның үз рәсемен күрсәтеп, таягы белән Шакирҗанны кыйнарга тотына.)*

Шакирҗан. Алла! Алла!

Миңлебай. Алланы искә төшердеңме? *(Һаман кыйный.)*

Карчык *(килеп)*. Җитәр, карт, җитәр!

Миңлебай. Мин сиңа күрсәтермен киртә сикерергә!

Шакирҗан. Валлаһи сикермәдем!.. Мин тәрәккый пәрвәр генә булырга теләгән идем!

Марҗа *(килеп)*. Бу нинди необразованныйлык!.. Кайчан графларда, князьләрдә кереп кешене кыйнаганны күргәнегез бар? *(Килеп, Миңлебайны туктатмакчы була.)*

Миңлебай *(борылып)*. Бу ни? Каһәр суккан! Синмени мәткәсе? Синмени?

Марҗа. Мин — графиня!

Миңлебай. Син — графиня?! *(Марҗаны таяк белән кыйнарга тотына. Марҗа акыра.)*

Халык *(килеп)*. Җитәр, бабай!

Миңлебай. Нигә безнең динне мыскыл итә! Безнең динне бит ул мыскыл итә!

Шакирҗан. Әти, юк, валлаһи, юк! *(Карт тагы аны кыйнарга керешә.)*

Халык. Җитәр инде, бабай, җитәр!

Миңлебай. Сез мине ничек тыясыз? Мин үз өемдә теләсәм ни эшләрмен!.. Мин өч ел старшина булдым! Это мой баранчук.

Карчык *(Шакирҗан янына килеп, картны аера)*. Ярар, ярар инде, тәүбә итәр, карт!

Шакирҗан. Иттем!.. Валлаһи менә тәүбә иттем, кайттым, тәүбә иттем... Кайттым!

Миңлебай *(тагы җикеренеп, таягын күтәреп, Шакирҗанга таба бара)*. Үтерәм мин сине, мордар! Әйт, киртә сикердеңме?

Шакирҗан. Валлаһи сикермәдем, әти, валлаһи сикермәдем! Мин болай гына, мин образованный гына булдым дип белдем!.. Мин тәрәккый пәрвәр генә булдым!.. Тәүбә иттем, әти, тәүбә иттем!

Миңлебай. Йә, әйт иманыңны!

Карчык. Йә, йөдәтмә кешеләр алдында!

Шакирҗан. Әйтәм, әйтәм! Ля иләһә илля аллаһе, ля иләһә илля аллаһе.

Ишектән бер околоточный, ике городовой килеп керәләр. Яһүд акрын гына чыгып кача.

Околоточный. Монда нинди җыелыш? Полициядән рөхсәтегез бармы?

Пристав. Монда мин Хаим Соломоновичның алачагы өчен әйберләрне яздым.

Околоточный *(каранып)*. Болар кемнәр?

Итче. Без — бурыч иясләре, господин околоточный. Менә өч айлык ит бәһасен бирмәделәр.

Тегүче кыз. Господин околоточный! Мин — тегүче кыз, хуҗа хатыным куып чыгара... Минем акчамны гына алып бирсәнә! *(Еглый.)*

Околоточный. Молчать! *(Шул арада марҗа чыгарга маташа. Бер полиция барып ишекне тота. Околоточный Шакирҗанга карап.)* Бу фатирның хуҗасы сезме?

Шакирҗан *(кыйналган көенчә)*. Элек мин идем!.. Мин! *(Калтырана.)*

Околоточный. Монда сездә Казан уезды Каравай авылының крестьянкасы Федосия Ивановна торамы?

Шакирҗан. Юк, монда, бездә андый кеше юк.

Околоточный *(марҗага күрсәтеп)*. Бу кем соң?

Шакирҗан. Бумы? Бу... бу... элек графиня иде!

Марҗа. Мин — графиня!

Бер полис. Син күптән графиня булдыңмы? Болак буендагы пивнойда торганда, әле крестьянка идең түгелме?

М а р җ а. Бу мине мыскыл итү!.. Мин — графиня!

О к о л о т о ч н ы й. Паспортыгызны рәхим итегез!

М а р җ а. Сез нинди графларда, князьләрдә паспорт йөрткәнне күргәнегез бар? Безнең исем алтын берлә казенный китапка басылган. Минем паспорт юк. *(Шакирҗанга.)* Минем паспорт кайда икән, синдә түгелме?

Ш а к и р җ а н. Мин белмим, минем күргәнем юк.

П о л и с. Шул, бу шул! Мин аны таныйм!

О к о л о т о ч н ы й. Син Болак буенда пивнойда хезмәт итеп торган идеңме?

М а р җ а. Минме? Мин!.. Юк! Кайда графларның, князьләрнең пивнойда хезмәт иткәннәрен күргәнегез бар?

О к о л о т о ч н ы й. Тугрысын әйт, югыйсә эш начар!

М а р җ а *(еглаган тавыш берлә).* Торган идем. Бер фәкыйрьлеккә калып торган идем... Мин — графиня! *(Үзе еглый. Шакирҗанга килеп.)* Князь, мине сакла, мине сакла! Болар миңа бәла якмакчы булалар! *(Миңлебай марҗаны бәреп җибәрә.)*

О к о л о т о ч н ы й. Син пивной хуҗасының бер беләзеген урлап качкан икәнсең. Рәхим итегез, сез кулга алындыңыз!

Ш а к и р җ а н *(марҗага килеп).* Син графиня түгелмени? Син графиня түгелмени?.. Тфү, ялганчы! Ни дип син мине, господин Җан Баевичны... *(Миңлебайга карап.)* Юк, юк!.. Шакирҗан Миңлебай угылын алдадың?

М и ң л е б а й *(марҗа янына килеп).* Син Каравай авылының көтүче Иван кызымыни?

М а р җ а *(еглаган тавыш берлә).* Әйе!..

Х а л ы к *(кычкырып көлә).* Менә сиңа графиня!

Ш а к и р җ а н. Соң, син ни дип графиня булган булып йөрисең?

М а р җ а. Соң, син ни дип князь булган булып йөрисең? Син дә бит авыл мужигы! *(Халык тагы кычкырып көлә.)*

О к о л о т о ч н ы й *(марҗага).* Киен киемнәреңне, әйдә полициягә, анда карарлар!

Марҗа киенә башлый. Шул арада ишектән С ә х и п җ а м а л ике кулына ике баласын тотып килеп керә. Ул халыкны күреп аптырабрак китә.

Б а л а л а р *(Шакирҗанга барып).* Әти! Әти! *(дип әтиләренә асылыналар.)*

Ә н в ә р. Әти, без сине алырга килдек, бездә күңелле, әти! Әни пәрәмәч пешерер!..

Шакирҗан *(аптырап кала).* Сәхипҗамал, синме? Сәхипҗамал, синме? Коткар мине бу бәладән, коткар!..

Сәхипҗамал *(кулыннан букчасын биреп).* Менә киемсалымыңны алып килдем... Бик күп саташтың, җитәр инде! Әйдә, киен дә өйгә кайтамыз!

Балалар. Әйдә, әти, өйгә кайтамыз!.. Әйдәңез! Әйдәңез!.. Тизрәк әйдәңез!

Шакирҗан *(бик тиз итеп, кама тиреле тунны, тәвәккәл бүрекне кия дә).* Әйдәңез!.. Әйдәңез, тизрәк киттек моннан, киттек!

Ике полис, маржаны ике ягыннан тотып алып, өйдән чыга башлыйлар.

Миңлебай *(маржа янына барып).* Мәлгунь, бәдбәхет! *(дип җирне тибеп кала. Бөтен халык акрын гына күтәргән әйберләрен алып чыгалар.)*

Шакирҗан. Шул шайтанга алданып никадәр дәүләт бетердем, никадәр дәүләт!.. Мин бит тәрәккый пәрвәр булдым дип белдем!.. Мин бит тарихка керәм дип белдем!

Сәхипҗамал. Ярар инде! Баш сау булса, мал табылыр. Әйдә тизрәк, әйдә!..

Шакирҗан. Тагы толчокта иске кибетемне алырмын. Тагы иске-москы берлә сату итә башлармын. Бик яхшы торырмыз әле!

Миңлебай. Киртә сикермәгән булсаң, берни түгел...

Шакирҗан. Валлаһи, юк!.. Валлаһи, юк, әти!

Шул арада, бик кызуланып, гармунчы килеп керә, кулында бер зур путаллы тышлы китап.

Гармунчы. Господин Жан Баевич, керттердем сезне!.. Падишаһлар берлә бер рәттән китапка керттердем! *(Шакирҗанга китапны төртә.)*

Шакирҗан *(аптырап китеп, тора да, үз-үзен туплап).* Мин — Шакирҗан Миңлебай угылы, беләмсең? Мин — Шакирҗан Миңлебай угылы, мин синең Жан Баевичыңны күргәнем, ишеткәнем юк. Бу — минем мулла кушкан исемем. Мине ничек урыс исеме берлә атыйсың? Ничек син мине мыскыл итәсең? *(Өстәлгә сугып.)* Как ты смеешь?! Безнең динне мыскыл итәргә?! *(Китапны күтәреп җиргә бәрә дә йодрыгыны күтәреп гармунчыга килә башлый. Миңлебай да таягын күтәрә. Сәхипҗамал — Шакирҗанны, карчык картны тоталар. Балалар арага керә.)*

Пәрдә төшә.

бәддога — каргыш
мәсхәрә итү — оятка калдыру
мордар — *монда:* юньсез, динсез
кама тиреле — кыйммәтле мехлы су җәнлеге тиресеннән
тәвәккәл бүрек — эче мехтан тегелгән, гөмбәз сыман, колакчынсыз бүрек
путаллы — ялган алтын белән капланган

Сораулар һәм биремнәр

1. Әсәрдә сурәтләнгән Миңлебай карт образы турында сөйләгез.
2. Шакирҗанның ялгышы нәрсәдә? Аның үз ялгышын аңлавына нәрсә этәргеч була?
3. Гаяз Исхакыйның шушы әсәр аркылы әйтергә теләгән төп фикере нинди?
4. Хәзерге көндә дә мәдәнилекне Шакирҗан кебек аңлаучы кешеләр бар микән? *Мәдәнилек* төшенчәсен сез ничек аңлыйсыз? Шул турыда фикер алышыгыз.
5. Әсәрне тулысынча укыгыз һәм авторның драматург буларак осталыгы турында фикерегезне әйтегез.

Һади Такташ
(1901—1931)

Татар шигъриятенең классикгы Һади Такташ (Мөхәммәтһади Хәйрулла улы Такташев) 1901 елның 1 гыйнварында хәзерге Мордва Республикасының Торбеево районы Сыркыды авылында крестьян гаиләсендә туа. Әнисе шигъри күңелле, нечкә хисле кеше була. Бик күп җырлар, әкиятләр белә, үзе дә җырлар чыгара. «Әни хәзер дә әле миңа хатларын җырлар белән яза. Ләкин ул үзенең җырчы икәнен белми»,— ди шагыйрь әнисе турында.

Һади укырга-язарга башта әти-әнисеннән өйрәнә. Аннан соң авыл мәдрәсәсендә укый. Үсә төшкәч, аны Пешлә мәдрәсәсенә бирәләр. Сыркыдыдан утыз чакрымдагы бу мәдрәсәдә малай бик тырышып укый. Шул вакытта чыккан газета-журналлар белән танышып барырга тырыша. Габдулла Тукай һәм Сәгыйт Рәмиев шигырьләрен яратып укый. Кызганычка каршы, тормышлары авырлашып китү сәбәпле, Һади бу мәдрәсәне ташларга, Бохарага барып, эшкә урнашырга мәҗбүр була. Бохарада Һади, авыр шартларда яшәвенә карамастан, белемен күтәрергә омтыла, җәмәгать эшләрендә кайный, спектакльләрдә катнаша. Гомумән, яшьләр арасында мәдәни-агарту эшләре алып бару һәм үзенең мондый омтылышларына теләктәшлек иткән кешеләр белән аралашу Һадиның әдәби иҗатка булган дәртен тагын да арттыра. 1916 елда язылган «Газраилләр» һәм «Караңгы төннәрдә» кебек әсәрләрен Такташ иҗатының әнә шул чордагы беренче иҗат җимешләре дип карарга кирәк.

1918 елның җәендә ул, туган якларына кайтып, педагогия курсларында укый һәм Сыркыдыда укытучы булып эшли.

Кече яшьтән үк әдәбият белән кызыксыну, белемгә омтылу Һади Такташны Оренбург шәһәренә алып килә. Ул «Юксыллар сүзе» газетасында җаваплы секретарь булып эшли, бу аңа әдәбият белән тирәнрәк танышырга мөмкинлек бирә.

1921 елгы ачлык вакытында Һади Ташкентка китәргә мәҗбүр була. Ул анда әдәбият укыта, «Белем йорты» журналында җаваплы секретарь булып эшли. Шул ук вакытта әдәби иҗат эше белән дә шөгыльләнә.

Шулай да аның күңеле татар әдәбияты һәм сәнгатенең үзәге булган Казанга тартыла. 1922 елның көзендә ул Казанга килеп урнаша. Татар театрында, «Чаян», «Авыл яшьләре», «Азат хатын», «Яңалиф» журналларында эшли.

Һади Такташ, барыннан да элек, шагыйрь буларак танылa. Әмма ул башка жанрларда да иҗат итә. Мәсәлән, «Күмелгән кораллар» (1927), «Югалган матурлык» (1928), «Камил» (1930) исемле драма әсәрләре һәм хикәяләр дә яза.

Һади Такташ иҗатында һәм язу стилендә чынбарлыктагыча сурәтләү көчәйгәннән-көчәя бара, бу — шагыйрьне яңа иҗади ачышларга китерә. «Сагыну җырлары», «Такташ шигырьләре» исемле җыентыкларында урнаштырылган лирик-публицистик шигырьләр һәм яшьлеккә, мәхәббәткә, тормыш матурлыгына дан булып яңгыраган «Мәхәббәт тәүбәсе», «Алсу», «Мокамай» кебек лирик поэмалар Такташны егерменче еллар татар шигъриятенең алдынгы сафына чыгара. Ул халыкның уй-хисләрен, хыял-омтылышларын илһамланып җырлаучы трибун-шагыйрь булып таныла.

Һади Такташ 1931 елның 8 декабрендә вакытсыз вафат була. Иҗаты ярты юлда өзелеп кала. Аның гәүдәсе Казан шәһәрендәге туганнар каберлегендә җирләнгән.

МОКАМАЙ [1]

Белмим,
Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге оныта алмамын
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын...
Алар мәңге минем хыялымда
Шаулый-шаулый яфрак ярырлар.
Карт имәннәр, калмый минем арттан,
Кая барсам, озатып барырлар...
Бер җирдә юк андый ак каеннар,
Бер җирдә юк андый урманнар,
Бер җирдә юк камыш сабаклары —
Андагыдай шаулый торганнар...

Әкияттәге ике бала кебек,
Каен башларына үрмәләп,
Ике штансыз малай дөнья белән
Танышып йөргән идек бергәләп...
Беребез сары чәчле, беребез кара,
Сары чәчлесе ул — мин идем,
Кара чәчле, коңгырт кара күзле,
Кәкре аяклы дустым, җан кисәгем,
Ул, Мокамай бәгърем, син идең...
Ак каенга асылып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым.
Менгән саен, җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күралдым...
Ә син меналмадың,
Калдың,
Югалдың...

[1] Мокамай — кушамат (дөресе — Мөхәммәтҗан). Ул — Сыркыды авылының Бәкер исемле иң ярлы бер кешенең баласы. Соңгы елларда авылда арба тәгәрмәче урлауда гаепләнеп, җыенда кыйналган һәм идән астына ябылып, шунда үзен үзе суеп үтергән. *(Һ. Такташ искәрмәсе.)*

И. Л. Язынин рәсеме

Әкияттәге ике бала кебек,
Икебез дә кара борынлы.
Зурлар кебек, кулны артка куеп,
Йөри идек таптап болынны...
Һәрбер нәрсә безгә яңа иде,
Һәрнәрсәгә исебез китә иде,
Бернәрсә дә бездән качмый иде,
Бар нәрсәгә кулыбыз җитә иде...

Күпме кыен күрдек шуның өчен,
Күпме тал чыбыгы ашадык,
Әкияттәге ике бала кебек,
Күпме «җәфа чигеп» яшәдек...
Кем уйлаган шушы шаярулар
Синдә кәсеп булып калыр дип,
Уйнап башланган эш тормышыңны
Һәлакәткә алып барыр дип...
Хат язсам да, хәзер соңга калдым,
Укымассың минем хатымны,
Ләкин минем бурычым, Мөхәммәтҗан,
Йолу синең яманатыңны!
Син гомереңне усал исем белән,
Канлы пычак белән чикләдең...
Әллә ничек булды синең гомер,
Син, Мокамай, әллә нишләдең!..

Әкияттәге ике бала кебек,
Каен башларына үрмәләп,
Ике штансыз малай дөнья белән
Танышып йөргән идек бергәләп...
Ак каенга асылып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга таба юл алдым.
Менгән саен, җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күралдым.
Ә син меналмадың...
Калдың, югалдың...

Үткәннәрем — авыр әкият минем.
Ул әкиятне әгәр сөйләгәндә,
Чагылып китсә синең күләгәң,
Юк, юк,
Мин ант итәм: һичбер вакытта да
Сине карак итеп сөйләмәм...
Син яшәргә хаклы кеше идең,
Син яшәргә җирдә теләдең.
Тик син ачлык тырнагыннан,
Түбәнлектән
Чыгу юлын гына белмәдең...
Ә бит

Бергә чабаталар үреп йөргән чакта,
Син остарак миннән үрәйдең,
Минем матур итеп үрәлмауны
Булдыксызлыгымнан күрәйдең...
Ник соң бу болай булды әле,
Ничек һәлакәтең күрмәдең,
Ник, Мокамай, соң син тормышыңны
Чабатаңдай матур үрмәдең?

Син гомереңне усал исем белән,
Канлы пычак белән чикләдең,
Әллә ничек булды синең гомер,
Син, Мокамай, әллә нишләдең!..
Ә бит безнең гомер матур урманнарда
Май аедай матур башланды.
Әкияттәге ике бала кебек,
Икебез ике якка ташланды...
Синең тормыш авыр әкият булды,
Ул әкиятнең соңгы битләрен
Син зур исем, мәңге онытылмаслык
Эшләр белән бизәп китмәдең...
Син адаштың,
Ләкин син яхшы идең,
Синең яхшы иде күңелең,
Тик белмәдең тормыш баткагыннан
Ялгыз чыгу мөмкин түгелен...
Син белмәдең,
Кешеләр җирдә тормыш баткагыннан
Чыгу юлын бергә эзлиләр,
Ялгыз калып ачтан үлмәс өчен,
Күмәк тормыш җирдә төзиләр...

Үткәнемне әкият итеп сөйләгәндә,
Чагылып китсә синең күләгәң,
Юк, Мокамай, һичбер вакытта да
Сине усал итеп сөйләмәм...
Син ярлы идең, ләкин эш сөя идең,
Синең яхшы иде күңелең.
Син белмәдең сыйнфый бөлгенлектән
Алай чыгу мөмкин түгелен...

җан кисәгем — якын итеп, кадерләп эндәшү
кәсеп — шөгыль, һөнәр
йолу — бетерү, юкка чыгару

Сораулар һәм биремнәр

1. Шагыйрьнең туган ягы ни өчен исендә калган?
2. Туган як табигатен сурәтләгәндә, ул нинди сынландырулар һәм чагыштырулар кулланган?
3. Дусты Мокамай белән икесенә дә уртак сыйфатлар кайсы юлларда чагыла?
4. «Күпме тал чыбыгын ашадык» дигән юлларның мәгънәсен ничек аңлыйсыз?
5. Мокамайның аяныч язмышы мисалында шагыйрь нинди фикер әйтергә тели?
6. Мокамай турында шагыйрь ни өчен начар фикер әйтмәс дип уйлыйсыз?
7. Соңгы 2 строфаның эчтәлеген үз сүзләрегез белән сөйләгез.
8. Шигырьнең укытучы күрсәткән өлешен ятлагыз.



Хәсән Туфан
(1900—1981)

Татар халкының классик шагыйре, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хәсән Туфан (Хәсән Фәхретдин улы Туфан) 1900 елның 27 ноябрендә (яңа стиль белән 9 декабрьдә) Татарстанның Аксубай районы Иске Кармәт авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә сигезенче бала булып дөньяга килә. Булачак шагыйрьнең әтисе Фәхретдин абзый, иген игүдән тыш, сәгать төзәтү, пыяла кую, тимерчелек кебек эшләр белән дә шөгыльләнә һәм бу һөнәрләргә балаларын да өйрәтә.

Әнисе турында болай дип искә ала шагыйрь: «Дөньяның, табигатьнең матурлыкларын күрергә әни өйрәтте мине. Белеп, максат итеп түгелдер, әлбәттә, ә үзе шундый үтә нечкә күңелле, үтә шигъри җанлы булгангадыр, тормышның безне чолгап алган ямьсез якларын минем күздән яшерергә, күңел күземне табигатьтәге ямьлелекләргә юнәлтергә тырышкан булган күрәсең ул. Мине йортка яки бәрәңге бакчасына алып чыга да дөнья күрсәтеп йөри, кайткан яки киткән кыр казлары, торналар белән генә түгел, куаклар, үсемлекләр, җилләр, йолдызлар белән дә сөйләшә башлый иде.

Йолдызларны танырга, аларны табарга өйрәтә, аларның исемнәрен әкиятләр белән бәйли иде. Әни миндә табигатьтәге бар нәрсәнең җаны бар икән, чишмәләр генә түгел, йолдызлар да, җилләр дә сөйләшә икән дигән «иман» тудырды».

Хәсән Туфан, Кармәттә мәктәп ачылгач, шунда йөреп укый башлый. 1914 елның көзендә аны Уфага «Галия» мәдрәсәсенә укырга җибәрәләр. Үз чорының алдынгы уку йорт-

ларыннан саналган бу мәдрәсә Х. Туфанның әдәби иҗат эшенә тартылуына уңай йогынты ясый. Анда ул Галимҗан Ибраһимовтан әдәбият дәресләрен тыңлый, шул ук мәдрәсәнең шәкерте Шәехзадә Бабич оештырган түгәрәккә йөреп, шигырь серләренә өйрәнә, әдәби кичәләрдә Сәгыйт Рәмиев, Мәҗит Гафури, Сәгыйт Сүнчәләй кебек шагыйрьләрнең чыгышларын ишетә.

1918—1924 елларда Хәсән Туфан Урал һәм Себер мәктәпләрендә балалар укыта. 1924 елның җәендә Казанга килә һәм 1928 елга кадәр Н. Нариманов исемендәге 17 номерлы Бишбалта мәктәбендә укытучылык хезмәтен дәвам иттерә.

Х. Туфанның исеме матбугатта беренче тапкыр 1924 елда күренә: «Октябрь баласы» журналы һәм «Кызыл Татарстан» газетасы битләрендә шигырьләре басылып чыга. Берничә ел эчендә Хәсән үзенчәлекле шагыйрь булып танылa. Бу елларда ул поэма жанрында аеруча зур иҗади уңышларга ирешә. Аның «Урал эскизлары» (1926), «Ике чор арасында» (1927), «Башлана башлады» (1927), «Бибиевләр» (1927) кебек поэмалары шушы елларда языла.

1928 елның язында Х. Туфан Кавказ һәм Урта Азия якларына җәяүле сәяхәткә китә. Аның бу сәяхәте ике елга сузыла. Сәяхәттә йөргәндә, ул төрле халыкларның тормышлары белән якыннан таныша, халык иҗаты әсәрләрен өйрәнә. Болар һәммәсе шагыйрь иҗатын яңа темалар, яңа хисләр белән баета.

Сәяхәттән кайткач, Хәсән Туфан 1930—1934 елларда Татарстан радиокомитетында әдәби һәм музыкаль тапшырулар редакторы, аннары 1937 елга кадәр «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының җаваплы секретаре булып эшли.

Сталин шәхес культының котырган елларында шагыйрьнең төрмәләрдә газаплануы, Себергә сөрелүе, табигый, аның хисләренә тәэсирсез калмый. Ачу, әрнү тойгысы йөрәктән шигырьләргә күчә. Бу авыр чорда Хәсән Туфанга тормыш иптәше Луиза Салиаскарова олы таяныч була, яшәүгә көч бирә. Аны үлемнән алып калу өчен төрле юллар эзли, соңыннан шагыйрь, олы хөрмәтен белдереп, аңа күп кенә шигырьләрен багышлый.

Гомумән, Х. Туфан, тормыш һәм иҗат юлында нинди генә хәлләргә очрамасын, бервакытта да туган ягына, халкына һәм шигъриятькә булган тирән ышанычын югалтмады. Аның

халык әдәбиятына нигезләнгән иҗаты, татар классик поэзиясенең традицияләрен алга таба үстереп һәм киңәйтеп, үзенә бер шигъри дөнья булып формалаша.

Ул татар шигырен яңа эчтәлек, яңа ритмик ачышлар, лирик композициянең, строфа төзүнең классикага әверелердәй яңа үрнәкләре белән баета («Иртәләр җитте исә», «Агыла да болыт агыла», «Сиңа», «Ромашкалар», «Әйткән идең» һ. б. шигырьләре).

Татар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен Хәсән Туфан ике тапкыр (1970, 1980) Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә, «Сайланма әсәрләр» (Казан, 1964) китабы өчен аңа 1966 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

Хәсән Туфан 1981 елның 10 июнендә Казан шәһәрендә вафат була.

ТУГАН ТЕЛ ТУРЫНДА ҖЫРЛАР

1

И телем, сансыз гасырны
Исән-сау кичкән телем!
Сыкраулар теле түгел син,
Күкрәүләр теле бүген.

И безнең батыр телебез,
И безнең гәүһәр мирас!
Күпләрне күргән башыңны
Инде син күтәр бераз.

2

Тарихым истәлеге син,
Болгарым истәлеге,
Гасырлар аша үтелгән
Юлларым истәлеге.

Чишмәләр исән чагында,
Иделләр кибәмени?
Гасырлар күммәде сине,
Дәверләр күмәмени?

Иңгә-иң безнең теләкләр,
Кулга-кул уйларыбыз,
Якты язмышларга таба
Барасы юлларыбыз.

Син — минем тере тарихым,
Син — минем киләчәгем,
Тик синдә, газиз туган тел,
Бәхеткә җитәчәгем.

И телем, синдә нәфислек
Чишмәсе кибәрмени?
Гасырлар сиңа тимәде,
Дәверләр тиярмени?

сыкрау — ыңгырашу, зарлану
гәүһәр — асылташ; *монда:* кадерле (мирас)
нәфислек — гүзәллек, матурлык
сансыз — исәпсез-хисапсыз, чиксез күп, бик күп
кичкән — үткән, узган

Сораулар һәм биремнәр

1. Хәсән Туфанның тормыш юлы турында сөйләгез.
2. Сез шагыйрьнең иҗаты белән моңа кадәр таныш идегезме?
3. Х. Туфан шигырен ни өчен «Туган тел турында җырлар» дип атаган?
4. «Күкрәүләр теле бүген» сүзләре белән шагыйрь ни әйтергә теләгән?
5. Татар теленең үткәненә багышланган юлларны табып укыгыз, ул сүзләрдән сез нәрсә аңлыйсыз?
6. Тел турында нинди мәкаль һәм әйтемнәр беләсез? Һәр мәкаль һәм әйтемнең мәгънәсен аңлатыгыз.
7. Шигырьне ятлагыз.

КАЙСЫГЫЗНЫҢ КУЛЫ ҖЫЛЫ?

Дөнья мине
Үзгәртте:
Еламаска өйрәтте.
Күлмәк җиңен ертасымы? —
Бәйлисе бар
Йөрәкне.

Сугышлардан замана
Туктап торган арада,
Яраларны ямаштырып
Ята идем
Далада:

— Кайт!..— дип, хатлар килделәр.
Юллар... озын иделәр...
Кайттым.
— Бусы — алкалары,
Бусы — кабере...— диделәр.

Әгәр тагын килсәләр:
— Сау! — дип хәбәр бирсәләр,
Вулканнарга керер идем,
Шундадыр ул... дисәләр.

Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...
Кайсыгызның кулы җылы? —
Бәйлисе бар йөрәкне...

дала — степь
ямаштыру — *монда:* савыктыру

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырь кемгә багышлап язылган? Аны авторның үз тормышы белән бәйләп аңлатып буламы? Ни өчен?
2. Шигырьнең төзелеше, теле турында фикерләрегезне әйтегез.
3. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз.

КЕМНӘР СЕЗ?

Һәр елда
Бөек Тукайның
Бәйрәме таңы туса,
Эндәшә сезгә — яшьләргә
Һәйкәлдән Җәлил Муса:

«Кемнәр сез?
Безнең дәвамны?
Һәм безнең нәселме сез?
Тукайлар изге йоласын
Үтәргә әзерме сез?!

Якладым соңга кадәр мин
Туган ил гадәтләрен,
Кулымны бәйләсәләр дә,
Телемне бәйләтмәдем!

Сез балык баласы түгел,
Сез халык баласы бит.
Киләчәк көнгә Тукайны
Сез алып барасы бит!

Киселде башлар... тиделәр...
Тик телгә тидертмәдек;
Агабыз Тукай йөзенә
Каралык китертмәдек!» —

Һәр елда бөек Тукайның
Бәйрәме таңы туса,
Эндәшә сезгә һәйкәлдән —
Эндәшә шулай Муса.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьнең беренче юлларында нинди бәйрәм турында сүз бара?
2. «Сез балык баласы түгел,
   Сез халык баласы бит.
   Киләчәк көнгә Тукайны
   Сез алып барасы бит!» —
   дигән юлларны ничек аңлыйсыз?
3. Шагыйрь куйган сорауга җавап бирегез.
4. Шигырьдән үзегезгә аңлашылмаган сүзләрне табыгыз, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» ярдәмендә ул сүзләрнең мәгънәләрен ачыклагыз.

Мирсәй Әмир
(1907—1980)

Күренекле прозаик, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мирсәй Әмир (Мирсаяф Мәсалим улы Әмиров) 1907 елның 6 гыйнварында Башкортстанның Мәләүез районы Җиргән авылында крестьян гаиләсендә туа. 1919 елда әтисе, 1921 елгы ачлык вакытында әнисе дә үлеп китә. Ятим малай башта туганнары гаиләсендә, аннары Эстәрлетамак шәһәрендәге җидееллык үрнәк-тәҗрибә мәктәбе интернатында тәрбияләнә. Хезмәт юлын Миркитле волосте башкарма комитетында башлап җибәрә. Шушы елларда Башкортстан өлкә яшьләре газеталарында беренче мәкалә һәм очеркларын бастыра башлый.

1926 елда Казанга килә һәм сәнгать техникумына укырга керә. Техникумда укыган елларында ук ул «Кызыл яшьләр» газетасы һәм «Авыл яшьләре» журналы редакцияләрендә җаваплы секретарь булып эшли. 1926 елда «Авыл яшьләре» журналында Мирсәй Әмирнең «Дуслар һәм дошманнар» исемле беренче хикәясе басылып чыга. Бу аның иҗатының башлангычы була.

1931 елда берникадәр вакыт «Чаян» журналында әдәби хезмәткәр, аннан соң 1934 елга кадәр Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли.

Бу чорда Мирсәй Әмир иҗатын авылдагы үзгәрешләрне яктыртуга юнәлтә. 1935 елда шул темага «Агыйдел» дигән атаклы әсәрен яза. Күп планлы һәм драматик вакыйгаларга бай, шул ук вакытта яшьлеккә хас якты һәм лирик җылылык белән сугарылган бу повесть тиз арада үз укучыларын таба.

Сугыш чорында әдип Татарстан радиосында эшли. Аннан соң, фронтка китеп, «Ватан өчен» исемендә чыга торган газета редакциясендә дә эшләргә туры килә аңа. Шул газета битләрендә һәм соңыннан республикабыз матбугатында туган ягыбыз халкының сугыш кырында һәм тылдагы батырлыкларын лирик планда тасвирлаган күп кенә очерк һәм хикәяләрен бастыра («Курай», «Үз өемдә», «Бабайлар», «Дошман көтмәгәндә» һ. б.).

Мирсәй Әмир,— проза әсәрләре язу белән беррәттән, драматургия өлкәсендә дә уңыш казанган әдип. Аның «Тормыш җыры», «Җыр дәвам итә», «Миңлекамал» әсәрләре татар театр сәхнәләрендә зур уңыш белән барды.

Гәрчә драматургия М. Әмир иҗатында мөһим урын алып торса да, әдипнең илленче-җитмешенче еллар арасындагы иҗади уңышлары күбрәк проза жанры белән бәйле. 1953 елда ул «Ялантау кешеләре», 1959 елда аның дәвамы булган «Саф күңел» романнарын тәмамлый. Бу дилогиядә халкыбызның 1941—1945 елларда сугышта һәм тылда күрсәткән каһарманлыгы гәүдәләндерелә.

1971 елда иҗат ителгән «Балыкчы ялганнары» повесте, маҗаралы, юмористик стильдә язылуыннан тыш, табигатькә мөнәсәбәттә кешенең рухи дөньясы һәм әхлакый йөзе кебек мөһим мәсьәләләрне күтәрүе белән әһәмиятле.

М. Әмир гомеренең соңгы елларында үзәктә шәхси тормышы торган документаль повесть яза. Ул «Без бәләкәй чакларда», «Үсә төшкәч», «Казан» дигән кисәкләрдән тора.

М. Әмир 1937, 1961—1962 елларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе вазифасын башкара.

Татар язучыларының олы буын вәкиле — күренекле прозаик, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе Мирсәй Әмир Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемгә һәм Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Әдип 1980 елның 1 июнендә Казан шәһәрендә вафат була.

4 К 5/146

АГЫЙДЕЛ

(повестьтан өзекләр)

1

Иртәнге кояшның йомшак нурларына иркәләнеп, көлеп уяндым. Торакта чакта, сигнал булгач та, бер-ике генә минут булса да изрәп яту өчен тартышырга, дежурныйның кәефен бозарга туры килгән көннәр күп була иде. Торганның соңында да әле, спорт залына кереп бераз сикергәләмичә, күп кранлы умывальник янында ялангач иптәшләр белән салкын су сибешә-сибешә юынмыйча, йокы ачылып җитми торган иде. Ә бүген... һичкем кыңгырау шалтыратмады, өстемә ябынган чикмәнемне һичкем килеп тартмады, фәкать куксел урман белән капланган көчле таулар артыннан көлеп күтәрелгән иртәнге кояш нурларының йомшак кына итеп битемнән сыйпавы җитте — уяндым. Эчке тәртипне бозу куркынычы да, иртәнге ашка кичегү, беренче дәрескә барып өлгерә алмау хәвефе дә юк иде — сикереп тордым.

Юк, бу йокыдан уяну гына түгел, бу — яңадан туу, барлык кайгы-хәсрәтләрне, кыш буенча үтелгән дәресләрдән имтихан бирү авырлыкларын онытып, мәктәп стенасында үпкәләргә кунган тузаннарны юып, белем белән бергә мигә оялаган талчыгу «микробларын» куып чыгарып, сабый баладай җиңеләеп, яңадан туу!..

Шундый бәхетле, шатлыклы, җиңел уяну иде бу!

Агыйдел буе табигатенең никадәр матурлыгын, никадәр көчлелеген: аның төшенке күңелләрне күтәрү, сәламәтлекне ныгыту өчен кирәк булган барлык даруларга иксез-чиксез дәрәҗәдә бай табигать икәнлеген фәкать шул иртәдә генә сиздем булса кирәк. Югыйсә сабый чагым да шул ук Агыйдел буеның ямьле сахраларында йөгереп, эшкә ярый башлагач та шул ук җирнең печәннәре, саламнары арасында аунап узды инде. Ләкин бәләкәйдән үк авыр эшкә җигелү, һәрнәрсәнең кыен ягын, авыр ягын гына күреп үсү тойгыларымны тупасландырган булган күрәсең, берсенә дә әһәмият бирмәгәнмен.

Ә бүген!..

Без йоклаган арба төбендәге кичә генә чабып кайтарылган печән исе дә мине исертә. Хәтта хуш исле чәчәкләр арасына кысылган әрем исе дә кыйммәтле хушбуйлар исеннән тәмлерәк булып тоела. Әллә ничә төрле яшел белән бизәлеп,

иртәнге кояш яктысында күзләрне иркәләрлек булып күренгән урманлы таулар гына түгел, хәтта читән буйларына сырышып үскән алабуталар да, кычытканнар да Шишкин пейзажларыннан матуррак булып күренәләр.

«Әйе, дөнья матур, чиксез матур!..» — шулай дип, үзалдыма кычкырып җибәрә яздым. Күңелле минутны якын иптәшем белән уртаклашасым килде. Ә иптәшем уянмаган әле.

Аның өстендә дә, минеке кебек үк, җиңсез челтәр күлмәк, арзанлы материядән тегелгән кара чалбар. Таза мускуллы ялангач беләкләре ике якка ташланган, тыгыз күкрәк итләре белән нығытылган авыр гәүдәсе чи печәнгә чумган. Куе яшел печән белән кушылып киткән кара бөдрәләре астыннан ап-ак, шома булып күренгән киң маңгае аны әкиятләрдә сөйләнә торган гүзәлләргә охшата. Тырышып төзәтелгән төсле тигез булып сызылган коңгырт кара кашлар, көлеп чыккан кояш нурлары кебек, түбәнгә табан атылган озын керфекләр, «кашкүз, маңгай тирәсендәге бөтенлеккә зыян китерә күрмәсен» дип, саклык белән генә эшләнгән төсле кечкенәрәк авыз-борын аны тагын да матуррак итеп күрсәтәләр. Чынлап та, аның йөзендә ниндидер нур балкый төсле күренә иде ул минутта. Мин, аның матурлыгына, җанлылыгына, ягымлылыгына сокланып, шактый вакыт сүзсез генә карап тордым. Мин аны яратам. Техникумда укый башлаганыма менә быел — 1927 елның көзендә — ике ел тула. Шул ике ел эчендә без, аның белән икебез, бер кеше төсле яшәдек. «Ишәй белән Кушай» дип бездән көләләр, берәр җирдә ялгызыбызны гына очратсалар: «Кушаең кайда?» — дип сорамыйча булдыра алмыйлар иде. Чыннан да, безне ялгыз очрату кыен булгандыр. Бер-беребездән аерылып, бер генә сәгать тору да безнең өчен ямансу-күңелсез иде шул. Шуңа күрә дә җәйге ял чорында өч ай буена аерылышып тору беребезнең дә башына сыя алмады. Бергәләшеп, Агыйдел буена — минем туган авылыма кайттык.

Кайткан вакытта, олаучыбызның бездән башка да егерме биш потлап йөге булганга күрә, чемоданнарыбыз гына утырып кайттылар. Үзебезгә йөз километрдан артыкка сузылган юлның күбрәк өлешен җәяүләп үтәргә туры килде. Ямьле җәйге юл буенча җәяүләү җиңелчә киенгән яшьләр өчен авыр булмаса да, авылга кайтып җитү белән, буыннарыбызда арыганлык сизелде. Агыйдел буенда утырган авылның матурлыгы, авыл өстенә ишелә язып күтәрелгән күксел түбәле тауларның

мәһабәтлеге белән дә кызыксынмадык, фәкать каймаклы чәй эчү белән генә канәгатьләнеп, кояш батар-батмастан йокларга яттык.

Әнә шул йокыдан мин яңадан туган төсле булып уяндым. Иптәшемнең дә, һичбер ирексезләүсез, шундый бәхетле уяну белән уянуын теләп, кояш чыкканны көткән төсле, аның күзләре ачылганны көтә башладым. Ләкин аның күзләре тиз генә ачылмады. Сабырлыгым җитмәде, шундый күңелле, матур минутларда аның йоклап ятуын әрәм санадым да уяттым:

— Гаяз!.. Гаяз!..

Ул күзен ачмыйча гына эндәште:

— Кем тия?

— Тор, күр тизрәк безнең авылның ямьлелеген. Мондый яхшы иртәдә йоклап яту җинаять, Гаяз, тор. Күзеңне генә ачып кара, уянырга кирәклекне үзең үк аңларсың.

Аның күзләре ачылды. Әйтерсең лә ул кара күзләр юри генә йомылып торганнар: шундый мәшәкатьсез, шундый чиста булып ачылдылар алар, минем өчен, чыннан да, икенче кояш чыккан кебек булды.

— Нигә бик иртә? Барасы җир юк бит,— диде ул.

— Бар, Гаяз, барасы җир бар. Әйдә, мин сине хәзер Агыйдел буена алып барам, су коенырга.

Ул, минем күзләремә туп-туры карап, бик аз гына вакыт хәрәкәтсез ятты да кинәт машина тизлеге белән сикереп торды. Шундый ук җитезлек белән җиргә сикерде:

— Әйдә, киттек.

2

Агыйдел!..

Рәсемдәге төсле матур, әкияттәге төсле серле, җырдагы төсле моңлы елга ул Агыйдел... Аның даны зурлыгы белән түгел, хозурлыгы белән таралган. Җырларда аны, күбесенчә, яшь гомергә охшаталар. Чынлап та, бик урынлы охшату. Бик кыска гына вакыт эчендә дә чиксез күп борылышлар ясый, агымын әледән-әле үзгәртеп тора: бер карыйсың — яшәү көче, тормыш дәрте белән ярсыган яшь йөрәкне хәтерләтә; үзеннән-үзе биеп торган аякларын кая басарга, ташып барган көчен кая куярга белми аптыраган егетләр шикелле, ташларны актарып, уң яклап күтәрелгән текә тауларның каты ярларын кисеп, баштүбән ага. Ул ара да булмый, көчле мәхәббәт кармагына эләгү нәтиҗәсендә төн йокысыннан мәхрүм калып,

ай яктысына чыгып утырган яшь кызлар төсле, уйга батып китә; ике як ярларында үскән куаклардан асылып төшкән күләгә эчендә бөтенләй агуын онытып тора. Хәтта чит-читләрендә тәнбоеклар үсүгә дә каршы килми. Аның мондый урыннарын үрдәк-каз кебек кошлар бик яраталар, ләкин тормышлары өчен куркыныч барлыгын белмиләр алар: күл кебек тыныч, тәнбоеклы суга булган мәхәббәтләренә каршы килә алмыйча, йөзеп китәләр дә, чоңгылда яткан усал җәен авызына барып кергәннәрен сизми дә калалар. Ә Агыйдел аларны күрмәмешкә салыша, бөтенләй дөньясын оныткан төсле тынып, тик тора... Күп тә үтми, тагын, бик кирәкле эшен исенә төшергән кеше сыман, яңа тауларга таба борылып ашыга башлый. Ташларга бәрелүдән туган кечкенә-кечкенә дулкыннар күп булып җыелышалар да, кызык күрергә ашыккан төркемдәй, берсен берсе төртешә-төртешә, үзара әрләшә-әрләшә алга йөгерәләр. Шулай бер котырып, бер басылып ага ул. Барган юлында очраган кечкенә-кечкенә елгаларны үзенә ияртеп, зурая бара, зурайган саен «акылга утыра». «Ай уймаккай кебек сызылып аккан Ашказар»ны, төбенә шом яшереп аккан тыныч Димне, «Нәзеккәй билле, ак тәнле кызлар» үстергән Уфа суларын ияртеп, ул шактый үсеп җитә, зур хезмәтләргә ярый башлый: пароходлар, баржалар йөртергә хәленнән килә. Шулар белән бергә Кама, Волга кебек абыйларына кушылып, Каспийга —диңгезгә чыга — киң тормыш эченә керә...

Без төшкән тәңгәлдә Агыйдел каты акмый: өзлексез акрын гына күчеп торган киң, шома көмешкә охшый аның ул җире. Аргы як ярында үскән бөдрә таллардан асылган күләгәләр аның иртәнге серен тагын да арттыралар. Без, уң яклап күтәрелгән биек, урманлы тау белән яр арасында булган шактый зур тугайлык буйлап, түбәнгерәк — чит-читләре чуерташлар белән тигезләнгән чистарак урыннан эзләп барабыз. Тугайлыкны каплаган куе яшеллек эчендә санап бетергесез төрдәге кошлар бергә кушылып сайрыйлар. Матур иртәгә көлеп ачылган гөлҗимеш, зелпе чәчәкләреннән чыккан хуш исләр, тын яткан Агыйдел өстеннән бөркелгән салкынча һава һәм яңа гына елмаеп күтәрелгән иртәнге кояштан сибелгән рәхәт җылылык белән бергә кушылып, барлык тойгыларны да иркәлиләр, сөяләр. Тойгылар үткенләнә, күңел үзеннән-үзе романтикага бирелә. Җитди әйберләр турында уйлыйсы да, сөйлисе дә килми. Уйныйсы, шаярасы, җырлыйсы килә; сөеләсе килә; күкрәкләрнең иркенлеге, тавышның

көр булып, яңгырап чыгуы, кәефнең әйбәт булуы белән масаясы килә, җырлап җибәргәнеңне сизми дә каласың.

Без дә, Гаяз белән сүз берләшкән кебек, бер үк җырны бер-авыздан сузып җибәрдек:

> Ямьле Агыйдел буйлары
> Бетерәдер хәсрәтле уйларны...

Кызыл яр астына җәелгән чиста чуерташлар өстенә йомшак сандалиларыбыз белән басып, иртәнге тынлыкны чатната-чатната су читенә якынлаштык. Төн уздырыр өчен чуртаннан куркып сайга чыккан ташбашлар төркеме, Идел читен вак кына дулкыннар белән бизәкләп, тирәнрәк китте. Без, кечкенә-кечкенә яссы ташлар белән «коймак» җибәреп, ялтырап яткан Агыйдел өстен бождралар белән чобарлый-чобарлый, чишенә башладык. Ялангач калгач, үз тәннәребезнең тазалыгына үзебез сокланышып, тән хәрәкәтләре ясадык.

Салкынча һавада пыяла төсле тигез булып яткан су башта безне бераз куркытты. Кинәт кенә кереп китәргә тәннәребез карыша, без, кулбашларыбызны җыерып, бер-беребезгә караша идек.

— Болай булмый, тәвәккәллек кирәк,— диде Гаяз.— Әйдә. Раз, два, три...

Агыйдел өстенең пыяла тигезлеге чәлпәрәмә килде. Һавага караганда җылырак булган суның чисталыгына, йомшаклыгына сокланып туя алмыйча, аргы як ярдагы бөдрә таллларга карап, колач сала башладык.

— Аркылы чыгабызмы?

— Чыгабыз.

Яр шактый ерак булып чыкты. Колач сала-сала беләкләр арыгач, сырт өстенә әйләндек. Аяк белән генә йөзеп, кулларны, кул белән генә йөзеп, аякларны ял иттерә идек. Шулай мәшәкатьсез генә йөзә-йөзә, икенче як ярга шактый якынлашкан идек инде.

— Әйдә, тагын колач салабыз,— диде Гаяз, кинәт кенә талларга күмелгән ярга таба йөзе белән әйләнде. Ләкин шундый ук тизлек белән йөзеп китә алмады, кинәт тукталып, бөтенләй хәрәкәтсез диярлек хәлдә калды:

— Тукта! — дип пышылдады ул миңа.— Кара, кем бу? Нинди сын бу?

Көтелмәгәндә күз алдына килеп баскан бу гаҗәп күренешкә мин дә телсез калдым.

Каршыбызда, акыл ирешә алмаслык сер булып, бөтенләй диярлек ялангач кыз басып тора иде. Ул гәүдәсенең бөтен авырлыгын сул аягына салган да, уң аягын аз гына алгарак басып, аны үз уңаена гына куйган, уң кулын артка каерыбрак бөеренә таянганлыктан, күкрәге текә булып алга омтылып тора — әйтерсең лә аның зифа буе үзеннән-үзе дулкынлана. Нечкә булып сузылып киткән кара кашлар астыннан тыныч, рәхәт итеп карый торган чем-кара күзләр күксел тауларга йотылганнар. Түгәрәк битнең бөтенлегенә аз гына да кимчелек китермәслек булып урнашкан кечкенәрәк борын, тамарга торган чия төсле иреннәр... Матурлык, чиксез матурлык. Барлык Венераларга алмаштырмаслык җанлы матурлык...

Бөтен җире тигез килгән алсу-көрән тәнле бу кызның, үз тәне төсле үк материядән тегелгән су киемнәреннән генә булуына карамастан, безгә шулкадәр якын җирдә шулкадәр тирән тынычлык белән басып тора алуын күреп, каушап калдык.

Кызлар белән очрашканда каушау түгел, киресенчә, күп вакытта әрсезләнеп, теле ачылып китә торган иптәшем Гаяз да, үзенең кайда икәнлеген онытып, таянычсыз хәлдә калды: аның тулы кара күзләре, зарыгып җавап көткән төсле, билгесез кызның серле торышына текәлеп тукталды. Куллары да, аңлы бер максат белән түгел, тик инстинкт белән генә үзләреннән-үзләре хәрәкәтләнеп, тыгыз гәүдәсен су өстендә тоталар иде...

Кем ул? Шәһәрдән читтә, Агыйделнең дә пароходлар йөрми торган җирендә, Башкортстанның шактый караңгы почмакларыннан исәпләнгән тәңгәлендә шундый матурлыкка, кыю батырлыкка ия булырлык серле кыз кем ул?..

Бу сорауларга җавап таба алмау тәэсирендә нишләргә белмичә байтак азапланган булыр идек, Гаяздагы кыюлык ярдәмгә килде. Ул, әле һаман да селкенми торган кызга карап, кискен, батыр тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Бәхетле иртәгез белән тәбрик итәбез!

Кызның тауларга текәлгән кара күзләре кинәт безгә борылды. Тамарга торган чия төсле иреннәр, сизелер-сизелмәс дәрәҗәдә генә елмаю билгесе күрсәтеп, җай гына хәрәкәтләнделәр:

— Рәхмәт.

Тал арасына сибелгән сандугачлар музыкасын күмеп, шыңгырдап чыккан көмеш тавыш белән әйтелгән бу җавап

безгә шулкадәр якын, шулкадәр ягымлы булып ишетелде, моңа кадәр татып каралмаган яңа, рәхәт тойгы бөтен тәнебезне чолгады. Әллә кайдан тирәннән, керсез йөрәктән чыккан төсле булып ишетелде ул рәхмәт. Якын киләчәктән кадерле очрашулар вәгъдә иткән төсле булып яңгырады ул музыка.

Мин, кызның серле карашын үземә тартырга теләп, бөтен көчем белән аның күзләренә карый идем. Билгеле, Гаязның да шул теләктә икәнлегендә, аның да кара күзләре (ул көчле кара күзләр бу минутта минем өчен куркыныч тоелдылар) мин караган сихерле нокталарга тартылган булуында шигем юк иде. Ләкин серле кызның сихерле карашын үзебезгә тарту өчен барган бу көрәштә икебез дә җиңелдек. Кыз беребезгә дә аерым караш бирмәде, җитез хәрәкәтләр белән куе таллар арасына кереп югалды.

Икебез дә телсез калып, кызның яңадан күренүен көттек. Бик озак көттек. Кыз яңадан күренмәде. Су өстендә озак тору, өзлексез хәрәкәт безне арытты. Агыйдел, бу тәңгәлдә кызу акмаса да, безне шактый алып китеп өлгергән иде инде. Арыган булуыбызга карамастан, кыз күренгән ярга чыгып ял итәргә батырлыгыбыз җитмәде, ерак булса да, кайту ягына борылдык...

Кире кайткан вакытта инде без килгәндәге төсле шаян түгел идек. Кыз безнең йөрәкләрдән нәрсәнедер алып киттеме, нәрсәсендер безгә калдырып киттеме, ни булса да булды, безнең уйда да, телдә дә шул булды. Тик, никадәр генә уйласак та, никадәр генә сөйләсәк тә, аның кем булуы, каян килеп чыгуы турында рәтләп бернәрсә дә белә алмадык. Агыйделнең бу тәңгәленә килүенә карап кына, Кинҗә исемле кечкенә башкорт авылыннан булырга тиеш, дигән нәтиҗәгә килдек.

— Очратырбыз әле без аны, Гаяз, ә?

— Бәлки...

изрәп яту — рәхәтләнеп яту
фәкать — бары тик
хозурлыгы — яме, матурлыгы
чоңгыл — омут
тәңгәл — *монда:* урын
зелпе — җимеш бирә торган куак (жимолость)
чобарлый-чобарлый — чуарлый-чуарлый

Сораулар һәм биремнәр

1. Ильяс ни өчен татлы җиңел уяну кичерә?
2. Авторның Агыйдел табигатен сурәтләве сезгә ошыймы? Ни өчен?
3. Текстта сез сөйләмегездә файдаланмаган нинди матур сүзләр бар? Алар күбрәк кайсы очракта кулланылган?
4. Агыйделнең матурлыгын тасвирлау өчен, автор нинди әдәби алымнардан файдаланган?
5. Бу бүлектә сурәтләнгән ике егет турында нәрсәләр белдегез?
6. «Туган ягым табигате» дигән темага сөйләшүне дәвам итегез. Аны саклауда сез нинди өлеш кертәсез? Бер-берегездән интервью алыгыз.
7. «Туган ягым табигате» дигән темага сочинение языгыз.
8. Агыйдел табигате тасвирланган бер өзекне яттан өйрәнегез.

17

Спектакль башланырга биш минут вакыт калганда, көтелмәгән бер бәла килеп чыкты.

Кичәбезнең сөйләүләр өлеше бетеп, тәнәфес игълан иткән вакытта, безнең күңелләр артык күтәренке иде. Пәрдә төшерелеп, сәхнә артында калгач, без Гаяз белән яхшы тойгыларыбызны уртаклашып алдык.

— Я Ильяс, синең кәефләр ничек, эшләр бара бит? — диде Гаяз.

— Көтелгәннән дә артыграк,— дидем мин.

— Тик Имәли генә бераз арттырыбрак җибәрде. Бу чаклы масса алдында ул кадәр ачылу кирәкмәс иде, ә?

— Беркатлырак шул ул, аны аңа аңлатырга кирәк булыр.

— Зарар юк, гомумән алганда, безнең файдага. Тик менә Артыкбикә килмичә начар итте.

— Әйе шул, ул да килгән булса, дөньябызның төгәлләнмәгән җире калмый иде. Бик күңелсез булды аның килмәве.

Чынлап та, Артыкбикәнең юклыгы тагын да яхшырак тойгылардан мәхрүм итә иде безне.

Ул арада безнең яныбызга гримланган артистларыбыз җыела башлады. Аларны күрүгә, Гаязның да төп эше исенә төште: ул ашыга-ашыга Хәлил булып киенергә, гримланырга тотынды. Минем яныма Мәһибикә килде. Өстенә биле бөрелеп тегелгән киң чуар күлмәк кигән, башына зур яшел яулык ябынган, япь-яшь битенә калын-калын сызыклар сызган — янәсе, карт хатын булган...

— Ильяс абый, гримым әйбәтме? — дип сорады ул миннән.

Зур кара күзләрен тутырып ачып, күзләремә карады да, елмаеп, башын түбән иде. Карчыклардан бигрәк бите-башы балчыкка каткан балаларга охшый иде ул.

— Юк, Мәһибикә, болай ярамый,— дидем мин,— кил, үзем төзәтим,— дидем. Грим өстәле янына алып килеп, карт хатынга охшатырга тотындым. Чем-кара сызыкларны кызгылт буяу белән күләгәләп, җыерчыкка охшата төштем. Күзләренә тарткан сөрмәсен бетердем.— Болай да синең күзләрең тарантас тәгәрмәче хәтле, карчыкларның күзләре алай булмый,— дип көлдем. Ул минем төзәтүемә, битләреннән сыйпавыма иркәләнеп, риза булып торды.

Аны рәтләп бетерергә өлгермәдем, Зоя килеп бүлдерде:

— Ильяс, кара әле, минем гримым ярарлыкмы?

Зояга борылып карау белән, каушап, кычкырып җибәрдем:

— Юк, юк, һич ярамый. Бу мөмкин түгел!

Ул Галиябануны — авыл кызын — революциягә кадәр булган татар авылы кызын уйный. Үзе, ярты күкрәген ялангач калдырып, зур ачык якалы ак кофта кигән. Бөдрәләндереп кабарткан сары чәчләре өстенә кечкенә калфак кадаган булган. Җитмәсә, тездән генә итеп тегелгән зәңгәр юбкасы астыннан тыгыз ефәк оеклар ялтырый. Аягында биек үкчәле туфля.

— Юк, юк, Зоя, хәзер киемнәреңне алыштыр. Син авыл кызын — крестьян кызын уйныйсың. Сиңа әзерләгән киемнәр бар бит.

Зоя минем сүзләремә аз гына да илтифат итмәгән кыяфәт белән көлде һәм, кирәксез кыланышлар белән боргалана-боргалана:

— Ә миңа шушылай килешә,— диде.

— Һичшиксез алыштырырга кирәк, тиз бул. Башларга вакыт җитте,— дидем.

— Мин алыштырмыйм.

— Алыштыр!

Ахрысы, катырак кычкырып җибәргәнмендер, яныбызга ашыга-ашыга Гаяз килеп җитте. Ул Хәлил булып киенеп, бизәнеп өлгергән иде инде.

— Нәрсә бар, нинди кычкырыш? — диде ул.

— Менә Галиябануның киемнәрен кара әле, нинди чибәр! — дидем мин, Зояны күрсәттем.

— А-а... Һич ярамый,— диде Гаяз.— Нинди рольдә уйнаганыңны белмисеңмени син, Зоя? Алыштыр, тиз бул!

Зоя һаман киреләнде:

— Миңа шушылай килешә.

Гаяз кыза төште:

— Сиңа килешүдә эш түгел. Авыл кызы булып киен. Тиз бул. Вакыт бетте бит.

— Юк, мин шушылай уйныйм.

— Бу нинди капризлану? — диде Гаяз тавышын күтәреп.— Бүгенгә генә ташлап тор ичмасам шул мещанкалыгыңны!

— Алайса, мещанка булмаган кызларыгызны табыгыз,— диде дә Зоя, борылды да китте.

Без, Гаяз белән икәүләп, аның артыннан ташландык. Икебез ике иңбашыннан тотып туктаттык.

— Бу ни эшләвең, Зоя? Әзерләнгән спектакльне җимермәкче буласыңмы?

— Мещанка булмаган кызларыгыз уйнасын,— диде Зоя, башындагы калфагын алып ыргытты.— Мин кайтып китәм.

— Мәҗбүр итәрбез без сине! — диде Гаяз.

Зоя, мәсхәрәле елмаю белән безгә карап: «Рәхмәт»,— диде дә киенү бүлмәсенә чыкты.

Гаяз белән күзгә-күз карашып, аптырашта калдык.

— Нишлибез?

— Бернишләр хәл юк, хатын-кызлар җитмәве үтерә. Болай да бит карчык ролендә малай кеше уйный.

— Әйе, бернишләр хәл юк, Ильяс, риза булырга туры килә. Уйнасын шул киемендә. Соңыннан кирәген бирербез, кабахәтнең.

Икәүләп Зоя кергән бүлмәгә ташландык. Ишек бикле иде.

— Зоя, ач әле.

Эчтән җавап булмады. Йомшаграк тавыш белән дәшеп карадык. Җавап булмады. Залда халык, пәрдәнең тизрәк ачылуын сорап, кул чаба башлады.

— Зоя, ач, анда безнең әйберләребез бар! — дип өзгәләндек без.

Ишек ачылды. Үзенең көн дә кия торган гади киемнәрен киенеп, Зоя килеп чыкты. Безгә эндәшмичә, сәхнәдән чыгуга табан атлый башлады.

— Тукта, Зоя, үзең теләгән киемнәрдән уйнарсың, спектаклебезне генә харап итмә.

Зоя, безгә эндәшмичә, сикереп сәхнәдән төште дә, ашыга-ашыга атлап, мәктәптән үк чыгып китте.

Нишләргә белмичә, тирән аптырашта калдык. Залда кул чабулар, аяк дөбердәтүләр көчәйгәннән-көчәя бара иде.

— Әллә Галиябану ролендә үзең уйныйсыңмы, Ильяс? — диде Гаяз.— Төскә-биткә артык ямьсез түгелсең, грим белән рәтләп булыр, бәлки.

Гаязның бу сорауны куюы миңа кызганыч тоелды. Ике елдан артыкка сузылган иптәшлек гомеремдә аның бу кадәрле таянычсыз хәлдә калуын беренче күрүем иде.

— Син, Гаяз, юләрләнәсең булса кирәк, миннән Галиябануны уйнату — адәм көлдерү бит.

Гаязның бу фикергә кушылмыйча чарасы юк иде.

— Ичмасам, Артыкбикәсе дә килмәде, шайтан! — дип куйды өзгәләнеп.

— Болай булгач, аның килмәве хәерле булды инде,— дидем мин,— мондый хурлыкка калуыбызны аңа күрсәтү тагын да начаррак булыр иде.

— Бәлкем, ул безне мондый әшәке хәлдән коткарган булыр иде.

Без тагын нәрсә әйтергә белми сүзсез калдык. Котчыккыч хурлыклы аптыраш иде бу. Ул минутта Гаязның йөзенә чыккан өметсезлек, таянычсызлыкка карап елыйсым килә иде минем. Тик Гаяздагы бу ямьсез чырай озакка бармады. Ул каты итеп тешен кысты, кашларын җимерде дә, уң кулын каты йодрыклап, һавага кизәнеп куйды:

— Ярый! — диде. Тавышы нык, ышанычлы иде.— Булмаса булмас, «Галиябану»ны калдырабыз, концерт бүлеген башлыйбыз. Бар, син чыгып халыкка аңлат, мин монда гримнарымны сөртеп, Зоя турында берәр нәрсә яза торыйм. Концерт бүлегендә үзем чыгып сөйләрмен. «Галиябану»ны ни өчен куймавыбызның сәбәбен әйтми тор. Бәгъзе бер сәбәпләр аркасында гына дип әйтерсең. Концертта аңлатырбыз без аны, бар, тынычландыр, син тынычландыра беләсең...

Мин пәрдә алдына чыгып басуга, кул чабу, аяк тыпырдату, сызгыру тавышлары басылды. Иң алдагы сафта утырган Низамыйның миңа карап мыскыллы елмаю күрсәтүе мине эсселе-суыклы итеп җибәрде. Коточкыч җинаять күрдем мин аның йөзендә. Ләкин түзүдән башка чара юк. Никадәрле авыр булса да, сабырлыкны югалтмыйча, халыкны тынычландыру кирәк иде. Әйтәсе сүземне тиз генә күңелемнән барлап чыктым.

Минем нәрсә әйтүемне тирән тынычлык белән көтүче халык өстенә карап, «Иптәшләр!» диюемә, урам як ишек ачылып китте. Миңа таныш булмаган берничә башкорт кызы күренде. Күңелем нәрсәдер сизенде. Әйтәсе сүземне әйтмичә, күземне шул кызлар арасына юнәлттем. Ят кызлар арасыннан аерылып, Артыкбикә күренде. Шулкадәр җиңел булып китте миңа, әйтә алмый торган авыр сүзләр башымнан бөтенләй чыгып киттеләр. Аз гына да уйлап тормыйча, кичәбезгә күрше авылдан килгән кунаклар турында хәбәр бирдем.

— Иптәшләр, көткән кунакларыбыз килде. Алгы сафтан урын әзерләгез.

Үземне үзем белешмичә, сәхнәдән сикереп төштем дә Артыкбикәгә каршы йөгердем. Артыкбикә белән бергә алтыҗиде башкорт кызы һәм биш-алтылап мәктәп малайлары килгән иде.

— Соңгарак калдык, Ильяс иптәш, ачуланмыйсызмы? — диде Артыкбикә.

— Бик вакытлы, бик вакытлы, әйдәгез.

Мин аларны, йөгерә-йөгерә, алгы сафка уздырдым. Алгы сафта Низамыйдан башкалар урыннарын бушатканнар иде. Ләкин ике кунакка урын җитми калды.

— Низамый, кунакларга урын кирәк,— дидем мин.

Низамый сүзсез кузгалды. Аның урынына кечкенә башкорт малаен утырттым да урын җитми калган кунакларның соңгысы булган Артыкбикәне сәхнәгә алып кердем.

— Гаяз кайда?

— Кием бүлмәсендә,— диделәр.

Гаяз, сул кулының бармакларын чәч араларына тыгып, кашларын җимереп, язып утыра иде. Без кергәч тә, күтәрелеп карамады ул.

— Гаяз, кунак килде, кузгал,— дип кычкырып җибәрдем.

Гаяз кинәт безгә борылды. Артыкбикәне күрү белән сикереп торды. Исәнлек-саулык сорашып тормастан, Артыкбикәнең иңбашларына килеп тотынды:

— Иделбаева, әйтегез, «Галиябану»да уйнаганыгыз бармы сезнең?

Артыкбикә тыныч кына елмаеп куйды:

— Техникумда чакта мин аның героинясы идем. Гаяз да, мин дә шатлыктан шашкан тавыш белән кычкырып җибәрдек:

— Шулаймы?

Үз-үзебезне онытып, икебез берьюлы кочаклап алдык без аны.

— Димәк, безне бу хурлыклы хәлдән котылдырдыгыз?

— Ни булды сезгә? — диде Артыкбикә. Бернәрсә аңламаган кара күзләре белән бер миңа, бер Гаязга карап сорау бирде.— Ни булды сезгә? Бернәрсә дә аңламыйм.

Эшнең нәрсәдә икәнен тиз аңлаттык. Шул ук минутта мин, яңадан пәрдә алдына чыгып, спектакльнең биш минуттан башланачагы, Галиябануролендә яңа артистка уйнаячагы турында хәбәр бирдем. Көчле алкышлар мәктәпне күтәрә яздылар...

Артыкбикә беренче җыры белән үк залны үзенә каратты.

Андый көчле җырны, андый йөрәк җырын гомеремдә беренче тапкыр ишеткәнмендер. Шулкадәр дәртләнеп, шулкадәр бирелеп җырлый иде Артыкбикә, әйтерсең лә ул чынчынлап Галиябану кичергәннәрне үз йөрәгендә кичерә. Аның вакытлыча гына Галиябану роленә кергән һәвәскәр артистка икәнлеген онытасың. Йөрәгең, үзеңә дә сиздермәстән, аның йөрәге белән кушыла. Ул куанганда куанасы, ул көлгәндә көләсе килә. Ул боекканда боегасы, ул елаганда аның белән бергә елыйсы килә. Бер күтәрелеп, бер төшеп сулый торган калку күкрәгеннән агып чыккан үтә саф тавышның кеше тавышы булуына ышанасы килми. Анда гади кешегә аңлашылмый торган ниндидер сер яшерелгәндер сыман тоела...

Бүгенге кичәнең җитәкчесе — үзенә күрә режиссеры булуым мине беразга айнытты. Бу сихерле музыка әсирлегеннән йөрәгемне тартып алып, үзен үзе оныткан залга карадым. Залдагылар, чын-чынлап, үзләрен үзләре онытканнар иде. Бик күпләрнең кыяфәтләре миңа көлке тоелды. Кем нинди хәлдә булса, гипноз белән йоклатылган шикелле, шул хәлендә катып калган. Күпләрнең, аскы ияклəрен дәябып тотарлык ихтыярлары калмыйча, авызлары ачылган, күпләр, муеннарын тота алмыйча, көлке кыяфәтләргә кереп, башларын кыегайтканнар, һәрберсе үзенә бер төргә ия булган күзләр, барлык көчләренә киерелеп ачылып, сәхнәгә текәлгәннәр... Бөтен зал шулай катып калган.

Бу тиңе булмаган йөрәк көче алдында үзен үзе югалтмаган бер генә кеше күрдем мин — ул Низамый иде. Аның аптырашта калган ачулы күзләре ниндидер авыр сорауга җавап эзлиләр. Ләкин мондый минутта кем аңа җавап бирсен?! Аның барлыгын белүче дә юк... Ул, залда урнашкан йөрәк

тынлыгын җимерергә теләмәгән сыман, әкрен генә урыныннан кузгалды. Кепкасын кулына тоткан килеш, аяк очларына гына басып, ишеккә таба атлады. Аның чыгып китүен миннән башка берәү дә күрмәде дә, сизмәде дә. Мин, үземне зур көрәштә җиңеп чыгучы батыр кебек хис итеп, залдан күзләремне алдым. Йөрәгем яңадан Артыкбикә йөрәге белән тоташты.

сөрмә — чәч, каш, керфек каралта торган буяу
ихтыяр — *монда:* түземлелек
бәгъзе — кайбер

Сораулар һәм биремнәр

1. Яшьләр нинди спектакльгә әзерләнәләр? Ул әсәрнең авторы кем? Сезнең бу спектакльне караганыгыз бармы?
2. Зояның спектакльне өзеп чыгып китүе белән килешәсезме? Ни өчен?
3. Артыкбикә образына характеристика бирегез.
4. Өзектән фразеологизмнарны табыгыз, мәгънәләрен аңлатыгыз.
5. Әсәрне тулысынча укыгыз.

Фәхри Насретдинов

(1911—1986)

Татарстан Республикасының һәм РСФСРның халык артисты Фәхри Насретдинов (Фәхри Хөсәен улы Насретдинов) Татарстанның Апас районы Шәм-Балыкчы авылында крестьян гаиләсендә туа. Бу гаиләдә татар халык җырларын бик яраталар һәм матур итеп җырлый да беләләр.

1921 елгы ачлык вакытында Фәхри ятим кала, һәм олы абыйсы аны Мәскәүгә алып китә. Монда ул текстиль фабрикасында эшли һәм фабрика каршындагы драмтүгәрәккә йөри.

Балачактан ук җыр яратуы, җырчы булу теләге аны 1929 елда Мәскәү эшче татар күчмә театрына алып килә.

Өлкән артистларның киңәше буенча Фәхри Насретдинов 1930 елда Мәскәү музыка техникумына укырга керә. Әмма театрны да ташламый. Музыка техникумын тәмамлагач, 1934 елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы Татар опера студиясенә кабул ителә.

Аның иҗат юлының башы Казанда Татар дәүләт опера һәм балет академия театры ачылган чорга туры килә. 1938 елның декабрендә ул бер төркем татар композиторлары, җырчылары, музыкантлары белән Казанга кайта һәм шушы театрда эшли башлый. Анда утыз елдан артык эшләү дәверендә Фәхри Насретдинов бик күп образлар тудыра.

Һәр җырчының үз амплуасы була. Тавышы лирик тенор булганга күрә, ул күбрәк лирик партияләрне җырлый. Шулай ук башка характердагы образларны да бик уңышлы иҗат итә. Җырчы буларак талантын исәпкә алып, аңа опера спектакльләрендә төп партияләрне тапшыралар. Мәсәлән,

татар композиторлары әсәрләреннән Н. Җиһановның «Алтынчәч» (М. Җәлил либреттосы), «Качкын» (Ә. Фәйзи либреттосы), «Түләк һәм Сусылу» (Н. Исәнбәт либреттосы), «Илдар» (М. Җәлил либреттосы) операларында — Җик, Кирәмәт, Түләк, Илдар, Ж. Фәйзинең «Тапшырылмаган хатлар»ында (Г. Кутуй повесте) — Вәли, «Башмагым»да (Т. Гыйззәт либреттосы) — Галимҗан партияләре, рус һәм дөнья классикасы әсәрләреннән төрле партияләр. Ф. Насретдинов татар халык көйләрен һәм композиторларыбыз җырларын да яратып башкара, эстрада концертларында да еш катнаша.

Татар опера сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Фәхри Насретдинов 1950 елда Татарстанның халык артисты һәм 1957 елда РСФСРның халык артисты дигән мактаулы исемнәргә лаек була. 1959 елда күренекле җырчыбызга актив концерт эшчәнлеге һәм композиторлар әсәрләрен пропагандалавы өчен Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

Фәхри Насретдинов 1986 елда Казан шәһәрендә вафат була.

амплуа — бер актер тарафыннан башкарыла торган бер тип рольләр
тенор — җырчының тавыш төре, ирләрнең югары тавышы

Сораулар һәм биремнәр

1. Фәхри Насретдиновның иҗат юлы турында сөйләгез.
2. Сез аның башкаруында нинди җырлар тыңлаганыгыз бар?
3. Хәзерге көндә опера сәхнәсендә зур уңышларга ирешкән артистлардан кемнәрне беләсез? Үзегез яраткан опера артисты турында сөйләгез.

5 К 5/146

Шамил Усманов
(1898—1937)

Күренекле язучы Шамил Усманов (Шамил Хәйрулла улы Усманов) 1898 елның 26 декабрендә хәзерге Пенза өлкәсенең Пәндәлгә авылында укытучы гаиләсендә туа. Шамил башта Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала, аннары һөнәр училищесын тәмамлый. 1917 елгы февраль революциясенә кадәр Акчуриннарның Гурьевка туку фабрикасында эшли. Шул елның җәендә гаскәри хезмәткә алына. 1918 елда «III Интернациональ легион»[1] оештырыла. Легионның комиссары итеп Шамил Усманов билгеләнә. Ә 1919 елда Беренче Идел буе татар бригадасы комиссары итеп сайлана. 1925 елда дивизия комиссары дигән хәрби исем бирелә.

1930 елдан башлап, Шамил Усманов тулысынча әдәби иҗат эшенә күчә. Ул — проза һәм драма әсәрләре авторы. Аның хикәяләрендә («Ил кызы» (1923), «Әптери агай хикәясе» (1925), «Зур түрә» (1927), «Идел буйлап» (1929) h. б.) гражданнар сугышы күренешләре, революциягә кадәрге эшчеләр тормышы сурәтләнә, гади хезмәт кешеләренең гаделлеккә, бердәмлеккә омтылулары чагылдырыла. 1923—1935 елларда Ш. Усманов «Легион юлы» исемле дилогиясен яза. Әсәрдә гражданнар сугышы чорында ак казакларга каршы алып барылган героик көрәш сурәтләнә.

Язучының маҗара жанрында язылган һәм төрле телләргә тәрҗемә ителгән «Памирдан радио» повестенда Урта Азиядәге гражданнар сугышы фаҗигаләре күрсәтелә.

---

[1] Бу легион татар-башкорт кызылгвардиячеләре һәм әсир венгр, поляк, немец үзиреклеләре кушылып төзелә.

Драматург буларак, Ш. Усманов «Канлы көннәрдә», «Беренче адым», «Бай кызы» һәм «Кичеккән фәрман» исемле пьесаларын яза. Алар төрле театр сәхнәләрендә күп мәртәбәләр куела.

Шамил Усманов — шәхес культы корбаны. Аның гомере 1937 елның 3 декабрендә Казан шәһәрендә өзелә.

ӘПТЕРИ АГАЙ ХИКӘЯСЕ

Әптери агай фабриканың язылмаган аяклы тарихы инде. Ул фабрикада туган. Алты яшеннән бирле өзлексез эшләп килә. Аңа хәзер илле тугыз яшь. Киләсе елга эшчеләр аның алтмыш еллык юбилеен үткәрергә уйлыйлар. Әптери агай үзе дә юбилей ясауга каршы түгел. «Тик, алтмыш яшь тулды дип, эшемнән алып пенсиягә куа күрмәгез»,— ди.

Илле елдан артык хезмәт аны бик бетермәгән. Үзе эшне бик сөйгәнлектәндер инде, эше никадәр авыр булса да, ул шундый дәрт белән аңа керешә. Аның белән сверхурочный эшләү дә күңелле. Эштән бушап, тәмәке кабызырга утырды исә, хәзер сөйләргә тотына.

Нәрсә сөйли дисез... Аның сөйлисе сүзләре күп шул.

Алтмыш яшенә карамастан, аның хәтере яшь егетнеке төсле. Һичнәрсә онытмаган. Ничек итеп илле ике ел элек фабрикага хезмәткә килеп кергән дә ничек тәмәке тарта башлаган. Управляющий кыйнаган, бер мәртәбә үзе управляющийны кыйнарга теләгән өчен бай, расчет биреп, ике-өч көн ялындыргач, кире хезмәткә алган.

— Нигә ялвардың соң, әллә фабрикадан башка җир дөньяда юк идеме? — диюгә, ул:

— Дөньяда җир күп тә, туган җир күк була алмый шул,— дип җавап бирә.

Сүзне ул ашыкмыйча гына, матур итеп тезеп сөйли белә. Аның хикәяләрен тыңлап, таң җиткәнне сизми каласың.

Сүз күп вакытта газетадан башлана. Ул яңа килгән эшче газеталарыннан берәрсен алып карый да, бер урында туктап:

— Менә шахтада газ шартлавын язган. Күп эшчеләр үлгән, ди. Хәтеремдә, бер елны бездә дә казан шартлаган иде...— дип, исенә килеп төшкән эпизодны сөйли башлый. Яисә моннан егерме биш ел элек булган бер пожарны сөйләп китә.

Беркөнне шулай, бүлмәдә утырганда, «Иске хуҗаларны бетерергә кирәк» дигән мәкаләне укыдык. Анда частный завод-

ларның берсендә хуҗаның эшчеләр белән начар кылануы язылган. Әптери ихлас белән тыңлап утырды.

— Әх, егетләр! Сез иске хуҗаларны белмисез әле... Сез менә минем яшьлектә фабрика хуҗасы булып торган Мөхит байны белсәгез иде...— дип, сөйләргә теләгәнен белдерде.— Әйе... андый хуҗаларны сезнең күргәнегез дә юк. Күрергә дә туры килмәсен. Ул үзе фабрикант та, алпавыт та иде.

Менә бу тирә-якның бөтен җирләре, каршыдагы урманнар — барысы да аның кулында иде. Тирә-яктагы авыллар — барысы да электә крепостнойда булганнар, хәзерге байның җирен арендага алып эшләп киләләр иде. Барысы да муеннан бурычка баткан. Эшләгән саен бирәчәкләре арта бара. Ахырында, җир белән тамак туйдыру өметен югалтып, фабрикага килеп керәләр иде. Ә монда эшләр тагын да начар, чын каторга.

Хәзер бит сез менә барыгыз да сигез генә сәгать эшлисез. Әүвәлдә унар сәгать эшләгәннәр, дип сөйлибез. Ә менә мин үзем ул вакытларда унөчәр-ундүртәр сәгать эшли идем. Күбрәк эшләүчеләр дә бар иде.

Туку корпусында, хәзерге машиналы станоклар урынына, кул белән тукый торган агач станнарда эшли торган иделәр. Тукучылар, эшкә үз шәмнәре белән килеп, көн-төн эшләп, шунда кунып, шунда ашап-эчеп, атналар буе өйләренә кайтмыйлар иде.

Бай үзе, иртә таңнан торып, эшләгәнне карап йөри. Кулына таяк тоткан. Бераз гына күңеленә ошамаган эш күрсә, хәзер кычкырынып, сүгенергә тотына. Кызып китсә, чукмары белән аркага да кундыра.

Әптери агай белән утыз еллап бергә эшләп килгән Шәймәрдән карт:

— Дөрес, егетләр, җир йотсын, дөрес. Хәзер минем дә исемә төште. Бервакытны мине дә кыйнаган иде. Ике атна буена җилкә тамырларым авыртып йөрде,— дип куйды.

Аның болай итеп сүзне беркетүе тыңлаучылар алдында Әптеринең авторитетын күтәрде. Тагын да якынрак килеп тыңлый башладылар.

— Әйе, таяк ягына юмарт иде. Приказчик мастерларны бик еш алмаштыра торган иде. Нинди усал булсалар да, байга ярап бетмиләр, юаш күренәләр.

Икенче яктан, артык каты булсалар, эшчеләр үч алалар. Кич белән туры китереп, башына капчык кидертәләр дә кабыргаларын санадылар.

Приказчик яллаганда, бай, элек фабрика буйлап йөртеп, бөтен нәрсәне күрсәтеп чыга.

— Менә сиңа эш. Таңнан алып кояш баеганчы карап йөрисең. Сәгать санаулы түгел. Жалованье — айга 25 сум. Таяк хозяйский,— ди торган иде.

Шулай итеп, «хозяйский таяк»ка хезмәт итәргә яраклы кеше эзли торгач, бервакытны эзләгән кешесен тапты да бит.

Күрше фабрикаларның берсеннән Каганин дигән, усаллык белән даны чыккан бер урыс килеп чыкты.

Калын, тәбәнәк, чөгендер төсле кызыл. Кыяфәткә ямьсез. «Бик яхшы» булганлыгы өчен эшчеләр бер-ике мәртәбә капчык кидергәннәр, шунда борыны изелгән. Ну, чын эт иде дә инде! Иртә таңнан алып караңгыга кадәр йорт буйлап усал эт төсле өрә торган иде.

Бай үзен бик тиз яратып китте. Кайвакытларда управляющий авыру яисә берәр эш белән читкә киткәндә, Каганин аның урынына кала торган иде...

Бер елны яз җитү белән фабрика ремонтка тукталды.

Аппаратныйга Германиядән килгән секретлар куя иделәр. Башка машиналар да сүтелеп, чистартып, бозылган җирләре яңадан ясалып куела башлады. Мин ул вакытны механический мастерскойда эшли идем. Ремонт вакытында берничә слесарьны, шулар арасында мине дә, пар казаннарын чистартырга җибәрделәр. Казан чистартуны беләсез, кулга чүкеч-зубило тотып, люктан төшеп, казан эчендә шәм кабызып, ябышкан пычракларны куптара башлыйсың. Берничә чүкечнең тавышыннан һичнәрсә ишетелмәслек шау күтәрелеп тора.

Теге Каганин көнгә ун мәртәбә килеп, казан түбәсенә менеп, эчкә карап тора иде. Берәр эш белән чыкканда ул:

— Яхшылап арчыгыз! — дип кала. Эштән туктап озаграк тәмәке тартсаң:

— Әй сез, әрәмтамаклар, вакытыгыз өчен акча аласыз бит,— дип кычкырынырга тотына. Ачудан, югарыдан зубило белән бәреп җибәрәсе килә.

Беркөнне казанны арчып бетердек. Мин, ялгыз гына калып, соңгы эшләрне эшләдем дә инструментларны алып чыгарга дип люк янына килдем. Чыкканда карасам, бай белән Каганин казан башына менгәннәр дә сөйләшеп торалар.

— Үзем өсләреннән карап арчыттым, Мөхит Харитоныч, казан эче көзге төсле булды,— дип сөйләнә тегесе. Мине күргәч:

— Я ничек, бетердегезме? Яхшы арчыдыгызмы? — дип сорады.

— Яхшы. Көзге төсле ялтырый. Теләсәгез, үзегез төшеп карагыз,— дим. Мин уйнап кына әйткән идем, карасам, Каганин казан авызына килде дә җиңнәрен сызгана башлады. Мин көлеп җибәрмим дип, сулышымны эчемә алып, әкрен генә борылып карадым. Теге бер-ике мәртәбә шикләнеп карады да люк эченә төшеп тә китте. Казан авызын беләсездер инде, анда төшәргә бик җиңел. Ә менүгә килгәндә — эшләр башка. Мин тиз генә машинныйга бардым да иптәшләргә:

— Поганин (приказчикны без шулай дип йөртә идек) казанга төште,— дидем.

— Чынлапмы?

— Менә бәйрәм!

— Хәзер анда тозлыйбыз үзен.

— Ничек итеп төште, кем төшерде? Мин эшне сөйләп бирдем. Слесарьларның йөзләрендә бәйрәм уйный иде.

— Кара бәдбәхетне, чыга күрмәсен.

Без әкренләп кенә ишек ярыгыннан карадык. Теге, казан авызыннан башын чыгарган да, ярдәмчесез кыяфәт белән тирә-ягына карап тора.

— Менә алмый, менә алмый,— дип шатландык. Бай элек үзе дә кызыгып караган иде. Соңыннан люк янына килеп, Каганинга кулын биреп, күтәреп карады. Бернәрсә дә чыкмады.

— Әй, кем бар анда? Булышырга килегез! — дип кычкырды бай.

Без мыек астыннан гына көлеп мендек һәм:

— Ни боерасыз, бай? — дидек.

— Чыгарыгыз әле үзен,— дип, безгә әмер бирде.

Бай кушкач, безгә нәрсә! Элек аска төшмичә генә күтәрергә уйладык. Теге мәхлук та, дуңгыз кебек симез, кызарган, безне күргәч, ышанып кулларын сузды. Без, икәү, ике кулыннан тартып чыгара башладык. Өченчебез башыннан тотты.

Чыкмаячагын үзебез дә беләбез, өстәвенә уңайсызрак итеп күтәрергә тырышабыз. Мин кулын уңайрак итеп борып күтәргән идем:

— Алла, кулым! — дип кычкырып җибәрде. Без, аның кычкыруына карамыйча тарткач, әллә нинди тавышлар чыгарып акыра башлады. Җибәрергә туры килде.

Бай ачулана башлады:

— Карт пәри! Кем кушкан иде сиңа анда кереп йөрергә? Менә хәзер үзең чык инде,— дип борылып китте. Киткәндә безгә:

— Акыруына карамыйча чыгарырга тырышыгыз үзен,— дип әмер биреп китте.

Ярдәмгә берничә кеше чакырдык. Икәү, өчәү аска төштек. Күтәреп карадык, күтәргән саен теге хәлсезләнә бара. Ул хәлсезләнгән саен, без катырак тартабыз. Бер эш тә чыкмый. Кулын уңайсыз күтәргәнлектән, чынлап та каймыккан икән: кызарып чыкты, шешә башлады.

Бераздан бай кайтты.

— Әле дә чыкмадымыни, дуңгыз? — дип сүгенә башлады.

Ул бу эшнең ахыры хәерлегә булмасын сизенә иде. Кичкә казаннарны ягып, иртәгә фабриканы җибәрәсе бар. Ә казан эчендә Каганин ята. Ничек тә чыкмый. Я авырган кулы төзәлгәнне көтәргә яисә казанны сүтәргә кирәк. Фабриканың бер көн эшсез торуы меңнәрчә зарар бирә, өстәвенә Мәскәүдән мастерлар чакыртып казанны сүттерү үзе меңнәр тора.

Бу уйлар байны чынлап борчый башлады. Ул, казан авызына бөгелеп, «сөеклесен» тиргәргә тотынды:

— Карт тиле! Дуңгыз кебек корсагың була торып, тар казан авызыннан сыярга уйладың, дурак. Хәзер үк чыккан бул, югыйсә үзеңне тереләтә казанда пешерергә кушармын.

Каганин җавап бирми иде. Ул, казан төбенә ятып, авырткан кулын тотып, ыңгырашып, сау кулы белән туктаусыз чукына иде.

Аның казанга төшү хәбәре бөтен фабрикага таралды. Әллә кайдан хатыны килеп чыкты. Хатыны элек турыдан казанга төшәргә уйласа да, бай кушмады.

— Бер дуңгыз ятуы җитмәгән. Монысы тагын да калынрак,— дигәч, хатыны югарыдан торып кына ире белән сөйләшә башлады:

— Җаным, үзең генә чыга алмыйсыңмы соң?

— Алтыным, байга әйт, ачуланмасын, банкыда җыйган өч меңем бар. Китергән зарарны шуның белән түләрмен.

— Түләрсең, карт дурак! Синең ул өч меңең нәрсәгә җитсен!

Казан эченнән тагы да өметсезрәк тавыш ишетелде:

— Феклушам. Җаным. Әйт байга, әгәр дә күп зарар күрә торган булса, мине кызганмасын. Фабриканы җибәрсен, тәкъдиремдә шулай үләргә язылгандыр.

Бай бер сум файда өчен биш кешене терелэтэ кайнатырга әзер булса да, бу юлы ул эшне эшләргә ярамавын белә иде. Ул тирә-ягына җыелган слесарьларга карады да:

— Яле, егетләр, чыгарыгыз үзен. Акыруына карамагыз, тере килеш чыгарсагыз, егерме биш сум сезгә,— диде.

Безгә нәрсә, бай кушкач эшлисең генә.

Дүртәү казанга төштек тә, тегенең акыруына карамыйча, аяк-кулларын сөлге белән бәйләп, югарыдагы иптәшләр белән өстерәп чыгардык.

Акырды, тавышы бетте, һушы китте. Аннан, өстенә су сибеп, һушына китердек.

Берәр атна авырып ятты. Аннан терелеп чыкты. Усаллыгы кимемәде. Әмма казан бүлмәсенә биш сажинга якын килми торган булды.

чукмар — бер башы йомры кыска таяк; гадәттә, тимердән эшләнә
секрет — *монда:* машина
акыру — ямьсез тавыш белән кычкыру

Сораулар һәм бирем

1. Әптери агайны ни өчен «фабриканың язылмаган аяклы тарихы» дип йөртәләр?
2. Аны иптәшләре нинди сыйфатлары өчен ярата?
3. Приказчик Каганинның усаллыгы үзенә ничек кайта?
4. Хикәянең эчтәлеген сөйләгез.

Таҗи Гыйззәт

(1895—1955)

Күренекле драматург Таҗи Гыйззәт (Таҗи Кәлимулла улы Гыйззәтуллин) 1895 елның 15 сентябрендә Татарстанның Әгерҗе районы Барҗы Омга авылында крестьян гаиләсендә туа. Әтисе Кәлимулла абзый, ишле гаиләне туйдыру өчен, гомер буе батраклыкта йөреп, күп кыенлыклар күрсә дә, балаларына белем бирергә омтыла. Сигез яшендә Таҗи остабикәдән сабак ала, аннары мәдрәсәдә укый. Ул үзлегеннән дә күп укый, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксына. Шул чорда шигырьләр яза, авылдагы төрле гыйбрәтле вакыйгаларга багышлап, бәетләр чыгара.

1917 елда Таҗины Ижевск шәһәрендә оешкан һәвәскәр театр труппасына суфлер итеп чакыралар. Ул, суфлерлык эшеннән тыш, спектакльләрдә дә катнаша. Театр сәнгате, артистлык һөнәре аңа бик ошый. Армиядә хезмәт иткәндә, ул, драмтүгәрәк оештырып, гаскәри частьларда да спектакльләр куеп йөри. Ниһаять, аны Самара шәһәрендә ачылган татар драма студиясенә укырга җибәрәләр. Студияне тәмамлагач, Т. Гыйззәт Кәрим Тинчурин җитәкчелегендәге театр труппасы составында Оренбургта эшли. 1921 елгы ачлык вакытында труппа таралгач, Урта Азиянең мәгариф оешмаларында, аннары, Казанга килеп, Татар дәүләт академия театрында эшли.

Чирек гасыр буе театрда артист булып эшләү чорында Таҗи Гыйззәт дистәләрчә сәхнә образлары иҗат итә.

Шулай да ул татар театр сәнгате тарихында, иң беренче чиратта, сәхнә әсәрләре белән данлыклы.

Тажи Гыйззәтнең үзен драматург итеп таныткан беренче әсәре — «Талир тәңкә» исемле драмасы — 1922 елда языла. Бу әсәр Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела, тамашачылар аны яратып кабул итәләр. Соңыннан драматург әсәрнең исемен үзгәртә: ул «Чаткылар» дип атала башлый.

Беренче әсәренең уңыш казануы драматургка дәрт өсти. 1923 елда ул тарихи темага багышланган «Каһәрле мөһер» һәм 1925 елда «Наемщик» исемле пьесаларын яза. «Наемщик»ны автор 1928 елда үзгәртеп эшли. Салих Сәйдәшевнең гүзәл музыкасы белән сәхнәгә куелган бу вариант ике авторга да уңыш китерә.

Тажи Гыйззәт — татар театр сәнгатендәге беренче музыкаль комедия «Башмагым» либреттосының авторы. Бу әсәрне, Казан тамашачылары гына түгел, Киев, Харьков, Улан-Удэ, Ташкент, Сәмәрканд һәм башка шәһәрләрдә дә яратып кабул итәләр.

Тажи Гыйззәт — бай әдәби мирас калдырган язучы. Ул дүрт дистәгә якын сәхнә әсәре («Төнге сигнал», «Изге амәнәт», «Чын мәхәббәт», «Мактаулы заман» һ.б.) яза. Шуның өстенә, аның тәрҗемәләре, театр тарихына, аерым сәхнә эшлеклеләре иҗатына багышлап язылган тәнкыйть, публицистик мәкаләләре дә бар.

Хөкүмәт аның хезмәтен югары бәяли: ул ике тапкыр (1939, 1950) «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә. 1939 елда аңа Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, 1940 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Тажи Гыйззәт 1955 елның 7 мартында Казан шәһәрендә вафат була.

ИЗГЕ ӘМАНӘТ

(драмадан өзекләр)

КАТНАШУЧЫЛАР:

Гыйният Галимҗанов — күмер остасы.
Фуат — аларның улы, шахта мөдире.
Наҗия — аларның кызы.
Хәзинә — Гыйниятнең анасы.
Әбузәр — шахтада хуҗалык мөдире.
Асия — Әбузәрнең сеңлесе, Фуатның хатыны.
Лида — телеграфистка.
Шәйхи — шахтер.
Ганс — немец солдаты.
Розенбах — комендант ярдәмчесе.
Петраччио — Италия солдаты.
Лазареску — румын солдаты.
Остап — шахтер.
Һольцман — элекке шахта хуҗасы.
Мартынов — электротехник.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче күренешнең кыскача эчтәлеге:

Вакыйга Галимҗановлар фатирында бара. Донбассны немецлар басып алу куркынычы яный. Фуат гаиләсендә тылга китү өчен әзерлек башлана, әмма өлгерә алмыйча калалар, немецлар чигенү юлын кисә. Фуат әтисенә шахтаның планын һәм яңа ачылган участокның сызымнарын сакларга кушып китә. Моны Әбузәр ишетеп кала.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Галимҗаннар фатиры. Пәрдә ачылганда, кулына китап тотып, Хәзинә көйләп утыра. Асия кайтып керә.

Асия. Әткәйләр өйдә юкмы әллә?

Хәзинә. Юк шул... Үзем дә шул турыда ут йотып утырам... Иртән, полицайлар килеп, Наҗия белән икесен бергә алып киткәннәр иде, шуннан бирле кайтканнары юк... Син кичә тагын өйдә булмадың, кайда идең?

Асия. Караңгыда сезне уятып борчыйсым килмәде, абыйларга кереп кундым. Мин гомумән инде, дәү әни, сездән китәм.

Хәзинә. Китәсең, кая?

Асия. Яңа фатирга күчәм.

Хәзинә. Бездә урын тармыни?

Асия. Киресенчә, сездә шундый киң, шундый иркенлек... Җил-давылдан тынып калган дала шикелле, кайтып керсәң, җанны кая куярга урын тапмыйсың.

Хәзинә. Бу дөньялар һаман шулай бармас бит, үзгәрер әле. Сугыш бетәр, Фуатың кайтыр...

Асия. Юк, ул кайтмас инде.

Хәзинә. Каян беләсең?

Асия. Алар отрядыннан беркем дә калмаган.

Хәзинә. Кем әйтә?

Асия. Бар да шулай дип сөйлиләр.

Ганс керә.

Ганс. Капитан әфәнде сезне алырга җибәрде.

Хәзинә. Бу нинди мәхәббәтсез кеше?

Асия. Мине алырга килгән. Хуш, сау бул, дәү әни, әткәй белән Нәҗиягә әйтерсең. Мине гаепләмәсеннәр. Һәркем дөньяда үзенчә уйларга, үзенчә торырга тырыша бит.

Ганс *(ирониялe көлү белән)*. Исән бул, матька!

Китәләр.

Хәзинә *(тәрәзәдән карап кала)*. Әйе, тормышның астыөскә әйләнә, кешеләр, су өстендә йөзгән йомычкадай, төрле якка чайкала... *(Себерке алып идәнне себерә.)*

Нәҗия *(кайгылы хәлдә кайтып керә)*. Нинди хурлык, нинди түбәнлек...

Хәзинә. Тукта, кызым, сиңа ни булды?

Нәҗия. Биржада...

Хәзинә.Соң?

Нәҗия. Бөтен шәһәрдән җыелган кызларны залга чыгарып тезделәр дә сәламәтлегебезне барлау хәйләсе астында чишендереп карадылар...

Хәзинә. Мәккә кәферләре икән... Шуннан?

Нәҗия. Шуннан, төрлебезне төрле исемлеккә язып, мине бойнядa эшләргә билгеләделәр.

Хәзинә. Риза булмаска иде.

Нәҗия. Риза булмый нишлисең?! Шунда ук конвой белән лагерьга йә Германиягә озаталар.

Хәзинә. Бу нинди законсыз, миһербансыз кешеләр икән?! Атаң кайда калды соң, нигә кайтмады?

Н а җ и я. Без бит бергә булмадык, аны бүген комендатурага алып киттеләр.

Х ә з и н ә. Тагын ниләр күрәсебез бар икән... Синең ашыйсың килә торгандыр, хәзер чәй куям. *(Кухня ягына китә.)*

Н а җ и я *(битен кулы белән каплап, ишекле-түрле йөри).* Нишләргә, нишләргә соң миңа?..

Л и д а керә, Наҗия аңа ташлана.

Лидочка, бу син?!

Л и д а. Әйе, Надя, мин...

Кочаклашып үбешәләр.

Н а җ и я. Сөйлә тизрәк, син каян?

Л и д а. Киевтан.

Н а җ и я. Куптәнме?

Л и д а. Яңа гына.

Н а җ и я. Берәр эш беләнме?

Л и д а. Юк, торырга кайттым.

Н а җ и я. Торырга? Без моннан ничек качарга белмибез, син торырга дисең.

Л и д а. Зарар юк, акрынлап торырбыз әле. Тормыш бит ул үзе өйрәтә. Йә, сездә ниләр бар?

Н а җ и я. Әтине һәр көнне биржага чакырып эшкә чыгарга кысалар иде, бүген комендатурага алып киттеләр... Абый хәбәрсез югалды... Әнкәйне үтерделәр...

Л и д а. Нәрсә өчен?

Н а җ и я. Безнең күршедә эсесчылар тора. Моннан бишалты көн элек абзарыбызда сыерыбызны суеп ятканда өсләренә барып кергән. Эндәшмәскә кирәк иде аңар. Каравыл салып халык җыярга теләгән. Шул чагында капка төбендә атып үтерделәр. Син беләсеңме, Лида, мине бойняга эшләргә куйдылар...

Л и д а. Елама, Надя, синең ул зарлы нәфрәтләреңне күз яшьләре баса алмас. Мин беләм, син хискә бирелүчән, шагыйрә йөрәкле кыз, ләкин оккупация шартларында кичергән тормышыбыз хис белән түгел, акыл белән яшәүне таләп итә. Йөрәкләребездә кайнаган ачы нәфрәт тойгыларын көрәшкә файдаланыйк. Безнең мәктәптә бергә укыган иптәшләрдән биредә кемнәр бар?

Н а җ и я. Малайлардан беркем дә күренми. Катя Сорокина биржада кучерүче булып хезмәт итә. Аня Сидоренконы аттылар.

Лида. Ни өчен?

Нәҗия. Яралы командирны яшереп асраган.

Лида. Тагын?

Нәҗия. Луиза Янчевская румын офицерына кияүгә чыкты.

Гыйният кайтып керә.

Лида. Исәнмесез, Гыйният Галимҗанович.

Гыйният. Лидочка... Син укуда идең түгелме?

Лида. Әйе, шулай идем.

Гыйният. Димәк, син дә китә алмадың?

Лида. Юк, мине биредә эшләргә калдырдылар.

Гыйният. Биредә эшләргә?

Әбузәр керә.

Әбузәр. Исәнмесез?

Нәҗия. Лида, әйдә, урамда йөреп керәбез.

Лида. Хәзергә хушыгыз.

Нәҗия белән китәләр.

Әбузәр. Йә, кода, ни эшләр бетереп ятасыз?

Гыйният. Эшләр беткән, көлтә җыясы гына калды. Үзеңне котларга кирәк. Дәрәҗәгә менгәнсең икән.

Әбузәр. Нинди дәрәҗә?

Гыйният. Шәһәр идарәсенә тылмач булып кергәнсең түгелме?

Әбузәр. И кода, син аны куй әле, Әсфән яныннан бер кеше качып кайткан.

Гыйният. Ул исән?

Әбузәр. Әйе, пленга эләккән. Харьков янындагы лагерьда ята икән. Егетнең тормышы авыр, ди... Апасы, мескен, башын да күтәрми, елый да елый... Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, үземне бүген комендатурага чакырдылар.

Гыйният. Нәрсәгә?

Әбузәр. Фуат кияүнең сиңа биреп калдырган чертежларын сорыйлар.

Гыйният. Аның миңа чертеж калдырганын каян беләсең?

Әбузәр. Комендатурада шулай диделәр. Сез, имеш, кардәшләр икәнсез, бергә ашап, бергә эчкәнсез, әйтегез, юкса икегезне дә кулга алабыз, диләр. Нинди чертежлар иде соң ул, кода?

Гыйният. Белмим, минем андый чертежларны күргәнем юк.

Әбузәр. Алай булгач, нигә миннән сорыйлар?

Гыйният *(үз-үзенә)*. «Ярык юк димә бүрәнә өстендә, бүре юк димә бүрегең астында» икән.

Әбузәр *(аңламыйча)*. Ни дисең, кода?

Гыйният. Мин сине тылмач булып хезмәт итәсең икән дип ишеткән идем. Ләкин синең әле шпионлык һөнәрең дә бар икән.

Әбузәр. Мин шпион? Йа Алла!.. Кешеләргә яхшылык итим дисәң, яманлык булып кайта икән. Мин бит аны сезне кызганудан гына әйткән идем.

Гыйният. Сиңа үз-үзеңне кызганырга иде, юкса үлгән чагыңда авызыңа су салучың да табылмас. Бар, безнең өйгә аяк басасы булма!..

Хәзинә керә.

Әбузәр. Юк, басарбыз әле!.. *(Китә.)*

Хәзинә. Нигә җикеренә ул?

Гыйният. Фуат китәр алдыннан миңа аманәт итеп шахтаның генераль планын, антрацит участогының чертежларын калдырган иде. Ул аны ничектер сизгән. Шуны миннән юмалап алмакчы була. *(Яшергән җиреннән алып.)* Дөнья хәлен, әнкәй, белмәссең, минем белән әллә нәрсә булырга мөмкин, мин аларны сиңа тапшырам. Хәзер үк утта янмаслык, суда чыланмаслык җиргә урнаштыр.

Хәзинә. Ярый, улым, ярый, урнаштырырмын. Нигә чакырганнар?

Гыйният. Иртәгәдән эшкә чыгарга приказ бирделәр.

Хәзинә. Соң нишлисең?

Гыйният. Чыкмыйм, теләсә нишләсеннәр, чыкмыйм.

Остап керә. Хәзинә китә.

Әйдә, Остап Тимофеевич, бу көннәрдә күренмәдең, кайда идең?

Остап. Киров шахтасына кызымның хәлен белергә барган идем.

Гыйният. Соң, анда ниләр бар?

Остап. Точно бездәгечә, бөтен халык кайгы-хәсрәткә күмелгән... Килеп кергән көнне үк җиде кешене асканнар. Шулар арасында минем кияү дә булган... Чирле кызым өч бала белән ятим калган. Шуларны үз яныма кайтардым. Синең үз хәлең ничек соң?

Г ы й н и я т. Һаман искечә, һәр көнне биржага чакырып эшкә кушалар иде, бүген комендатурада шахтаны торгызырга приказ бирделәр.

О с т а п. Димәк, эшкә чыгасың?

Г ы й н и я т. Юк, мин бүген төнлә качам.

О с т а п. Кая?

Г ы й н и я т. Партизаннар отрядына. Миңа монда яшәргә калмады.

О с т а п. Ансы точно. Сиңа улың янына китәргә кирәк.

Г ы й н и я т. Ул исән?

О с т а п. Точно, менә сиңа аннан хат. *(Хат бирә.)*

Г ы й н и я т. Остап Тимофеевич!.. *(Кочаклап үбә.)* Моның өчен мин сиңа нинди генә сөенче бүләге бирим икән?

О с т а п. Берни дә кирәкми, анысы соңыннан.

Г ы й н и я т. Юк, юк, хәзер үк бирәм. Шатлык көненә дип саклап килгән сыем бар иде, шуны эчик әле... *(Аракы чыгара. Чашкаларга сала.)* Әйдә, тот, киләчәк җиңүебез өчен...

О с т а п. Точно!..

Ут сүнә.

эманәт — һичшиксез сакланырга яки тапшырылырга тиешле әйбер яки сүз

тылмач — тәрҗемәче

сөенче бүләге — сөенечле, шатлыклы хәбәрне беренче булып әйткән кешегә бирелә торган бүләк

Сораулар һәм биремнәр

1. Тылдагы халык дошманга каршы ничек көрәшә? Әсәрдәге образлардан мисаллар китереп сөйләгез.
2. Асия һәм Әбүзәр образларына характеристика бирегез. Аларны нинди тип персонажларга кертер идегез?
3. «Ярык юк димә бүрәнә өстендә, бүре юк димә бүрегең астында» сүзләре кем тарафыннан һәм нинди вакыйгага бәйләп әйтелә? Бу сүзләр халык авыз иҗатының кайсы жанрына карый?

БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Алдагы пәрдәләрнең һәм күренешләрнең кыскача эчтәлеге:

Дошманга каршы көрәшүчеләрнең күбесен кулга алалар, газаплыйлар, җәзалыйлар. Әсфанны һәм Лиданы җәзалап үтерәләр. Нажияне елдан артык кулда тоталар һәм ул, газаплауларга түзә алмыйча, акылдан яза. Гыйниятне дә бик нык газаплыйлар, соңыннан ул немецларга эшләргә сүз бирә, бу хәлгә Остап Тимофеевич бик гаҗәпләнә.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шахта эче — рудничный двор. Төрле якка китә торган вагонетка юллары. Арткы планның бер ягында водопровод будкасы, икенче якта электротрансформатор, уртада клеть. Бер читтә телефон будкасы. Ара-тирә әйбер күтәреп узалар. Еракта тимер-томыр тавышы, вагонеткалар авазы ишетелә. Пәрдә ачылганда, Лазареску белән Петраччио сакта тора.

Петраччио. Күңелсез, дустым Лазареску, күңелсез. Әгәр дә монда төнгә калырга туры килсә, акылдан шашарсың.

Лазареску. Без инде Россия белән чиктәш халык, русларны җиңгәннән соң, безгә өлеш тиячәк. Менә мин сезне аңламыйм. Өч-дүрт дәүләт аша монда килеп, нигә сугышып йөри торгансыздыр?!

Петраччио. Без, билгеле, бөек империя өчен сугышабыз. Муссолини белән Гитлер бөтен илләрне үзләренә буйсындырачаклар. Димәк, без, итальян сугышчылары да, табыштан, бәлки, мәхрүм булмабыз. Ә сез менә ни өчен сугышасыз? Сезгә бит барыбер бернинди өлеш тимәячәк.

Лазареску. Ә син үзең, Петраччио, рус җиренә килеп искиткеч баедыңмы? Ефрейтордан бүген ничә тапкыр йодрык алдың?

Петраччио *(кулын селтәп)*. Безнең кебек гади солдатларга шул инде ул. Туйдырды! Дөресен әйткәндә, Лазареску, бу җирдән башыңны тереләй алып китә алсаң, шуны зур бәхетең дип санарга кирәк. Белмим, ни белән бетәр бу сугыш. Хәтта биредә, тылда да, һәр минутта җаныңны алганнарын көтеп кенә тор.

Ганс керә.

Ганс. Нәрсә биредә такылдашасыз? Барыгыз урыннарыгызга!

Лазареску белән Петраччио китәләр. Гыйният керә. Телефонга бара.

Гыйният. Диффузорны бирегез. Остап Тимофеевичмы? Галимҗанов сөйли. Минем янга төшегез. Әйе, хәзер үк. *(Трубканы куя.)*

Ганс китә. Остап керә.

Остап. Нәрсә бар?

Гыйният. Хәзер генә мине комендант чакырган иде, Германиядән хуҗа килгән, бүген миннән шахтаны кабул итү тантанасы була, ди. Сиңа ничек кенә булса да «кочегарны» күрергә, безгә нишләргә икәнен белергә кирәк. Моннан да уңайлы чакның булуы мөмкин түгел, чөнки шәһәрдәге бөтен начальство монда булачак.

Остап. Ярый, мин киттем. *(Китә.)*

Хәзинә керә.

Хәзинә. Менә ул кая икән.

Гыйният. Әнкәй, син нишләп килергә булдың?

Хәзинә. Бер атнадан бирле кайтканың юк, сагындым, ашарга китердем. Әйдә, улым, җылы көйгә ашап ал.

Гыйният. Син, әнкәй, юкка минем өчен мәшәкатьләнеп йөрисең. Мине монда бик яхшы сыйлыйлар.

Хәзинә. Дөресен әйткәндә, улым, мин сиңа икенче эш белән килдем. Кичә безнең шәһәрдә бик зур вакыйга булды.

Ганс керә.

Нихәл син, сыбызгы.

Ганс. А, матька, сәлам!

Хәзинә. Син нишләп монда?

Ганс. Күрәсез, шахта саклыйбыз.

Хәзинә. Әллә кичәге пух-пухтан куркып төштегезме дигән идем.

Ганс. Безнеке пух-пухтан курыкмаган. *(Узып китә.)*

Гыйният. Шуннан, әнкәй?

Хәзинә. Нәрсә турында сөйли идем әле, улым?

Гыйният. Шәһәрдә булган ниндидер бер вакыйга турында.

Хәзинә. Әйе, төнге сәгать икеләрдә үзебезнекеләр килделәр. Берничә сәгать буена вокзал тирәсендә дөп тә дөп, дөп тә дөп итеп торды. Шулкадәр шатландык инде.

Гыйният. Әйе, яхшы шатлык... Ярый әле яныгызга төшмәгән.

Хәзинә. Яңадан килмәсләрме дип, яктырганчы сакладык, ләкин килмәделәр. Вокзалның бернәрсәсе калмаган, диләр. Бүген анда таба беркемне дә җибәрмиләр. Аннан бүген Шәйхи карт килгән иде. Ул әйтә: «Тиздән үзебезнекеләр киләр, улы Фуат кайтыр, Гыйниятькә әйт: эшләмәсен шуларга»,— ди. Чынлап та, улым, әле соң түгел, ташла син бу эшеңне.

Гыйният. Сез мине аңламыйсыз, әнкәй...

Хәзинә. Аңлыйбыз, бик яхшы аңлыйбыз. Төрмәдә сиңа авыр булгандыр, шуңар күрә вәгъдә биргәнсең. Хәзер берәр хәйлә тап, авыруга сабыш. Кара инде кыяфәтеңә, кырынмаган, атна буена юынмаган. Кабердән чыккан әрвахка охшыйсың.

Гыйният. Алган эшемне ахырына кадәр җиткерим. Аннан кырынырмын да, юынырмын да.

Хәзинә. Белмим, улым, белмим. Бу эшеңнең ахыры ни белән бетәр?!

Остап керә.

Гыйният. Йә, ничек?

Остап. Күрдем. Башларга куша. «Ләкин үзен саклап калу өчен кирәк булган чаралар күрелгәнме?» — ди.

Гыйният. Әйе, күрелгән. Газ дулкыны үтеп киткәнче чандагы суга чумам. Аннан иске шахта авызына киләм. Калганы сезнең иректә.

Остап. Ул турыда кайгырма. Бөтен нәрсә җайлап куелган.

Әбузәр керә.

Гыйният. Син бар урыныңа, бер генә минутка да телефоннан китмисең. Мин сиңа «зыбак», ягъни кабыз дип сигнал бирермен. *(Әбузәрне күреп, сүзне икенчегә бора.)* Вентиляциягез эшләми, газны начар куасыз.

Остап. Бездән эш сорарга беләсез, ләкин техника куркынычсызлыгын тәэмин итмисез! Әйдә әле, мин сиңа күрсәтим.

Гыйният. Күрмичә дә бик яхшы беләм.

Остап. Юк, штейгер әфәнде, син башта барып кара. Аннан мине ачуланырсың.

Китәләр.

Әбузәр. Нәрсә турында болар сөйлиләр? «Зыбак» — бу ни дигән сүз икән? Немецча да андый сүзне хәтерләмим, русча да ишеткәнем юк. Татарча да?! «Зыбак», «Тозак», «Йозак»...

һичбернәрсә төшенмим. Шулай да Остап Бондаренко белән серләшеп йөрүе нәрсәгәдер бәйләнгән, әйе, әйе, бу юкка түгел. *(Чан артына яшеренә.)*

Гыйният керә.

Гыйният. Ярый, эш бетте бугай, калды фәкать нәтиҗә...

Һольцман, Розенбах, Һерман, Ганс һәм башкалар керә.

Розенбах. Таныш булыгыз, безнең намуслы штейгерыбыз Гыйният әфәнде Галимҗанов.

Һольцман. А...

Гыйният. Мин сезне хәтерлим. Безнең әүвәлге хуҗабыз Һольцман әфәнде.

Һольцман. Аһа, ул мине онытмаган.

Гыйният. Сезне онытырга ярыймы соң?..

Розенбах. Әфәнделәр! Сезнең алдыгызда Гыйният әфәнде Галимҗанов. Башта ул да руслар шикелле үк безгә каршылык күрсәтте, ләкин кешеләрне дөрес тәрбия итү методыбыз аңар үз хатасын танырга мәҗбүр итте. Ул — хәзер безнең кеше. Гыйният әфәнде! Бөек Германия исеменнән рәхмәт әйтеп кулыгызны кысарга рөхсәт итегез.

Һольцман. Гыйният әфәнде, бәлки, сез дә бер-ике сүз әйтерсез.

Гыйният. Мин сүз сөйли белмим. Германия дәүләтенә ни дәрәҗәдә бирелгәнемне эшем белән күрсәтергә тырышырмын.

Розенбах. Алай булса, әйдәгез, безне антрацит участогы белән таныштырырсыз.

Гыйният. Сез бара торыгыз, мин диффузорга хәбәр итим. Бүген газны начар куалар.

Немецлар продолга кереп китәләр. Гыйният телефонга бара. Чан артыннан Әбузәр чыга.

Әбузәр. Син кая?

Гыйният. Диффузорга хәбәр итим, шахтада газ күбәйде.

Әбузәр. Син бар хуҗалар янына, мин үзем әйтермен.

Гыйният. Ә син нигә монда, нигә эшеңдә түгел?

Әбузәр. Синең нишләргә теләвеңне беләсем килә.

Гыйният кисәктән әйбер белән суга, Әбузәр егыла. Трубканы алып кычкыра.

Гыйният. Диффузор!.. Остап Тимофеевич, «зыбак», «зыбак», «зыбак», «зыбак»!!

Гыйният чанга чумарга бара, Әбузәр, торып, аңа ябыша. Ике арада көрәш китә.

Әбузәр. Әй халык, хыянәт, сакланыгыз, газ кипә!..

Ерактан шаулап газ килгәне ишетелә. Шашкан кыяфәттә немецлар йөгереп чыга.

Гыйният. Качмагыз, барыбер котыла алмассыз!..

Ут сүнә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук шахта төзелеше. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә дөм караңгы, еракта оркестр уйнаган матәм маршы ишетелә. Бераздан Шәйхи белән Остапның кармалашып килгәне күренә. Шәйхи кулында шахтерлар лампасы, Остап кулында телефон аппараты.

Остап. Шафееч, син кайда?

Шәйхи. Биредә! Әйдә тизрәк.

Остап. Күрмим, бернәрсә дә күрмим, точно.

Шәйхи. Әллә синдә тавык күзе инде.

Остап. Булыр да. Ике ел немец шулпасы эчтек бит. Тавык күзен ит ашамаудан була диләр. Көч тә, гайрәт тә бар икән үзебездә. Немецның мактаулы техникасын лепешкага әйләндерделәр, точно.

Шәйхи. Без ниндидер бушлыкка килеп чыктык.

Остап. Бу рудничный двор булырга кирәк, точно.

Шәйхи. Әйе, менә электр будкасы.

Остап. Менә кран, точно. Ул чан тирәсендәрәк булырга тиеш.

Шәйхи. Тукта. Аяк астында нидер бар. Әйе, менә алар.

Остап. Бусы кем?

Шәйхи. Әбузәр хаин.

Остап. Димәк, Гыйнияткә чанга чумарга ул ирек бирмәгән.

Шәйхи. Өскә хәбәр ит, төшсеннәр.

Остап. Алло, алло, рудничный двор. Мәетне таптык. Прожекторлар белән төшегез.

Шәйхи. Их, Гыйният, Гыйният! Бу көннәрне күрү сиңа насыйп булмады.

Остап. Бездә аның эше калды, даны калды, Шафееч!

Прожекторлар белән керәләр, сәхнә яктыра, халык җыела.

Шәйхи. Юл бирегез, майор килә!

Халык ике якка аерыла. Фуат белән Мартынов һәм гаскәрләр керә.

Остап. Фуат Гыйниятович, менә ул!

Фуат. Максим Савельевич, бу фаҗига нишләп болай булды соң? Ул үлемгә үзе теләп бардымы?

Мартынов. Төрмәдән чыкканда, чынлап та ул шундый теләктә иде. Немецлар белән бергә үзен дә һәлак итү уенда иде. Мин аңар андый адымны атларга ярамаганны, дошманнан үчне алып та, исән калырга мөмкинлеген өйрәттем. Ул минем тәкъдимгә күнде. Ярдәмгә Остап Тимофеевичны бирдек. Алар икәүләп эшкә керештеләр. Без, аның исән калуы өчен, бөтен чараларны булдырган идек. Күрәсең, планыбызны Әбузәр хаин сизеп алган да аңар чанга чумарга ирек бирмәгән. Шулай итеп меңгә якын фашист һәм хаиннәр белән үзе дә һәлак булган.

Фуат. Их, әткәй, әткәй! Күпме газап, авырлыклар күрдең син...

Остап. Юл бирегез, анасы килә!..

Үзен мәгърур рәвештә тотып, вәкарь белән атлап, Хәзинә керә. Гыйният янына тезләнә.

Хәзинә. И улым, улым...
Андый яшерен-изге уең булгач,
Ник соң аны миңа әйтмәдең?..
Бирер идем сүзсез фатихамны,
Ачкан булсаң миңа теләгең...
Улым, Фуат!
Мә, ал эманәтең,
Изге санап, аны сакладык *(план, чертежларны тапшыра).*
Илгә булган тирән мәхәббәтне
Зур корбаннар биреп акладык.
Сорыйм синнән, шулар хөрмәтенә,
Минем алда хәзер тез чүгеп,
Сүзеңне бир, бәбкәм, үч алырга...

Фуат. Һәлак булган атам һәм анамның
Үлемнәре белән ант итәм:
Туган илем, бөек халкым өчен
Үч алырга тагын мин китәм.

Гыйниятнең гәүдәсен, носилкага салып, күтәреп китәләр. Музыка көчәйгәннән-көчәя бара.

Пәрдә.

такылдау — күп сөйләү
әрвах — үлгән кеше
фәкать — тик
шашкан — ярсыган, котырынган
кармалашып — капшанып
фатиха — ананың ризалыгы, изге теләге

Сораулар һәм биремнәр

1. Гыйният образы турында сөйләгез. Ул сездә нинди тәэсир калдырды?
2. Хәзинә кем ул? Аның эшчәнлеге турында нәрсәләр беләсез?
3. Драмада нинди әманәт турында сүз бара? Автор ни өчен әсәрен «Изге әманәт» дип атаган?
4. Уңай һәм тискәре образларны әйтегез. Ни өчен шулай уйлавыгызны аңлатыгыз.
5. Нәрсә ул драма? Тагын кайсы драматургларның әсәрләрен укыганыгыз бар?
6. Әсәрне тулысынча укыгыз.

Фатыйма Ильская

(1902—1984)

Татарстан Республикасының һәм РСФСРның халык артисты Фатыйма Ильская (Фатыйма Салих кызы Хуҗасәетова) 1902 елда Оренбург шәһәрендә дөньяга килә. Берничә ай үтүгә, Фатыйманың әтисе Салих ага үлеп китә. Озакламый әнисе дә дөнья куя. Фатыйма әбисе белән бабасы тәрбиясендә үсә.

Аның бала чагы халык тарафыннан макталып җырлана торган ямьле Җаек һәм Сакмар елгалары уртасында урнашкан Оренбург шәһәрендә үтә.

Ятимә калган Фатыйманы бабасы, кул эшләре белән бергә, укырга-язарга да өйрәтә. Укуын тәмамлагач, Фатыйма фабрикада эшли, кичләрен «Халык йорты» бинасында куелган спектакльләргә йөри.

Бервакыт мондый хәл була: 1915 елның 20 апреленә игълан ителгән спектакльдә уйнарга тиешле туташ көтмәгәндә шәһәрдән китә. Театр труппасы кыен хәлдә кала. Спектакль өзелү алдында тора. Артистларның берсе спектакльне бирелеп карап утырган Фатыйманы күреп ала һәм аны үзләренең труппасына чакыра. Кыз риза була. Инде икенче көнне пьесада уйнарга әзерлек башлана.

Аның беренче уйнаган рольләрен күреп, язучы Шәриф Камал: «Татар сәхнәсенең зур артисткасы булырга тырыш»,— дип, кызны канатландыра. Унөч яшьлек бу кызның сәләте театр җитәкчеләрен дә, артистларны да, тамашачыларны да битараф калдырмый. Аның шөһрәте Казан шәһәренә дә килеп җитә. Бу турыда ишеткән Габдулла Кариев белән

Кәрим Тинчурин Фатыйма Хуҗасәетованы Казанга чакыралар.

«Сәйяр» труппасының бу тәкъдиме Фатыйманы уйга калдыра. «Татар дөньясында дан казанган труппа составында мәшһүр артистлар... Кариев, Тинчурин, Солтанов кебек исемнәр генә дә ни тора! Алар арасында югалып калмаммы?.. Кире борып җибәрмәсләрме?»

Ниһаять, 1916 елгы сезонда ул Казан тамашачылары каршына чыга. Казанда Фатыйма, Габдулла Кариев тәкъдиме белән, ил кызы мәгънәсенә туры китереп, Ильская фамилиясен ала.

Берсеннән-берсе оста иҗат ителгән образлары белән Фатыйма Ильская сәнгать эшчәнлегендә гаҗәеп талантлы икәнлеген күрсәтә. Татар, рус һәм Көнбатыш классикасы әсәрләрендә баш рольләрне зур осталык белән башкара, онытылмас образлар иҗат итә. Шуларның иң уңышлылары сыйфатында мондый рольләрне санарга мөмкин: Әкълимә (Һ. Такташ. «Җир уллары трагедиясе»), Дилбәр (К. Тинчурин. «Җилкәнсезләр»), Зөһрә (Н. Исәнбәт. «Һиҗрәт»), Айсылу (Т. Гыйззәт. «Ташкыннар»), Гөләндәм (Т. Гыйззәт. «Чын мәхәббәт»), Фатыйма (М. Әмир. «Тормыш җыры») һ. б.

Фатыйма ханым Ильская спектакльләргә бик нык әзерләнә. Ул иң элек әсәр белән яхшылап таныша. Аннан үзенә тапшырылган рольне өйрәнүгә күчә. Драматург тарафыннан образга нинди бурыч тапшырылганын, образның әсәрдә барган вакыйгада тоткан урынын, характерын ачыклый. Әнә шулай даими эзләнү, иҗади тынгысызлык Фатыйма Ильскаяга зур уңышлар китерә. Ул, 65 еллык сәхнә эшчәнлегендә 400 гә якын рольдә уйнап, онытылмас образлар иҗат итә.

Татар театры сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Фатыйма Ильскаяга 1939 елда Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исем бирелә, ә 1967 елда ул РСФСРның халык артисты дигән исемгә лаек була.

Фатыйма Ильская 1984 елда Казан шәһәрендә вафат була.

Ш. Рахманкуловтан

Сораулар һәм бирем

1. Фатыйма Ильскаяның артист булып китүенә нинди вакыйга сәбәп була, сез моны очраклылык дип уйлыйсызмы? Ни өчен?
2. Фатыйма Ильскаяның иҗаты турында сөйләгез.

Гөлсем Камская

(1901—1975)

Татарстан Республикасының — халык, РСФСРның атказанган артисты Гөлсем Камская (Гөлсем Сәйфулла кызы Камская) 1901 елда Казан шәһәрендә туа.

Кырыс һәм киеренке гражданнар сугышы елларында 18 яшьлек укытучы кыз үзе теләп фронтка китә һәм шунда артист булып йөри. Спектакль һәм концертларны төрле урыннарда куярга туры килә: тылда да, фронтта да. Сугышчылар татар артистларының чыгышларын зур кызыксыну белән кабул итәләр. Нәкъ шушы чорда Гөлсем халык тормышында театрның зур әһәмияткә ия икәнлеген аңлый һәм үзенең бөтен тормышын шул хезмәткә багышларга уйлый.

1922 елның 8 ноябрендә Казанда беренче дәүләт театры ачыла.

1922—1926 елларда Гөлсем Камская Татар дәүләт академия театрында эшли. Беренче чыгышларыннан соң ук театрны Камскаядан башка күз алдына китерү мөмкин булмый. Бернинди махсус белеме булмаган кыз ничек тиз арада зур уңыш казанып, популяр булып китә алган соң?

Камскаяның табигатьтән килгән таланты тамашачыларны табигыйлеге һәм гаҗәп гадилеге белән таң калдыра. Ул сәхнәдә үзе тудырган образларны чын сәнгатьчә сизгерлек, нечкә зәвык белән тирән итеп ачып бирә ала.

Гөлсем Камскаяның таланты үсүгә Кәрим Тинчурин, Зәйни Солтанов, Касыйм Шамил, Фатыйма Ильская, Хәлил Әбҗәлилов, Гөлсем Болгарская, Ширияздан Сарымсаков кебек күренекле режиссер һәм артистларның тәэсире көчле

була. Үз чиратында Гөлсем Камская яшь буын артистлар иҗатына да зур йогынты ясый.

Ул 1927—1933 елларда Мәскәү эшче театрында эшли. 1933 елдан 1962 елга кадәр Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында иҗат итә. Театр сәхнәсендә 50 еллап эшләү дәверендә, Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар» трилогиясендә Гөлниса, Галимҗан Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми?» әсәрендә Сабира, Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясендә Нәсимә һәм башка бик күп рольләр белән бергә, рус драматурглары әсәрләрендәге образларны да бик уңышлы башкара.

Хөкүмәтебез аның хезмәтен югары бәяли. 1951 елда аңа Татарстанның халык, 1957 елда РСФСРның атказанган артисты исемнәре бирелә.

Гөлсем Камская 1975 елда Казан шәһәрендә вафат була.

Халит Кумысниковтан

Сораулар һәм бирем

1. Гөлсем Камскаяның театр сәнгатенә килү сәбәпләре нәрсәдә?
2. Аның иҗаты үсүгә кемнәр ярдәм итә? Ул шәхесләр турында сез нәрсәләр беләсез?
3. Татар театр сәнгатендә Гөлсем Камскаяның тоткан урыны турында сөйләгез.

«Театр» темасына сөйләшү өчен сораулар[1]

1. *Театр* һәм *спектакль* сүзләренең мәгънәләрен сез ничек аңлыйсыз?
2. Татарстанда (яисә сез яшәгән өлкәдә) нинди театрлар бар?
3. Татар театры тарихы турында нәрсәләр беләсез?
4. Хәзерге вакытта сезгә кайсы театр күбрәк ошый? Ни өчен?
5. Сезнең нинди спектакльләр караганыгыз бар? Үзегезгә ошаган бер спектакль турында сөйләгез.
6. Хәзерге көндә татар театры сәхнәсендә уңыш казанган артистлардан кемнәрне беләсез? Аларның кайсы рольләре турында сөйләр идегез?
7. Театрда спектакльне әзерләүдә артистлардан тыш тагын кемнәр катнаша?

---

[1] Сорауларга җавап биргәндә, кереш сүз һәм кереш җөмләләрдән, *әйе*, *юк* сүзләреннән, аерымланган кисәкләрдән файдаланырга тырышыгыз.

Шәриф Еникеев
(1911—1986)

Язучы Шәриф Еникеев (Шәриф Кәлимулла улы Еникеев) 1911 елның 8 августында Башкортстан Республикасының Благовар районы Каргалы авылында крестьян гаиләсендә туа.

Шәриф 15 яшендә, авырып, сукыр кала. Казан сукырлар мәктәбендә укый. Анда Брайль алфавитын өйрәнә. 1930 елда татрабфакка укырга керә. Рабфак директоры Шәрифнең укый алуына шик белдерә. Шунлыктан аны шартлы рәвештә генә кабул итәләр. Әмма Шәриф укуда югалып калмый. 1934 елда рабфакны уңышлы тәмамлап чыга. Аннары Казан дәүләт педагогия институтының тарих факультетында укый. Студент чагында ук сукырлар арасында наданлыкны бетерү курсларында дәресләр бирә. 1938 елда институтны тәмамлагач, Казан шәһәре мәктәпләрендә тарих укыта.

Утыз елга якын Татарстан китап нәшриятында сукырлар әдәбияты бүлегендә редактор булып эшли, сукырлар өчен дәреслекләр язып бастыра.

Шәриф бала чагыннан ук әдәбиятка гашыйк кеше була, үзе дә хикәяләр, повестьлар яза. Язучының беренче зур әдәби әсәре — «Солтангәрәйнең язмышы» повесте. Бу повестьта якты дөньяны күрү бәхетеннән мәхрүм булган сукыр кешеләрнең авыр тормышы сурәтләнә. Автор унике яшеннән сукыр калган Солтангәрәйнең авылдан авылга, шәһәр «баз»ларында иза чигеп йөрүләрен зур осталык белән, нечкә психологик алымнар белән тасвирлый.

1984 елда Шәриф Еникеевнең «Тормышка гашыйклар» исемле повесте дөнья күрә. Дәһшәтле сугыш елларында авыл

яшьләренең тылдагы батырлыклары, характер ныклыгы, мәхәббәткә тугры булып калулары сурәтләнгән бу әсәрне дә укучылар яратып кабул итә.

Шәриф Еникеев 1986 елның 12 декабрендә Казан шәһәрендә вафат була.

СОЛТАНГӘРӘЙНЕҢ ЯЗМЫШЫ

(өзекләр)

Беренче бүлек

1

Әле яңа таң беленеп килә. Йокының иң тәмле чагы. Андый вакытта берәрсе килеп уятса, шундый ачу чыга, шундый җан үртәлә — балдай татлы йокыдан аерырга азапланган ул кешене шундук бәреп үтерәсе килә. Һай, бигрәк тә тәмле була шул иртәнге йокы!

Кемдер Солтангәрәйнең өстеннән ябынгычын тартып алды да, колак төбендә генә ачу китергеч пышылдап:

— Тор инде, улым, тор,— диде.

Кая ул тору! Җылы тәнендә этисенең каты кулын тоеп, аның пышылдавык тавышын ишеткәч тә, Солтангәрәйнең тагын да ныграк бөркәнәсе, йомшак, җылы мендәргә тагын да ныграк чумасы килде, һәм ул, ачылган өстен ябып куймакчы булып, йокы аралаш ябынгычын кулы белән капшап карады. Юк, ябынгыч каядыр читкә алып ташланган. Солтангәрәй аз гына вакытка сул як ботының туңа башлавын тойды, аннары яңадан рәхәт йокыга чумды.

Ләкин бераздан колак төбендә этисенең:

— Кара, син әле һаман тормадыңмыни? — дигән сүзләре яңгырап китте.

Ул инде тышка чыгып юынып кергән иде. Аның тәмам йокысы качкан һәм шуңа күрә тавышы бик ачык булып ишетелә. «Их, тагын әз генә черем итеп алырга!» — дип уйлады малай, күзләрен ачасы килмичә.

— Я, кемгә әйттем мин?! — диде этисе, сабырлыгын җуеп.

Солтангәрәй, ниһаять, теләр-теләмәс кенә аягына басты, әле һаман йокысыннан арына алмыйча, борынын сызгыртып, күзләрен угалап торды-торды да тәмам айнып җитте.

— Бар, тышка чык, юынып кер,— диде этисе, баягыга караганда йомшаграк итеп.

Солтангәрәй, берни әйтмичә, ишегалдына чыкты. Чыкса, дөнья шундый якты, шундый матур! Кайдадыр якында гына чыпчыклар чыркылдаша, сандугач сайрый, авылның әле бер төшендә, әле икенче төшендә әтәчләр кычкыра, һава салкынча. Ә көнчыгыш якта сызылып кояш чыгып килә.

Малайның күңелен шатлык хисе биләп алды. Күк читенә җәелгән алсу нурларга, еракта, авыл читендә зәңгәрләнеп күренгән калкулыкларга аның бик озак карап торасы килде, һәм ул әле генә берни белми йоклап ятуы өчен, шушы алсу таңны күрмичә, сандугачлар, әтәчләр тавышын ишетмичә йоклап ятуы өчен чын күңелдән үкенеп куйды.

— Әти, кояш чыга, кояш чыга! — дип кычкырды ул, кире өйгә кереп.

— Чыккан, улым, чыккан,— диде әтисе, аның белән килешеп.— Әйдә тизрәк. Әнә теге йомрыдагы сөтне генә эч тә... Икмәк юк. Бүген Сәхипҗамал әбиеңнәргә керәбез. Аларның үзләренә дә юк инде, бичараларның... Иртәнгене ашап тормабыз.

Ул инде киенеп куйган: аягында — чабата, өстендә — кырык ямаулы иске бишмәт, башында — каешланып беткән кара кәләпүш.

Солтангәрәй өсте утырган җылымса сөтне аяк өсте генә эчте дә, идәнгә утырып, тиз-тиз генә яңа чабатасын киеп алды. Башына әтисенеке кебек кәләпүш, өстенә бишмәтен киде. Аннары әтисе чөйдә эленеп торган үрүле букчаны, корымланып беткән кулказанны алды. Чыбыркылар чоланда иде. Алар ишекләрен бикләнми торган ватык йозак белән генә элдереп куйдылар да урамга чыктылар.

Ә бераздан, иртәнге тынлыкны бозып, авылның Утрау як дип йөртелә торган очыннан сузып-сузып кычкырткан быргы тавышы — моңсу көтүче тавышы ишетелде.

3

Менә болынга да барып җиттеләр. Сыерлар, мыш-мыш килеп, кыштыр-кыштыр итеп, баш калкытмый ашарга тотындылар.

Батыргәрәй абзый үзе белән алып килгән әйберләрен улына калдырды да авылга кайтып китте.

— Төшкә кадәр килеп җитәрмен. Шулай да күз-колак бул, таралыша күрмәсеннәр,— диде ул киткәндә, Солтангәрәйне кисәтеп.

— Хәзер аларны моннан куаласаң да җибәрә алмассың инде,— диде малай.

Әтисе китеп бераз вакыт узгач, ул көтү алдына чыкты да җиргә сузылып ятты. Сузылып ятты да Сәхипҗамал әби биргән көлчәләрне тәмләп-тәмләп ашарга кереште.

Чыгы да кибеп бетмәгән дымлы куе үләнгә күмелеп күккә карап яту нинди рәхәт! Беркем кычкырмый, беркем тиргәми, кайгы юк, хәсрәт юк. Тирә-якта чикерткәләр черелди, кошлар сайрый. Әкрен искән җилгә үлән сабаклары, алсу, зәңгәр, ап-ак чәчәкләр тирбәлә. Кайчакта үлән сабагыннан биткә берәр каты корт егылып төшә, егылып төшә дә, тәнне кытыклап, колак артына яисә яка арасына таба йөгереп китә. Ә зәп-зәңгәр күк йөзе нинди гүзәл, нинди төпсез! Җил уңаена әкрен генә ак болытлар агыла, аларның кайберләре ала-кола сыер тиреләре кебек, ә кайберләре бөдрә йонлы ап-ак сарыклар шикелле. Кая агылалар икән алар? Каян килеп чыгалар икән? Нинди киң бу күк йөзе! Үзе каплап куелган табак кебек. Болында булсаң да, авылда булсаң да — кайда гына булсаң да, һаман шул бер үк зурлыкта, һаман шул бер үк табак кебек. Нәкъ баш очында гына. Кайда икән аның чите? Моннан торып караганда, ул табакның чите авыл турысында кебек, ә авылга кайтсаң, киресенчә, болын ягы читтә торып кала. Ник алай икән соң ул? Бу турыда әтисе дә белми, беркем дә белми. Сорадың исә: «Аллаһы Тәгалә шулай яраткан»,— дип кенә җавап бирәләр.

Шулай төрле нәрсә турында уйланып ята торгач, Солтангәрәй үзенең йоклап киткәнен сизми дә калды. Ул тәмам онытылып йоклады, төш тә күрмәде, саташмады да.

Бер заман ул бик нык кояш кыздырганын тойгандай булды һәм искәрмәстән уянып китте. Уянып китсә, малайның коты очты. Кояш төшлеккә якынлашып килә иде, ә тирә-якта көтү дә, әтисе дә юк. Ул тиз генә сикереп торды да кулына чыбыркысын алды.

Шул чакны аның колагына бик еракта, елга буендагы әрәмәлек янында, зәгыйфь кенә кыңгырау тавышы чалынып китте. Аңа бераз җан кергәндәй булды, ләкин шулай да ул тиз генә тынычлана алмады. Җәйге челләдә әрәмәгә таралышкан көтүне бергә туплау никадәр авыр икәнлеген ул, билгеле, бик яхшы белә иде.

Малай, чыбыркысын өстерәп, әрәмә ягына йөгерде. Көтү чыннан да шунда булып чыкты. Сыерларның кайсы әлсерәп

куаклар арасында ята, кайсы койрыгы белән селтәнеп тора, кайсы агачка ышкына, ә кайберсе, чебен, кигәвенгә түзә алмыйча, үртәлеп, аягы белән корсак астын кашып азаплана иде.

Солтангәрәй, качак сыерларга ачуланып, кычкырынгалап алды, чыбыркысын шартлатты һәм, бер җиргәрәк җыярга теләп, әрәмәнең бер төшеннән икенче төшенә чабып йөрде. Йөгерә-йөгерә алҗып бетте. Шулай да бер ярты сәгатьтән көтүне елга буена, күләгәлерәк һәм ачыграк бер урынга туплый алды.

Сыерлар тынычлана төштеләр, бер җиргәрәк өелештеләр дә гөрселдәп җиргә аудылар һәм, әкрен генә күшәп, йокымсырап ята башладылар. Кайберәүләре күбенгәнче су эчте, әлсерәгәнрәкләре исә, зур корсакларын суга тидереп, шул көе елга эчендә торып калды.

Солтангәрәй аерата усал сыерларны барларга кереште.

— Ала Мүкләк... Хәбри танасы... Сынык Мөгез...— диде ул, сыерларны кушаматлары белән атап.

Ә кара сыер кайда? Итче Хәсәннең юньсез сыеры кайда? Малайның йөрәге жу итеп китте. Их, сизенгән иде аны! Юньсез булуы өстенә, ул бит әле көтүгә ныклап ияләшеп тә җитмәгән — гел каядыр качу ягын гына, көтүдән аерылып китү ягын гына карый. Итче Хәсән болай да аларны тотып ашардай булып тора, Бәдәре тагын әллә нәрсәләр сөйләнеп калды. Ах Аллакаем, нишләргә инде? Моның өчен әти үтерә бит инде мине!

Куркуыннан коелып төшкән малай шулай дип уйлады һәм, яңадан йөгергәләп, әрәмә арасыннан эзләргә кереште. Елга янындагы әрәмәне актарып чыккач, ул якын-тирәдәге чокыр-чакыр араларын карады. Аннары, елый-елый, бер чакрым чамасы ераклыктагы калкулыкка таба йөгерде. Калкулык өстенә менде дә икенче яктагы болыннарга, әрәмә араларына күз ташлады. Ләкин кара сыер беркайда да күренмәде.

Солтангәрәй, кая барып бәрелергә белмичә, инде көтүгә таба чапты. Бер-ике мәртәбә озын сабаклы үләннәргә абынып, уралып егылып алды, әрәмәдә, гөлҗимеш куагына эләктереп, күлмәк җиңен ерттырды, кулын тырнатты. Күзләреннән яшь акты, кулыннан, беләгеннән кызыл кан бәреп чыкты. Әмма ул бернигә дә игътибар итмәде. Аның бөтен күңелен, бөтен тойгыларын шул каһәр төшкән кара сыер биләп алды. «Әтигә нәрсә диярмен инде? Үтерә бит инде ул мине моның өчен!» — дип такмаклады ул бертуктаусыз үзалдына.

Солтангәрәй яңадан көтү янына якынлашып килгәндә, Батыргәрәй абзый күренде. Кулына икмәк белән беркадәр бәрәңге, өч-дүрт күкәй тоткан. Ул бик канәгать күренә иде; күрәсең, авылга кайтып, аның юлы бик уңгандыр.

Аны күргәч, куркуыннан Солтангәрәй хәтта елаудан да туктады.

(Сыерны таба алмыйлар. Бу форсаттан итче Хәсән оста файдалана, чөнки Батыргәрәй абзый белән аның арасында күптәннән дошманлык яшәп килә. Ул менә хәзер Батыргәрәй абзыйдан үч алмакчы була. Сыерны табып суя да итен сата. Ә Батыргәрәй абзый белән Солтангәрәйне бик каты кыйнатa. Ниһаять, Солтангәрәйнең әтисе үлә, малай сукыр кала. Һәм аның өчен гаҗәеп газаплы тормыш башлана.)[1]

җан уртәлү — күңел сыкрау, борчылу
черем итеп алу — аз гына йоклап алу
көлчә — кабартма

Сораулар һәм биремнәр

1. Әсәр ничек башланып китә? Солтангәрәйнең хәләтен аңлатыгыз.
2. Иртәнге табигать күренеше тасвирланган урыннарны кабат укыгыз. Автор мондый манзараны ни өчен бирә дип уйлыйсыз?
3. Сезнең кояш чыккан вакытны күзәткәнегез бармы? Булса, бу күренеш автор сурәтләвенә тәңгәл киләме? Шул турыда сөйләгез.
4. Көтүдә Солтангәрәй белән нинди вакыйга була? Шушы хәлләрдән соң малайның тормышы ничек үзгәрә?
5. Әтисе нинди язмышка дучар була?

Икенче бүлек

9

Ул авылдан авылга йөрде. Берсенең тәрәзә каршына килде, икенчесенең өенә үк керде, кызганыч тавыш белән «Алла хакы өчен сукыр ятим балага» ярдәм итүләрен сорады. Кайберсе капчыгына берәр телем икмәк, кайберсе бер-ике бәрәңге салды, кайсылары хәтта чәй эчереп, тамагын туйдырып чыгардылар. Чакырсалар керде, кусалар китте. Аның бөтен ва-

---

[1] Бүлекләр ахырында җәя эчендәге сүзләр дәреслек авторлары тарафыннан бирелде.

кыты юлда узды. Нинди дә булса берәр авылда төн кунды да, озак тоткарланып тормыйча, икенче авылга чыгып китте. Кайчакларда аңа кыр-басуда кунарга туры килде. Якында гына берәр ышык урын — кибәнме, куаклыкмы булганда бик яхшы иде, ләкин кайвакыт анысы да булмады — арып-алҗып, ул шунда юл читенә чыкты да, песи кебек бөгәрләнеп, җир өстенә ятты да йоклады.

Шулай итеп, вакытында җылы аш, башын терәргә мендәрястык күрмичә һәм эченә җыелган кайгы-сагышын сөйләргә якын иптәш тапмыйча, кешедән калган иске-москыга төренеп, кешедән калган телем белән, каты-коты белән тукланып, Солтангәрәйнең айлары, еллары узды.

Дөрес, язгы-җәйге айларда алай бик үк зарланырлык булмый, әмма салкын көз, көз артыннан карлы кыш җиттеме — аның өчен чын-чынлап газап башлана иде. Ә бервакыт ул чак-чак кына туңып үлми калды.

Кыш урталары иде, төкерек җиргә төшмәслек суык. Бу вакытта юлга чыгу турында уйларлык та түгел, һәм ул Салабаш дигән бер авылда атна-ун көн чамасы тоткарланырга мәҗбүр булды. Капчыгында сынык-саныклар бар иде, алары бетсә, беркадәр акчасы да бар. Йорт хуҗасы Лотфулла карт исә ифрат киң күңелле кеше булып чыкты. Беркая да ашыкма, диде, мондый салкында яхшы адәм этен дә куалап чыгармый — тынычлап ят, диде. Теләсәң, хәтта язга кадәр торырга була, өй иркен, ашарга икмәк бар, диде.

Мондый сүзләрне Солтангәрәйгә бик еш ишетергә туры килми иде.

«Әллә чынлап та көннәр җылытканчы калыйм микән? Лотфулла бабайга чабата ясарга булышырмын, вак-төяк эшләрен башкарырмын. Минем бит беркая ашыгасым юк»,— дип уйлады ул. Һәм Солтангәрәй киң күңелле бу карт йортында торып калды. Бабай белән алар бик тиз уртак тел таптылар. Солтангәрәй аңа кулыннан килгәнчә чабата ясарга булышты, үзенең башыннан кичкәннәрне сөйләде.

Ләкин ул арада көнне сындыргандай итте. Җанны кыя торган, үзәкләргә үтә торган суык йомшый төште. Кичләрен морҗалардан чыккан төтеннәр көнчыгыш якка авыштылар, урамнарда чана шуган бала-чагалар күренде, тәрәзә бозлары эри башлады. Ә беркөнне иртән күктән иренеп кенә берән-сәрән кар бөртекләре сибелде. Көн җылыну белән кешеләрнең күңелләре дә күтәрелеп китте.

Солтангәрәй инде юл йөрүгә күнегеп беткән иде. Хуҗа кешеләр никадәр ягымлы, торган җире никадәр җылы булмасын, шулай да ул монда үзен кыен сизә башлады. Аның күңеле каядыр читкә омтылды. Беркөнне иртән ул күршедәге Кичү авылына чыгып китәргә исәбе барлыгын әйтте һәм шундук киенергә тотынды.

— Үзең беләсең инде, улым,— диде кунакчыл карт.— Мин сине тота алмыйм. Тик шулай да тагын бер-ике көн кунасыңмы әллә? Көн җилләп тора, буран чыгуы бар.

Бер тәвәккәлләгәч, Солтангәрәйнең кире чигенәсе килмәде. Хуҗаларга рәхмәт әйтте дә кулына таягын алды, торкага тотынды.

Яңадан юлга чыккач, кыр-ялан уртасында ялгызы гына калгач, ул үзен ниндидер тоткыннан котылган кебек хис итте. Үзенең кайгыларын да, шатлык-куанычларын да ул бары үзе генә кичерергә, бөтен вакытын үзе генә уйланып уздырырга гадәтләнгән иде. Шуңа күрә бер өйдә, бер үк кешеләр белән ун көн чамасы тору аңа чын-чынлап тоткынлык булып тоелды.

Күрше авылга бара торган бердәнбер юл такыр, тигез. Адашырмын дип, икенче юл белән кереп китәрмен дип куркырлык түгел. Ул мәсьәләгә килгәндә, кышкы юлдан да яхшысы юк. Тик менә я алдан, я арттан килгән атларны уздырып җибәрү өчен генә читкә чыгарга кирәк, читкә чыктың исә, тула оек эченә кар керә. Анысы инде бигрәк тә яман.

Салкынча һаваны сулавы шундый рәхәт. Аяклар үзләреннән-үзләре атлый сыман. Чынлап та, нинди күңелсез икән бу бер урында яту. Язга кадәр торырга, ди. Язга кадәр калсаң, саргаеп үләрсең анда.

Шулай уйлана-уйлана, Солтангәрәй һаман алга атлый, ашыга, чаба, әйтерсең аны кемдер арттан этеп бара. Хәер, чынлап та, аны арттан җил этеп алып бара. Авылдан чыкканда, Солтангәрәй моңа бөтенләй игътибар итмәде, ләкин берике чакрым чамасы җир үткәч, җил үзен сиздерә башлады, чөнки хәзер ул аның сул ягыннан исә иде.

Япа-ялан уртасында җил торган саен көчәя барды, җил белән бергә һавада кар бөтерелде. Бу инде бер дә шәп түгел иде. Солтангәрәйнең сул ягына суык үтә башлады, һәм ул, җилдән битен-колагын каплап, сул кулын әледән-әле күтәреп барырга мәҗбүр булды.

«Ашыктым, ахрысы. Лотфулла бабайларда гына ятасы калган»,— дип уйлап алды ул, чабатачының җылы өен исенә

төшереп, һәм, буран-ни чыкканчы тизрәк Кичүгә җитәргә тырышып, кызурак атларга тотынды.

Ә җил көчәйгәннән-көчәйде, кар шәбрәк яварга тотынды. Солтангәрәйнең яка араларына, куенына, колакларына кар тулды, битенә сылашты. Суык җил аның сөякләренә кадәр үтте, шулай да ул һаман таягы белән юлны капшап баруында булды. Таягы исә атлаган саен, юл катысын тапмыйча, йомшак карга бата барды.

Менә бер заман аның бердәнбер дусты, бердәнбер якын иптәше, юл күрсәтүчесе үзе юлдан язды. Таяк бөтенләе белән карга чумды. Солтангәрәйнең коты алынды: димәк, ул ялгыш якка киткән. Ул кире борылды да як-ягына таягы белән төртеп карады, әмма таяк баягыча һаман төпсез карга батты. Солтангәрәйнең тәне эсселе-суыклы булып китте. «Шулай ук адашырмын микәнни?» — дип уйлады ул, нишләргә белмичә.

Ә җил-буран минут саен, секунд саен көчәя генә барды. Тирә-якта җил шаулаган, улаган тавыштан башка берни ишетелмәде. Солтангәрәй, бер кунычына кар кергәнлеген дә тоймыйча, баскан урынында катып калды. Ул җил юнәлеше буенча китмәкче булды. Бит баштарак җил сул яктан исә иде, ә хәзер каршыга исә башлады. Кичү кайсы якта да, юл кайсы якта? Юнәлешен минут саен үзгәртеп торган җилгә ничек ышанмак кирәк?

Шулай да ул бата-чума кирегә борылды. Никтер аңа юл нәкъ шул тирәдә булырга тиеш шикелле тоелды. Ул бер унунбиш минут чамасы барды, әмма юл табылмады. «Шушы икән үлемем»,—дип уйлады ул тетрәнеп һәм кинәт үз-үзен белештермәстән кычкырырга тотынды. Ул бик озак кычкырды, тамагы карлыгып бетте, тавышы хәтта үзенә дә ишетелмәс булды. Тирә-якта әллә нинди ямьсез тавышлар белән җил улавыннан, җил ыжгыруыннан башка бүтән берни ишетелмәде, Солтангәрәй хәлдән таеп кар өстенә утырды.

10

Көндез башланган буран кич тә, төнлә дә туктамады.

Солтангәрәй шикелле сукыр кешенең генә түгел, күзле, сау-сәламәт кешенең дә мондый буранда адашып, катып үлүе мөмкин. Буранда адашып үлгән андый бәхетсезләрне, гадәттә, өйләрендә кайгырып искә алалар, алар өчен күз яшьләре түгәләр, ә буран тынгач, дөнья бетереп эзләп йөриләр, үле гәү-

дәләрен тапсалар, хөрмәтләп күмәләр, тапмасалар, гомер буена аларны сагынып сөйлиләр.

Ә Солтангәрәй адашып, туңып калса, аны кем искә алыр да кем эзләргә чыгар, аның өчен кем кайгырып-елап торыр? Аның әтисе ягыннан да, әнисе ягыннан да туганнары юк. Юк, бар бугай, тик ул гына беркемне дә белми, һәм шулай ук алар да аны белмиләрдер. Хәер, кайгырмасалар, еламасалар, үлгәч барыбер түгелмени? Үлгәч ул аларның елавын да, кайгыруын да белмәс, аннан аңа күңелле дә, күңелсез дә булмас.

Кар өстендә утырганда, Солтангәрәйнең күңеленә шундый уйлар килде. Ул чын-чынлап үләргә җыенды, чөнки хәзер ул барыбер юлны таба алмаячак иде, тапса да, ихтимал. Кичүгә кадәр барып җитә алмас. Ул шундый арыган, хәлсезләнгән иде. Аннары мондый япа-ялан җирдә аның буран туктаганчы чыдарлык чамасы да юк. Капчыгында сынык-саныклары булса да, өс киеме юка иде. Суык җил аның табаннарына кадәр төшә. Әйе, үләргә калгач үләргә...

Кинәт шул чакны аңа якында гына ниндидер эт өргән тавыш ишетелгәндәй булды. Ялтылаш карга күмелгән килеш, туңып-катып, үлемеңне көтеп утырганда эт өргән тавыш ишетү — бу инде могҗизаларның да могҗизасы иде!

Солтангәрәй айнып китте, аңа яңадан яшәү дәрте, көчкуәт кире кайтты, һәм ул, өметләнеп, тавыш килгән якка борылды.

Чынлап та эт өрә иде. Җитмәсә, бу өрү тавышы һаман саен аңа таба якынлашып килә. Солтангәрәй аягына ук торып басты. Ә бераздан эт бөтенләй якында, Солтангәрәйнең аягы янында ук ырылдый-ырылдый шаулатып өрергә тотынды.

Нинди эт икән бу, кем эте икән? Солтангәрәй моны белмәде һәм белергә дә теләмәде. Шатлыгыннан ул этне кочаклап алмакчы булып кулларын алга сузды һәм елап җибәрде. Эт исә, Солтангәрәй аңа берәр төрле усаллык эшләргә тели дип уйлады булса кирәк, койрыгын кысып бер читкә атылды да, үчләнеп, яңадан өрә башлады.

Ул арада якында гына ниндидер кеше тавышы ишетелеп китте.

— Алгыр! Алгыр! Маһ, маһ! — дип кычкырды кеше, күрәсең, этен чакырып.

Аңа каршы Солтангәрәй бар көченә:

— Аб-ый! — дип кычкырып җибәрде.

— Монда кил, монда! — диде кеше, аңа җавап итеп.

Солтангәрәй, карга бата-чума, абына-сөртенә, тавыш килгән якка таба атлады. Кинәт аның аяклары юл катысын тойды. Ул аптырап китте. Димәк, ул юлдан ерак та булмаган!

Юлда аны атка атланган ниндидер бер кеше көтеп тора иде.

— Кем син? Адаштыңмыни? Кая барасың? — диде кеше, гаҗәпләнеп.

— Мин сукыр... сукыр мин, абый. Юлдан яздым... Саилче мин...—диде Солтангәрәй, кычкырып.

— Атлый аласыңмы? Ат бик йончыган, икебезне дә күтәрә алмас...— диде кеше.

— Атлыйм, атлыйм! — диде Солтангәрәй кабаланып.— Болай булгач, ничек тә калмам.

Һәм алар, икәүләшеп, дөресрәге, дүртәүләшеп, каты, нык юл буенча каядыр кузгалып киттеләр. Кеше юлда сөйләшмәде. Хәер, сөйләшерлек тә түгел иде — буран әле һаман котырына иде. Шулай да ул әледән-әле Солтангәрәйгә тавыш бирде, һәм Солтангәрәй, таягы белән капшанып та тормыйча, аның артыннан калышмаска тырышып, булдыра алган кадәр кызу-кызу атлап барды.

Солтангәрәй тирләп төште, хәлдән тайды, ә беркадәр вакыттан соң нишләптер аның башы әйләнә башлагандай булды. «Егылып калам, ахрысы, шушында»,— дип уйлады ул.

Ә кеше, борылып: «Барасыңмы?» — дип сорагач та, тизрәк: «Барам, барам!» — дип кычкырырга ашыкты.

Алар көрт ерып, җил каршылыгын җиңеп, һаман бертуктаусыз каядыр бардылар да бардылар. Бу нинди кеше, каян кайтып килә, кая бара — бу турыда Солтангәрәй берни уйламады. Кеше булгач кеше, кая да булса илтеп чыгарыр әле. Тик менә нишләп шулай ук бик озак баралар икән соң алар? Инде кузгалып киткәнгә дә шактый вакыт булды бит. Юк, чынлап та хәл бетә. Нәрсә дигән сүз бу? Тамагы ач түгел ләбаса, кар өстендә утырганда гына бер телем икмәк кимереп алган иде. Менә нинди каты буран булды бу; мондый буранга әле аның беркайчан да юлыкканы юк иде. Булмый, бер генә адым да атлар хәл юк! Кирәкми, китсен үзе генә...

Атка атланган кеше, онытылып, үз артындагы сукыр юлчыга аваз бирмичә, күпмедер вакыт тын гына барды. Шулай бара торгач, аның колагына арттан чинап өргән эт тавышы чалынып калды. Кеше атын туктатты да, артына борылып:

— Барасыңмы? — дип кычкырды.

Арттан җавап килмәде. Кеше тагын кычкырды, Солтангәрәйнең тавышы барыбер ишетелмәде, бары тик буран улавы аша эт өргәне генә аермачык булып яңгырап китте.

— Эх, гөнаһ шомлыгы! — дип куйды юлчы борчылып. Бик авырлык белән генә атыннан төште дә, атын җитәкләп, юл буйлап кире китте. Бер илле-алтмыш адым җир киткәч, ул кар өстендә сузылып яткан Солтангәрәй янына барып чыкты. Шунда ук чинап, нишләргә белмичә, Алгыр да бөтерелеп йөри иде.

— Менә сиңа бәла! — дип сөйләнде кеше, Солтангәрәйнең йөзенә иелеп.

Кеше, атның тезгенен ычкындырып, бияләйләрен салып кесәсенә тыкты да көрт күмеп китә язган саилчене аягына бастырды.

— Әй юлдаш, ни булды? Әйдә, киттек! — дип кычкырды ул Солтангәрәйнең колагына.

Җавап урынына «юлдаш» ниндидер аңлаешсыз нәрсәләр генә мыгырданды. Шуннан соң кеше аны, ике куллап тоткан көе, селеккәләп, каккалап алды. Егет барыбер аңына килмәде.

— Менә син гөнаһ шомлыгы! — дип куйды кеше тагын да үзалдына сөйләнеп.

Ә аяк астында бертуктаусыз шыңшып Алгыр бөтерелде.— Ярар, Аллага тапшырдык алайса, хәерле булсын,— дип сөйләнде атлы юлчы.

Ул Солтангәрәйнең ярым үлек гәүдәсен иңбашына күтәреп алды да, йөзтүбән каплатып, ат сыртына салды. Аннары өстендәге тунын салып, саилченең өстенә каплады һәм алар яңадан кузгалып киттеләр.

11

Төн урталарына таба, бала-чагалар инде йоклашып беткәч, тышта кемнеңдер тәрәзә капкачын шакылдатканы ишетелде. Лотфулла карт эшеннән туктап калды, билен турайтты да тыңлый башлады. Тавыш тагын кабатланды. Шуннан соң ул тәрәзә каршына килде, әмма тәрәзә аша берни күренерлек түгел иде. Мондый төнне тышка бик үк чыгасы килмәсә дә, Лотфулла карт өстенә-башына киде дә чыгып китте.

— Кем бар? — дип кычкырды ул, капка янына килеп.

Буран инде йомшый төшкән, шулай да тынып җитә алмаган иде әле. Тәрәзә турысындагы зур карачкы, картның

табышын ишетеп, кыймылдап куйды һәм әкрен генә капкага якынлашты. Лотфулла карт аның ниндидер атлы кеше икәнлеген аера алды. «Юлчыдыр. Төн кунарга сорыйдыр»,— дип уйлап алды ул һәм, берни сорашып тормыйча, көрәк алырга дип, кире чоланга кереп китте.

Кар күмеп киткән капка тирәсен беркадәр көрәп ташлагач, атлы кеше ишегалдына узды. Лотфулла карт, аны-моны сорап тормастан, шундук абзарга таба ашыкты. Абзар капкасы тирәсен көрәп ташлады да, юлчының атына дип, тиз генә улакка солы салды, печән салды.

Юлчы, ат өстеннән ниндидер авыр, кара нәрсә алып, аны баскыч төбенә куйды һәм карт артыннан абзарга юнәлде. Атны хуҗага тапшырды да шундук кире борылып килде. «Тәмам бетәшкән, ахрысы»,— дип уйлап алды Лотфулла бабай, юлчы турында.

Беркадәр вакыттан соң, күшеккән атның карын сыпыргалап, өстенә чикмән каплап һәм суынсын, тын алсын өчен аны бәйләп куеп, яңадан өенә килеп керсә, идән уртасында ниндидер кеше ятуын күреп, ул аптырап китте. Бер генә кеше шикелле иде ләбаса, нишләп икегә әйләнгән соң әле бу? Ул, үз күзенә үзе ышанмыйча, бер идәндәге кешегә, бер юлчыга карап алды.

— Таныш булыйк, Кичүнең Гыйльми дигән кешесе булам,— диде юлчы, хуҗага кулын сузып.— Ә менә монысы — юлдан таптым. Җаны бар... самовар куеп җибәргәндә яхшы булырые...

— Гыйльми? Соң, белми ни, беләм, бик беләм! — диде Лотфулла бабай, кабаланып.

Аннары ул иелеп Солтангәрәйгә карап алды да кинәт кычкырып җибәрде:

— Бу бит... теге... кем... сукыр егет! Юлда таптым диген, ә? Аһ Алла, туңып үлгәнме?

— Юк әле, үлмәгән,— диде Гыйльми, күшеккән иреннәрен көчкә кыймылдатып.

Өйдәге шау-шуны ишетеп, бүтәннәр дә торды. Лотфулла бабайның карчыгы, тыз-быз килеп, тиз генә самовар куеп җибәрде. Чоланга чыгып, зур гына бер янчык белән кипкән җиләк, төрле үләннәр алып керде.

Чәй кайнаганчы, Лотфулла бабай Солтангәрәйнең туңган аяк-кулларын бертуктаусыз кар белән ышкыды. Карчыгы күп итеп утын алып керде дә мичкә ягып җибәрде.

Кичү кешесе алай өшемәгән иде, өй җылынгач, кайнар чәй эчкәч, аңа шундук җылы кереп китте, әмма Солтангәрәй белән төне буе азапланырга туры килде. Кипкән кура җиләк, карлыган, мәтрүшкә һәм тагын әллә нинди үләннәр кушып кайнатылган суны эчергәч, аны ике кат тун, толып белән төреп, мамык ястыкка йокларга яткырдылар.

Иртәнгә буран тәмам тынды. Көн ачылып китте, бөтен дөнья тынып калды. Кичәгенәк кенә буран котыруына хәтта ышанасы да килми иде. Гыйльми хуҗага рәхмәтләр укыды да, этен ияртеп, атына атланып, үз йомышы белән чыгып китте. Ә Солтангәрәй саташып, Лотфулла бабайлар йортында ятып калды. Ул бары бер атнадан соң гына аңына килде. Үзенең яңадан Лотфулла картлар йортында икәнлеген белеп, ул бик нык гаҗәпләнде. Аңа монда ничек килеп эләгүе турында сөйләп бирделәр. Юлда хәлдән таеп егылганнан соң, нәрсә булганын ул бөтенләй белми иде.

Бер айдан Солтангәрәй тәмам хәлләнеп җитте. Беркөнне Лотфулла бабай әйтте:

— Улым, инде аягыңа бастың,— диде,— көннәр язга таба авышты, теләсәң кал, теләмәсәң тота алмыйм.

Ләкин хәзер Солтангәрәйнең болай гына чыгып китәсе килмәде. Үзен үлемнән коткарып калган, үзенә шулкадәр яхшылык күрсәткән кешеләргә аның да нинди дә булса изгелек эшлисе килде.

— Бабай, каршы килмәсәң, мин монда бераз торып торыйм,— диде ул тартынып кына.— Мин әллә ни эш кыра алмыйм, шулай да, үзең беләсең, мин сиңа чабата ясауда булыша алам.

Лотфулла бабай моңа чын күңелдән сөенде. Аның гаиләсе ишле генә иде. Үзе белән карчыгыннан башка тагын кияве каядыр читкә бәхет эзләп киткән кызы тора иде. Ә аның ике баласы бар иде. Ләкин балаларның икесе дә кызлар иде. Бөтен өй эчендә ир затыннан Лотфулла бабай берүзе генә булып, аңа ярдәм итәрлек, булышырлык беркем дә юк иде. Шуңа күрә дә ул Солтангәрәйне беренче күрүдә-танышуда ук яратып өлгергән иде.

Солтангәрәй бик уңган булып чыкты. Лотфулла бабай чабатаны аңа үреп-кайтарып кына бирде, ә калган бөтен эшне Солтангәрәй башкарды. Икәүләп эшләгәч, эш хәзер бермә-бер алга китте — урманнан юкә ташып кына өлгер дә нык, калын чабаталарны сатып кына өлгер! Солтангәрәй, билгеле, вакыт

булганда, хуҗалык эшләрендә дә булышты: мал-туарны ашатты-эчертте, кар көрәде, абзардан тирес түкте, утын-фәлән кертте. Ә кичләрен ул өйдәгеләргә үзенең башыннан үткәннәрен сөйләде, туган якларын исенә төшерде. Аны барысы да йотлыгып тыңлыйлар иде. Тора-бара ул монда бөтенләй үз кеше булып китте. Ул хәзер кая да булса чыгып китү, теләнү турында уйлап та карамады. Аның хәзер күңелсезләнергә, үзенең язмышы турында кайгырып утырырга вакыты да юк иде: бөтен вакыты эш белән узды, эш булмаганда, балалар белән, олылар белән сөйләшеп-аралашып узды.

— Син инде, улым, буйга да җитеп киләсең,— диде бервакыт Лотфулла бабай.— Ошатсаң, бөтенләйгә үземдә торып калырсың. Алла боерса, үзеңә берәр кыз ярәшеп ташларбыз, җәмәгатьле булырсың — таяк тотып, капчык асып йөрү бер дә һөнәр түгел.

Солтангәрәй оялудан кып-кызыл булды. Өйләнү! Кая инде ул аңа өйләнүләр, кызлар турында хыялланулар! Шулай да өметсез — шайтан, ди. Лотфулла бабайның сүзләре аның яшь күңелен җилкендереп җибәрде.

Тиздән көннәр җылыта башлады, тәрәзәдән көндезләрен кояш карады, арканы куеп утырдың исә, бөтен тәнне җылытты.

Чабата ясау бер генә көнне дә туктап тормады. Көннәр озайгач, эш тагын да шәбрәк бара башлады. Солтангәрәйнең тышка чыгасы, урамнарда йөреп кайтасы килде, һәм ул, әзрәк кенә вакыт булдымы, кулына таягын алды да, урамдагы балалар чыр-чуына, түбәләрдән аккан тавышларга колак салып, авыл буенча йөреп кайтты. Аның күңеле торган саен ныграк тынычсызлана башлады. Аның каядыр китәсе, кемнедер күрәсе килгән шикелле булды, һәм ул, әледән-әле Лотфулла бабайның сүзләрен исенә төшереп, үз-үзенә урын тапмыйча, дулкынланырга, хисләнергә тотынды.

Менә бер заман тамчылар да тамып бетте, өй түбәләре ачылып, караеп калды, урамнардан ерганаклар акты, елгаларда ташулар акты. Тышта күңелле бала-чага чыр-чуы, сыерчыклар һәм һәртөрле шат кошлар тавышы яңгырап торды.

Яздан соң озакламый җәй башланды, һәм җылы, моңсу көннәрнең берсендә, июль урталарында, Лотфулла бабайларга бер ир кеше килеп керде. Аның килеп керүе булды, кинәт әйтерсең бөтен дөнья үзгәреп китте. Балалар: «Эти!»— дип, карт белән карчык: «Улым!»— дип, «Кияү!»—дип, килеп керүчегә, дөресрәге, кайтып керүчегә ташландылар.

Кайтып керүче хуҗаларның кияве Госман иде. Ул ике елга якын читтә бәхет эзләп йөргән иде. Куптән инде аннан хат-хәбәр юк иде, һәм менә хәзер ул, беркадәр мал җыеп, хатыны, балалары янына кайтып төшкән иде. «Кияү кеше кайткач, өй эче шундук кысанланып калды. Карт белән карчык та, яшь хатын белән балалар да, билгеле, аның тирәсендә генә кайнаштылар, аңа гына игътибар иттеләр, аның белән генә сөйләштеләр.

Солтангәрәйне әйтерсең барысы да кинәт исләреннән чыгарып ташладылар. Беркем дә аңа элеккечә үз итеп, якын итеп эндәшмәде. Хәер, Солтангәрәйгә генә бу шулай тоелды. Хәтта кайчагында ашарга эндәшкәндә дә юри көттереп дәшәләр шикелле тоелды. Үзенең гариплеген, кимчелекле кеше икәнлеген бик яхшы аңлаганга, Солтангәрәйгә бу җитә калды. Аның бик тиз күңеле төште. Хуҗалардан бигрәк, ул үзе берни сөйләшмәс-эндәшмәс булды. Ашарга утырса, тамагына аш бармады, йокларга ятса, күзенә йокы кермәде. Юк, аңа монда төпләнеп калу, күрәсең, насыйп түгел иде. Ул монда чит кеше, артык, кирәксез кеше иде.

Солтангәрәй китәргә булды. Кичкә таба барысы да йоклап беткәнне генә көтте дә иплән кенә урыныннан торды, алдан әзерләп куйган иске-москыларын, капчыгын алды, ишек төбендәге таягын кулына элдерде дә шыпырт кына тышка чыкты. Уянмадылар микән, сизенмәделәр микән дип, беркадәр вакыт ишек төбендә тыңлап торды — юк, беркем дә уянмады, бары тик чоланда йоклаучы кияүнең гырылдавы да мич артындагы чикерткәләрнең сайравы гына ишетелде. Әйе, хуҗаларга ул берни белдермәде, чөнки аларны инде ата-анасы кебек яратып өлгергән иде. Хәзер исә шул ата-анасы кебек якын кешеләрнең: «Китмә! Сине беркем кумый бит!» — шикелле ялган, ышандыргысыз сүз әйтүләреннән курыкты.

Җәйге төн тып-тын. Кайдадыр елга буенда бакалар кычкыра да үләндә чикерткәләр черелди, еракта этләр өрә. Шул төнге тавышларга бераздан юл катысына тук-тук шакылдаткан таяк тавышы кушылды. Ләкин бу тавыш та бик зәгыйфь иде, һәм озакламый ул да каядыр кинәт юк булды. Бары тик туктаусыз бакалар кычкырды да, бертуктаусыз чикерткәләр генә сайрады...

ышык урын — *монда:* җилсез, тыныч урын
ифрат — гаять, бик

көнне сындыру — көннең кинәт җылытып җибәрүе
тула оек — киездән тегелгән калын оек
юлдан язу — *монда:* адашу
могҗиза — гаҗәпләнерлек, искитәрлек хәл
юлыкканы юк — очраганы юк
саилче — хәерче, теләнче

Сораулар һәм биремнәр

1. Солтангәрәй юлда нинди хәлләргә очрый? Шул урыннарны кабат укыгыз һәм сөйләгез.
2. Аңа кешеләр ничек ярдәм итәләр?
3. Лотфулла картның киң күңеллелеген нәрсәләрдә күрәсез? Ничек уйлыйсыз. Солтангәрәйнең юлга чыгуы кирәк идеме?
4. Бүлекнең кайсы урыннары сезгә ныграк тәэсир итте? Ни өчен?
5. Бүлекнең эчтәлеген сөйләгез.

Өченче бүлек

1

Шәһәрдә Солтангәрәйгә баштарак бик сәер булып тоелды. Урамнарда ул артык шау-шу, буталыш сизмәде, чөнки ул иртәнге вакыт иде, аннары... ул авылдагыча нәкъ урам уртасыннан барды. Аяк астына таш җәйгән. Таяк шакылдап-шакылдап китә, тик менә өйрәнмәгәнгә аякны гына авырттыра. Ә шулай да авылның тузанлы, кәкре-бөкре, чокыр-чакырлы урамнарына, юлларына караганда яхшырак. Халкы гына ничектер инде...

Шулай урам уртасыннан этен ияртеп, үзенчә уйланып барганда, Солтангәрәйнең артында гына:

— Әй-әй!— дип кычкырган тавыш ишетелде.

Солтангәрәй анда кемгә кычкыруларын, ни өчен кычкыруларын аңлый алмады. Тавышка ул хәтта әһәмият тә итмәде. Кинәт аркасында чыбыркы чыжлавын тоеп, ул сискәнеп китте, читкә тайпылды, һәм шулвакыт аның колак төбендә генә ачулы извозчикның:

— Әй ахмак! Әнә пыртуардан бар! — дип кычкырганы ишетелде.

Солтангәрәй аның нәрсә әйткәнен аңлап җитмәде, шулай да урам уртасыннан барырга ярамаганлыгын шәйләп алды һәм читкәрәк борылды.

«Нәрсә икән соң ул пыртуар дигәннәре?»— дип уйлады ул, чыбыркы төшкән урынын уа-уа.

Нәкъ шул чагында Алгыр, хуҗасына сугуларын күреп, ырылдап, узып киткән тарантас артыннан ташланды. Ләкин аңа да бик тиз хуҗасы татыганны татып карарга туры килде.

— Алгыр! Алгыр!— дип кычкырды Солтангәрәй, этен чакырып.

Эт авыртудан чинап, елап, кире Солтангәрәй янына йөгереп килде.

— Авыл түгел бу сиңа! — диде Солтангәрәй, эткә акыл өйрәтеп.— Икенче шулай өреп чапмассың теләсә нинди ат артыннан. Пыртуардан барырга кирәк, Алгырым.

Солтангәрәй урам читенә чыкты да, ниндидер кешене туктатып:

— Абый, кая ул пыртуар дигәннәре? — дип сорады.

Ләкин абый дигән кеше татарча аңламый булып чыкты, мыскыл итеп: «Тата-та, бата-та!» — диде дә ашыгып үз юлы белән китеп барды. Солтангәрәй авызын ачып торды да калды! «Менә сиңа! Монда мин күзсез генә түгел, телсез дә икән әле!» — дип уйлады ул, шәһәрдән күңеле кайта башлап.

Шулай да ул тагын кузгалып китте. Аны шәһәргә алып килгән бер абзый: «Син тот та базарга бар, синең ише халык шунда базарда була, энем»,— дигән иде. Һәм менә хәзер ул нәкъ шул базар янына китеп бара иде. Берәздән аның колагына татарча сүзләр чалынып калды. Якыннан гына ниндидер кешеләр үзара сөйләшеп баралар иде. Солтангәрәйнең эченә җылы кереп киткәндәй булды.

— Абзыйлар,— диде ул, аларга эндәшеп,— базарга шушы юл барамы?.. Белмисезме, пыртуар дигәннәре кайда икән?..

«Абзыйлар» туктап калдылар, таяклы, этле сукыр хәерчегә беравык аптырабрак карап тордылар да шаркылдашып көләргә тотындылар. Тавышларына карап, аларның һич тә абзый булмауларын, киресенчә, энеләр, малайлар булуын Солтангәрәй шунда гына аңлап алды. Ул үзенең ялгыш сөйләве өчен кызарынып китте. Ләкин «абзыйлар» бөтенләй моның өчен көлмәделәр, үзләренә олылап эндәшү, күрәсең, аларга хәтта ошап та куйды. Алар хәерченең сүзләреннән көлделәр.

— Сиңа соң, энекәш, базар кирәкме, пыртуар кирәкме?— диде яшьләрнең берсе, көлүеннән тыелырга тырышып.

— Базар кирәк... базарга барам мин...— диде Солтангәрәй каушап.

— Уу, бу юл анда бармый! — диде икенче берәү, «юл» сүзенә басым ясап.— Бу юл Мәскәүгә бара, сиңа соң Әтнә базары кирәкме?

«Абзыйлар» тагын авыз күтәреп көләргә тотындылар.

— Ташлагыз әле, әфәнделәр, гариптән көлүегезне! — диде арадан берәү, иптәшләренә ачуланып.— Пыртуар менә шушы була, менә урам чите. Алай урам уртасыннан йөрмә, таптап китәрләр. Ә базарга син, туган, дөрес бармыйсың, хәзер сиңа сулга борылырга кирәк, аннары бераз кирегә китәргә... юк, уңга борылырга...

— Аннары туп-турыга, аннары тагын сулга, шуннан соң уңга каерылган юл булыр...— дип тезеп китте «юл» сүзен кызык күргән егетләрнең берсе, яңадан көләргә тотынып.

Солтангәрәй тыңлап торды да өйрәткән юнәлеш буенча китеп барды, ләкин никтер ул егетләрнең сүзенә ышанып җитмәде, алар аңа бу юлны юри көләр өчен генә әйткәннәрдер шикелле тоелды. Шаян малай-шалайлардан ераклаша төшкәч, ул яңадан туктады һәм тагын берәр татарча сөйләшкән тавыш ишетелмәсме дип көтә башлады.

— Пыртуарын белдек, хәзер инде базарын гына табасы калды,— дип сөйләнде ул, этенә эндәшеп.

Шулай басып торганда, ниндидер бер яшь кенә хатын-кыз чыркылдык тавыш белән, коты алынып:

— Абау!— дип кычкырып җибәрде.

«Әһә, татарлар икән! — дип уйлап алды шундук Солтангәрәй.— Ләкин ник курыкты икән соң ул?»

Солтангәрәй, кычкыручы хатын-кыз тизрәк узып китә күрмәсен дип, ашыгып:

— Сеңлем...— диде.

— Абау, мәхәббәтсез! — диде хатын-кыз, тагын да яманрак чыркылдап.— Эте белән кеше куркытып торганы җитмәгән, сеңлем дигән була! Мин сиңа нинди сеңел булыйм, ди...

«Аһ Алла, бигрәк кызык икән бу шәһәр кешеләре! — дип уйлап алды Солтангәрәй, тәмам аптырап.— Ничек эндәшсәң дә ярамый, гаеп табарга гына торалар».

— Апа, базарга каян барырга?— диде ул, кычкырып.

— Кара, сукыр лабаса ул!— диде икенче бер картрак тавышлы хатын-кыз.

— Чынлап та, апа җаным,— диде чыркылдык яшь кыз, туктап.

— Этең тешләмиме? — диде хатыннарның олырагы.

— Юк, юк!— диде Солтангәрәй, Алгырның муенындагы каешыннан тотып. Хатын-кызлар бер адым кире килделәр дә базарга ничек барырга кирәклеген аңлата башладылар. Ләкин Солтангәрәй берни аңламады. Дөресен әйткәндә, ул игътибар белән тыңлый алмады. Ул якыннан гына искиткеч хуш ис килгәнлеген генә тойды. Ул кемнең шулай җиңел, татлы ис аңкытканлыгын бик яхшы белде. Аның кинәт нишләптер зиһене таралып киткәндәй булды, йөрәге сулкылдап тибәргә тотынды, һәм ул, кызарынган йөзен хатыннарга күрсәтмәс өчен, башын торган саен түбәнрәк иде.

Юл өйрәтүчеләр китеп бардылар.

Аларның хуш исләренә исергән Солтангәрәй дә, үзенең кая барырга тиешлеген онытып, каядыр читкә, кирегә борылды.

Шулай бара торгач, ул кинәт таягын ниндидер кешенең аякларына илтеп төртте. Ир кеше абынып китте, артына борылып карады да сүгенергә тотынды.

— Мин сукыр, абыкаем, ачуланма,— диде Солтангәрәй, коты алынып.

— Күреп торам сукыр икәнлегеңне! — дип җикеренде кеше, усал калын тавыш белән.— Сукырмын дип монда!.. Йөри белмәгәч, чыкмыйлар аны урамга.

Хуҗасына каты орынуларын күреп, Алгыр тагын аны якламакчы булды. Усал ырылдап юан кешегә ташланды һәм чакчак кына тегенең чалбар балагыннан эләктереп алмады — ярый әле Солтангәрәй аны вакытында тотып өлгерде.

— Ябып куярга кирәк сине этең-иең белән! — диде әлеге кеше, ераклаша барып.

Солтангәрәй, мондый сүз ишетеп, тагын да ныграк шүрли төште: «Эх, авылга җитәме соң!» — дип уйлады ул, пошынып, һәм, моннан соң тагын шундыйрак, көтелмәгән хәлләргә очрамас өчен, ничек тә игътибарлы, уяу-сак булырга үз-үзенә сүз биреп куйды. Әмма әле шәһәр тормышына ныклап күнеккәнче, аңа тагын күп кенә нәрсәләргә юлыгырга туры килде.

пыртуар — тротуар
чалынып калды — күренеп китте
беравык — бераз
коты алынып — куркып
җикеренде — кычкырды

Сораулар һәм биремнәр

1. Солтангәрәйне шәһәр ничек каршылый?
2. Шәһәрдә очраган кешеләрнең Солтангәрәйгә мөнәсәбәтләрен аңлатыгыз.
3. Аңа ни өчен базарга барырга кушалар?
4. Алгыр хуҗасына ничек булышырга тели? Шул юлларны табып укыгыз.
5. Соңгы җөмләне тагын бер кат укып, фикерегезне әйтегез.

Бишенче бүлек

7

Солтангәрәй бөтен күңелен укуга бирде. Укытучы ярдәмендә төрткеләр алфавитына шактый төшенә башлады. Дәресләр белән генә канәгатьләнмәде, булган бөтен буш вакытын шул яңа эшкә багышлады. Алай гына да түгел, хәтта төннәр буена калын авыр китаплар капшанып утырды. Яшьтән укымаганлыктан, уку аңа җиңел бирелмәде. Ләкин аның күңеленә әйтерсең ниндидер корт кереп урнашкан иде. Менә шул корт аны һәрвакыт борчып, тынычсызлап торды, һәртөрле кыенлыкларны, эч пошу, кайгы-хәсрәтләрне онытып торырга ярдәм итте.

Ике ай эчендә ул Брайль системасын тулысынча үзләштерде, шактый тиз язарга һәм сүзләрне бергә бәйләп укырга өйрәнде.

Бу ике ай бүтән яктан да Солтангәрәй өчен һәм башка сукырлар өчен бик нык хәтердә калырлык булды. Күп тырышып йөри торгач, алар өчен кәрзин үрү мастерское ачып җибәрделәр. Буш вакытларын кая куярга белми аптыраган яисә уку яшеннән чыккан, инде хәреф танудан өметен өзгән күп кенә кешеләр өчен бу чын-чынлап бәйрәм булды.

Кәрзин үрүдә Кармак барысыннан да уздырды. Бу эшкә аның кулы килешеп тора иде. Иптәшләренә караганда ул тизрәк тә, матуррак та үрә һәм, үзенең мондый сәләте белән горурланып, еш кына:

— Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс,— ди иде.— Без хәзер һөнәрле. Без әле киләчәктә кәрзиннәр генә түгел, матурматур креслолар, җиңел-җиңел өстәлләр дә үрербез бу талчыбыклардан!

Солтангәрәй, никадәр тырышмасын, һич тә Кармакныкы кебек матур, җыйнак кәрзиннәр үрә алмады. Бервакыт ул, зарланып, иптәшенә:

— Ничек алай яхшы итеп үрәсең соң син? — диде.— Минеке гел кыек-мыек була—кулыңа алырга хурланасың, валлаһи!

— Кемнең күңеле нидә бит! — диде аңа Кармак.— Син инде менә ничә китап укырга өлгердең, ә мин әле һаман хәрефләрне аерып бетерә алмыйм. Минем бармаклар шул нәгълэт төшкән төрткеләрне һич кенә дә сизми. Нишләтәсең инде аны? Кайчакта бармак битен игәүләп тә карыйм — юк, булмагач булмый! Томана минем бармаклар. Ә талчыбык ул төртке түгел, аны тотып карап була.

Яхшы эшләгәне, тырышлыгы, гомумән, үз иптәшләре арасында авторитет казанганы өчен Кармакны мастерскойның оста ярдәмчесе итеп билгеләделәр. «Түрә» булып алгач, Кармак сизелеп үк үзгәрде, үзен чын-чынлап башлыкларча җитди тота башлады. Ләкин ул әз генә дә борын чөймәде, иптәшләре белән элеккедән дә ныграк дуслашып, аралашып китте һәм, кайчан гына булмасын, теләсә кемгә сүзе-киңәше белән дә, эше белән дә ярдәм итәргә тырышты.

Бераз вакыттан, мастерскойның зур гына файда китерүен күреп, собес щетка ясау цехы ачып җибәрде. Бу эшкә ирләрне генә түгел, хатын-кызларны да җәлеп иттеләр. Мастерскойда эшләүчеләр саны хәзер сиксәннән артып китте. Шул чакны мастерскойның өлкән остасы авырып китте. Бөтен эш Кармакка йөкләнде. Кармак үзен чын-чынлап булдыклы җитәкче итеп танытты. Мастерской айдан айга табыш белән эшли башлады. Алар турында хәтта газетага да язып чыктылар.

Эшләр шулай җайланып барганда, сукырлар тормышында тагын бер яңалык артты. Беркөнне инвалидлар торагына халык иҗаты йортыннан нindидер бер вәкил килде һәм сукырлар арасында җырчылар, төрле уен коралларында уйнаучылар, шигырь сөйләүчеләр юкмы дип кызыксынды. Тикшерә-сораштыра башлагач, җырчылар да, уенчылар да һәм, гомумән, артист булырга яратучы башка кешеләр дә табылды.

Вәкил бер килде, ике килде һәм озакламый драмтүгәрәк белән баянчылар түгәрәге оештырып җибәрде. Түгәрәккә Солтангәрәй дә язылды. Ләкин ул аңа әллә ни күңел бирә алмады, чөнки уку аның бик күп вакытын ала иде.

Түгәрәк әгъзалары Беренче май бәйрәменә концерт әзерләделәр. Концерт алдыннан лекция тыңладылар. Аннары бер пәрдәлек пьеса куелды. Концертка сукырлар да, күзлеләр дә

В. Е. Булатов рәсеме

килгән иде. Алар бик игътибар белән тыңлап тордылар. Бер пәрдәлек пьесадан соң төрле номерлар башланды.

Щетка мастерскоенда эшләүче Миңзифа дигән яшь кенә бер кыз татар халык көйләрен җырлады. Аның тавышы искиткеч көр, моңлы иде. Ул кичне кыз бик күп егетләрнең йөрәк кылларын чыңларга мәҗбүр итте. Аңа шаулатып кул чаптылар, бер-бер артлы чакырып сәхнәгә чыгардылар. Ул, карышмыйча, тагын берничә җыр җырлады.

Кармак концертны исе китеп тыңлады. Кайчандыр үзенең Солтангәрәй белән базарда гармун уйнап, җырлап йөрүләрен хәтерләде. Ул чакта алар мәҗбүр булган өчен шулай җырлаганнар, уйнаганнар иде, һәм аларның җырлаганы-уйнаганы да күбрәк күз яше агызу өчен корылган иде. Ә хәзер? Хәзер ул тыңлаучы булып утырды, ләкин аның күзләреннән әз генә дә яшь акмады. Бары тик күңеле генә дулкынланды. Әйе, бик нык дулкынланды, моңарчы беркайчан да булмаганча дулкынланды. Нәрсә булды икән соң аңа? Ә бит моңарчы ул Миңзифаның хәтта барын-югын да белми иде...

Концерт бетүгә, ул «артистлар» янына ашыкты. Иптәшләре арасыннан көч-хәл белән үтеп, Миңзифаны эзләп тапты да, чын күңелдән аның кулын кысып:

— Котлыйм сине, сеңелкәш! — диде.— Шундый матур тавышың бардыр дип һич уйламаган идем. Карале, син бит, Миңзифа, без каргалар арасында бердәнбер сандугач икән ләбаса! Шундый матур тавышың барлыгын ник моңарчы яшереп йөрдең?!

Мондый мактау сүзләренә Миңзифа оялды, кызарды, юкны сөйләмәгез инде, Кадыйр абый, дигән булды, бу кадәр мактауга минем масаеп китүем бар, иплләбрәк, дигән булды.

Хатын-кызлар торагы ирләр торагыннан берничә квартал арырак иде. Кармак Миңзифаны озатып куймакчы булды. Миңзифа, тартынып булса да, риза булды. Бу кичне алар бер тын гына бакчада бик озак сөйләшеп утырдылар.

(Ниһаять, Солтангәрәй югары белем ала. Шәһәр мәктәпләренең берсендә тарих укыта. Күз врачы булып эшләүче хатыны Зөләйха ирен күзле итү турында хыяллана, күз дәвалау турындагы барлык яңалыкларны укып-белеп бара. Эзләнә торгач, бер яңа «метод»ка тап була. Һәм иренең диагнозын офтальмология институтына җибәрә. Институт клиникасыннан чакыру килә һәм Солтангәрәйгә опера-

ция ясыйлар. Операция уңышлы чыга, Солтангәрәй һәм аның гаиләсе өчен бәхетнең иге-чиге булмый.)

нәгъләт төшсен — бик каты гаепләү, каргау сүзе
игәүләү — шомарту, үткенләү
башлыкларча — җитәкчеләрчә
торак — яшәү, тору урыны
вәкил — берәр оешма тарафыннан җибәрелгән кеше

Сораулар

1. Солтангәрәй ничек укый, нинди каршылыклар кичерә? Егетнең уңышка ирешүенә кайсы сыйфатлары ярдәм итә?
2. Сукырларны нинди һөнәрләргә өйрәтәләр?
3. Кармак ни өчен иптәшләре арасында абруй казана дип уйлыйсыз?
4. Сукырлар йортында Кадыйр кем белән очраша? Бу очрашу егеттә нинди хисләр уята?
5. Тормышта шундый кешеләр турында ишеткәнегез яки укыганыгыз бармы? Шул турыда сөйләгез.

Самат Шакир
(1924—1998)

Күренекле язучы Самат Шакир (Самат Фәтхерахман улы Шакиров) 1924 елның 15 апрелендә Татарстанның Әтнә районы Күәм авылында туа. 1938 елда җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Арча педагогия училищесына укырга керә. Аннан соң укытучы, мәктәп мөдире, редакция хезмәткәре булып эшли. 1957 елда Казан дәүләт университетын тәмамлый.

Самат әдәби иҗат эшчәнлеген шигырьләр язудан башлый. 1939 елда «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналында Габдулла Тукайга багышлап язылган «Урман» исемле беренче шигыре дөнья күрә. Шуннан бирле аның шигырьләре көндәлек матбугатта да, аерым җыентыклар булып та еш басыла. Ул — уннан артык шигырь китабы авторы. 1984 елда язучының иң яхшы поэтик әсәрләре тупланган «Яраннар чәчәк аткан» дигән күләмле шигъри җыентыгы чыга.

Шулай да Самат Шакирның чын иҗат йөзен, шигъриятътән бигрәк, проза әсәрләре — очерклар, документаль повестьлар билгели. Автор күп эзләнә: дәһшәтле сугыш булган урыннарга бара, карт солдатлар, партизаннар белән очраша. Шулай итеп әсәрләре өчен мәгълүматлар җыя. Аның 1965 елда дөнья күргән «Легенда егетләре» исемле беренче документаль повестен укучылар яратып кабул итә. Бу әсәр Сталинград өчен сугышларда һәлак булган каһарман егетләребезгә багышлап язылган. Язучының «Үлемсезләр», «Һәйкәлләр итәгендә чәчәкләр», «Ташлардагы язулар», «Үлемне җиңгән батыр» һ. б. әсәрләрендә дә халкыбызның батыр уллары сурәтләнә.

С. Шакир фашист тоткынлыгында зур батырлыклар күрсәтеп һәлак булган шагыйрь Хәйретдин Мөҗәйнең фронт көндәлекләрен, шигырьләрен эзләп табып, аерым китап итеп бастырып чыгара, һәм үзе дә әлеге каһарманның тормышы, иҗаты турында «Үлемнән көчлерәк» дигән очерк яза. Шулай ук ул — сугыш кырларында һәлак булган татар язучылары әсәрләрен, биографик белешмәләрен эченә алган «Алар сафта» (1961), «Сугыш язмалары» (1967), «Солдат хатлары» (1968) җыентыкларының автор-төзүчесе дә.

Аңа җәмәгать һәм язучылык эшчәнлеге өчен 1984 елда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә.

Самат Шакир 1998 елда Казан шәһәрендә вафат була.

ҮЛЕМНӘН КӨЧЛЕРӘК

(очерктан өзекләр)

Малай йөрәгендә әкият батыры

Җәзаланучылар арасындагы Мөҗәһит Хәйретдинов шагыйрь һәм полк командиры була. Аның әдәби псевдонимы — Х. Мөҗәй.

Данко йөрәкле бу шагыйрь 1901 елның 26 мартында Башкортстан республикасының Туймазы районы Төрекмән авылында туа. Кышларын авыл мәктәбендә укый, җәйләрен хуҗалык эшләрендә катнаша: җир тырмалый, көлтә ташый.

Мәктәптә укыган елларында ук шигырьләр яза башлый. Бик кечкенәдән әкиятләр, җырлар ярата. Авыл малайлары белән бергә кичләрен үзәнлеккә ат сакларга йөри.

Бүген алар белән бергә Хәсән бабай да килгән иде. Көндәгечә учак ягып җибәрделәр. Мөҗәһит Хәсән бабай янына елышты. Ул бабайдан әкият сөйләвен үтенде. Иптәш малайлары да аны куәтләде.

Хәсән бабай, күзен бер ноктага төбәп:

— Чын егетлек — батыр булуда! — диде.— Батырларның батыры булу куркусызлыктан, тәвәккәллектән килә. Бик борынгы заманда Биктимер дигән бер батыр булган. Менә шул Биктимер батыр унике башлы аждаһага каршы берүзе сугышкан.

Кара чәчле, коңгырт-кара күзле, түгәрәк йөзле, чандыр гәүдәле Мөҗәһит бабайның сүзләрен йотлыгып тыңлый. Ул

Биктимер батырның көчле кулларын йомарлаган хәлдә аждаһаның өстенә басып торуын күргән кебек була. Менә ул ике потлы гер кадәрле кулларын селки-селки нидер сөйли... Менә ул басып торган җиреннән зур-зур атлап Хәсән бабай янына килә. Юк, Хәсән бабай янына түгел, каядыр ерактагы тау башына менә. Алтын-көмеш бизәкләргә баткан кылычын биек кыя башына кадап куя да: «Кайсыгыз кылычны менеп ала, шул батыр була!» — ди. Үзе шул минутта ук тылсымлы рәвештә ак томан булып күздән югала. «Их, шул кылычны алсаң иде»,— дип уйлый Мөҗәһит. Ул әкият ләззәтеннән исергән, татлы уй эчендә йөзә, тирбәлә...

— Бабай, син үзең нинди сугышларда булдың? — дип сорады Мөҗәһит.

Хәсән бабай 1904—1905 елларда рус-япон сугышларында катнашуын, томанлы диңгез өстендә үзләренең корабльләрен кыяга бәрелүдән ничек саклап калуларын, рус солдатларының арысландай батыр сугышуларын бәйнә-бәйнә сөйләде. Соңыннан малайларның башларыннан сыйпап:

— Бераз ятып ял итегез,— диде.— Атлар өчен борчылмагыз, үзем карармын.

көлтә — бер бәйләмгә җыеп бәйләнгән иген (сноп)
ләззәт — куанычлы, шатлыклы хис

Сораулар һәм бирем

1. Хәйретдин Мөҗәйнең бала чагы ничек уза, шул турыда сөйләгез.
2. Хәсән бабайның әкияте Мөҗәһиткә ничек тәэсир итә? Ул үзен кайда дип һәм ничек хис итә?

«Сугыш язмалары»

Безнең кулда Мөҗәһит Хәйретдиновның «Сугыш язмалары» дигән дүрт дәфтәре бар. Аларның табылу тарихы болай: 1942 елның җәендә Көньяк-Көнбатыш фронтта немецлар каты һөҗүмгә күчәләр. Немец генералы Клейстның танк армиясе Харьковны азат итү өчен көрәшүче сугышчыларның юлын кисә. Фронтта кан коюлы сугышлар башлана. Гитлерчылар, зур көч туплап, кайбер участокларда алга үрмәлиләр, Мөҗәй командалык иткән 789 нчы полк ярым боҗра эчендә кала... Полк командиры үзенең «Сугыш язмалары»н махсус

рәвештә кызылармеец Кожевников аркылы тылга җибәрә. Кожевников, фронт аркылы чыгып, дәфтәрләрне Мөҗәйнең хатыны Мәрьям ханымга җибәрә. Мәрьям ханымнан ул безнең кулга керде.

Кожевниковны шактый вакыттан бирле эзләп карасак та табылганы юк. Ләкин эзләү эзсез калмады. Мөҗәй белән фронтта булган финанс хуҗалыгы начальнигы Дуньның исән калуы билгеле булды. Аның янына баргач, ул Мөҗәй турында шактый материаллар бирде. Дуньның әйтүенә караганда, Кожевников дивизиягә кире кайта алмаган, полк чолганышта калган, тигезсез сугышта бик күпләр һәлак булган...

Менә шул Кожевников тапшырган «Сугыш язмалары»нда Мөҗәй, дошманның тар-мар ителәчәгенә ышанып, йөрәгеннән чыккан ялкынлы сүзләрен язган:

«Бүген төнге 12 дә атака.

Бу инде безнең Прохоровкага бишенче, әгәр 8 декабрьне искә алсак, алтынчы атака.

Без Прохоровкадагы дошманның нык бикләнгәнен, бөтен ягын утлы коршау белән урап алганын яхшы беләбез. Безнең һөҗүмне дошман биш мәртәбә кире кайтарды, без аңар алтынчы мәртәбә барабыз.

Йөрәкнең әллә кайсы җирендә «Җиңәрбезме?» дигән уй тора. Ләкин «Җиңәрбез!» дигән җавап көчлерәк. Чөнки без җиңә алмый торган нәрсә бу дөньяда юк әле һәм буласы да юк!

Без төнге сәгать 12 дә атакага барабыз. Безнең барыбыз да бу дәвер сугышындагы атаканың тик штык белән генә бәйләнмәгәнен, штык сугышына барып җиткәнче артиллерия, миномет, пулемет утлары гөрләп торган галәмәт куркынычлы полоса барын да, аның артыннан һәрбер метр җиргә йөзләрчә пуля төшә торган автоматлар уты полосасы барын да яхшы белә. Без бу утлы полосаларны үтәргә, дошманның йөрәгенә штык һәм гранаталар белән барып керергә аз гына да шик тотмыйбыз.

Бу атнадан соң, бәлки, безнең бик күбебез өчен Прохоровка да, дөнья да юк булыр. Без моны да бик яхшы аңлыйбыз. Ләкин минем үлемем әле Ватаным, сыйныфым үлүе түгел ич. Шулай булгач, без:

— Безгә үлем юк! — дибез».

Ут эчендә язылган «Сугыш язмалары» шактый калын. Аны укыганнан соң, Мөҗәйнең сугыш картиналарын вакый-

галарның иң хәвефле, куркыныч вакытларында да, каршында үлем көткәндә дә, көне, сәгате белән язып баруына, дошманның һәм безнең көчләргә дөрес бәя бирүенә, барыннан да элек оптимист булуына сокланасың. Юк, бу дәфтәрләрдә курку, каушау турында бер сүз дә язылмаган!

Мөҗәй, Муса Җәлил кебек, фашизмны гаепли, аның кабахәт, ерткыч йөзен бөтен халыкка ачып күрсәтә, фаш итә. Дүртенче дәфтәрдә фашистларның ерткычлыгы турында Хәйретдин Мөҗәй, нәфрәтләнеп, болай дип яза:

«Урман арасында бер үле гәүдәгә очрадым. Ул башы белән гарепкә (көнбатышка) таба ята. Куллары да шул якка, үргә сузылганнар. Немецларны куганда һәлак булган булса кирәк.

Әйләндерәм.

Уң күзе чокып алынган. Аяк киемнәрен салдырганнар... Күкрәгендә — пычак эзләре. Аркасында — сөягенә кадәр телгән йолдыз. Ниндидер «профессор» бер дә ашыкмый гына «операция» ясаган... Бәлки, аның өчен берәр фашист тимер тәре белән бүләкләнергә уйлагандыр. Бәлки, билгесез сугышчы өстендә канлы эшләр эшләгән фашист та тимер тәрегә ирешә алмый, шушы үлекләр арасында ятадыр. Ята, һичшиксез ята! Шул, тик шул гына көтә ул фашистларны! Алар, һичшиксез, һәлакәткә хөкем ителгән кешеләр!

Билгесез кызылармеецның үле гәүдәсе. Моны күрәләр, бер гәүдә өчен дошманның унысын егалар, һәркемдә үч, һич бетми торган үч кайный!»

Язмаларның икенче җирендә болай язылган:

«Гитлерчылар саранча кебек алар, аяк баскан урыннарында бернәрсәне дә калдырмыйлар. Нәрсә күрсәләр, шуны ашыйлар. Кием-салымны талыйлар, халыкны ач үлемгә калдыралар. Аз гына каршы килүче булса да асалар, аталар. Хатын-кызларны мәсхәрәлиләр... Без Призначное авылында. Бу авыл немецлар кулына кергән иде. Авылны безнең сугышчылар шул ук көнне кире алдылар. Бүген берничә хатын һәм балалар, картлар белән сөйләшергә туры килде.

Авыл читеннән өченче өйдә торган хатын мондый нәрсә сөйли:

— Минем өйдә барлыгы 40 тан артык немец солдаты булып чыкты. Бер төркем керә, икенчесе чыга. Күзләренә күренгән һәрнәрсәне алалар... Юбка, панталон, тастымалларны алдылар. Икенче төркем мендәр тышларын салдырды, одеял, шәл һәм яулыкларны капчыкларга тутырды. Өченче төркем,

сандыктан бернәрсә дә таба алмагач, марляга төрелгән синьканы, соданы, сабынны, шкафта торган пудраны алып чыгып китте. Дүртенче төркем, шыр өйгә кергәч, аптырап калды. Бер солдат почмактагы дегет чүлмәгенә бармагын тыгып, бал дип ялап карады. «Мидә-мидә!» — дип кычкырды. «Юк»,— дигәч, ачуланып, үкереп, чүлмәкне тибеп аударды. Ахырдан, бернәрсә дә таба алмагач, бозау муенчагын алып, биленә урады.

Бу тик бер хатынның гына сөйләве. Икенче урамда алар агалы-энеле ике картны чәнчеп үтергәннәр».

Фашист армиясенең көчә бетә баруы, башта «герой» булып атакага күтәрелүләре, безнең сугышчылардан үзләренә «кучтәнәч» эләккәч, зур югалтулар белән чигенүләре, оборона ныгытмаларына сукыр тычкан кебек посулары турында көндәлектә без тагын түбәндәге юлларны укыйбыз:

«Немецлар «өннәреннән» чыкмыйлар. Бүгенге разведка вакытында кызылармеец Матвеев, ПТРдан атып, бер танкларын җимереп ташлады. Башта «герой» гына кылә торган 6 танкның берсе башы тишелгәч тә туктады. Немецларның болай тик ятуларына беренче сәбәп — җимерелгән полклар җыйналмасы — сбор булуы».

Фашист солдатлары һәм офицерлары рус кышының салкынлыгына чыдый алмыйча өшиләр, халыкның өс-башын талап киенәләр, одеялларга, бала юрганнарына төренәләр. Бу турыда Хәйретдин Мөҗәй бик үткен итеп яза:

«Гитлер солдатларын гына түгел, офицерларын да яхшы киендерә алмый. Буранлы көннәрдә аның солдатлары, кунадагы тавык кебек, тышка чыгып керергә дә курка... Без аларны аулыйбыз».

«Сугыш язмалары»нда Мөҗәһит Хәйретдинов үзенең туып үскән урыннарын, ямьле Ык суын, яшел болыннарны бик сагынып искә ала.

«Без урманда. Июль. Бу бит — җәйнең җиткән кыз кебек матур ае. Аның көннәре дә, көннәреннән бигрәк төннәре матур булалар.

Ә урман!

Борынга хуш ис, күкрәккә саф һава бирә торган урман! Нарат урманы, ә!

Билгеле, июль аенда чебен-черкиләрнең дә ишле вакытлары була... Бу урманда берничә көн буена барган сугыш нәтиҗәсендә хасил булган үле гәүдәләрнең исләре дә, газ исләре

дә юк түгел. Шулай булса да урман — урман, бернәрсәгә карамыйча аның сандугачлары да сайрый, чикерткәләре дә кычкыра. Атулар тукталып торган араларда бу урманда һаман да тыныч вакыттагы кебек...

Мин биш-алты яшьтән башлап унҗиде-унсигез яшькә чаклы урманда тордым. Минем әти урман каравылчысы иде. Бер елны, көзнең ифрат суык бер көнендә, кемдер безнең хутор тәрәзәсен какты. Мин Миңлешаһ дигән ике яшькә олы иптәшем белән генә идем. Без аңар:

— Без куркабыз, ачмыйбыз,— дидек. Ул безгә:

— Курыкмагыз, мин урман карагы түгел, каравылчыны кыйнарга күсәк күтәреп килгән кеше дә түгел...— диде.

Без ачмадык».

Урман Мөҗәһиткә кече яшьтән үк таныш. Ул балачакта ук качкыннар турында әкиятләр тыңлаган. «Сугыш язмалары»нда әнә шулар турында язып китә дә чын качкыннар, ватанын ташлап качкан дезертирлар, дошманга сатылган хыянәтчеләр турында йөрәктән чыккан иң көчле нәфрәтен белдерә.

«Качкын — нинди кабахәт исем!

Бу исем тагылган кешенең йөзе — кабахәт, нәфрәтле йөз. Ул,— Илен, Ватанын онытып, хезмәттән качкан кеше. Ул — антын бозган кеше. Ул — туган һәм туачак балалар тарафыннан да каргала торган кеше. Качкын. Бу кешегә дару — бары тик үлем! Аңа халык җәзасы белән үлем бирелергә тиеш!

Качкын! Берәр иптәшең, атаң яисә анаң фашистлар угы белән яраланып кан эчендә ятканда, аңарга бер ярдәм күрсәтмичә ташлап киткән оятсыз кеше түгелме син?!

Әйе, син шул, кабахәт!

Сине кызгану юк!

Сине чәнчеп үтергән кешеләр — мактаулы патриотлар! Сиңа үлем, үлем, үлем!»

Халыкның сугышчыларга зур ярдәм итүен Хәйретдин Мөҗәй дәфтәрләрендә берничә урында яза. Шундыйларның берсендә Х. Мөҗәй дәһшәтле сугыш кырларында — окопларда һәм землянкаларда — туган ягын сагынып, аның эшчән, тырыш кешеләрен мактап искә төшерә. Ул Башкортстаннан килгән бүләкләрне һәм хатларны аерата зур шатлану, дулкынлану белән ала. Бу бүләкләрдә һәм хатларда никадәр йөрәк җылысы, никадәр хис һәм җиңүгә ышаныч бар!

Мөҗәйгә туганнары әледән-әле хатлар язып торалар. Төрекмән авылындагы бик күп ирләрнең, шул җөмләдән дүрт туганының фронтта батырларча сугышуларын, тылда калган олы яшьтәгеләрнең, балаларның һәм хатын-кызларның дошманны җиңү өчен бөтен көчләрен биреп эшләүләрен белдерәләр, Мөҗәйнең фашистларны тар-мар итеп туган җиргә тизрәк кайтуын телиләр. Полк командиры М. Хәйретдинов аларның бу изге теләкләрен үтәп чыгу өчен бөтен көчен, сәләтен бирә, якташларының, халыкның ышанычын аклау өчен утларга керә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Хәйретдин Мөҗәйнең «Сугыш язмалары» дәфтәре табылу тарихы турында сөйләгез.
2. Бу язмаларда нинди вакыйгалар тасвирлана?
3. Язмалар аша Хәйретдин Мөҗәйгә хас сыйфатларны әйтегез. Бу сыйфатларның кайсын үзегездә булдырыр идегез? Ни өчен?
4. Фашистларның ерткычлыгын язмалар авторы ничек сурәтли?
5. Туган ягы кешеләреннән хатлар, бүләкләр алу Хәйретдин Мөҗәйгә ничек тәэсир итә?

Тоткынлыкта

Мюнхен.

Зурлыгы ягыннан Германиядә өченче урында торган промышленность үзәге. Бу шәһәрдә сугыш кораллары эшли торган заводлар, хәрби полигоннар һәм җир асты аэродромнары бик күп.

Әсирләрне Мюнхенга куып китергәннәр һәм авыр эшләрне башкарырга мәҗбүр иткәннәр. Хәрби заводлардан читтәрәк, Штадельгейм төрмәсе һәм иске зират арасындагы Шванзее урамында хәрби әсирләр өчен лагерь төзелгән. Анда 1941—1942 елларда әсир ителгән рус офицерларын ябып тотканнар. Фашистлар лагерь урнашкан урамны «Аккош күле» (Шванзее — Аккош күле дигән сүз.— *С. Ш.*) дип атасалар да, чынында бу — мәет исе аңкып торган күңелсез, пычрак урамнарның берсе булган.

Ток җибәрелгән тимерчыбык киртәләр белән әйләндереп алынган бу үлем «утравы»нда озын, килбәтсез бараклар тезелеп киткән. Анда әсирләр интегәләр, авырулар ыңгырашалар, ютәллиләр...

Айлар буе бер лагерьдан икенче лагерьга йөртә торгач, Мөҗәһитне дә шушы упкынга китереп ташлыйлар. Әсирлек-

кә төшүенең беренче көннәрендә үк фашистлар аның полк командиры икәнлеген белеп алалар һәм «яхшы мөнәсәбәт» күрсәтергә тырышалар.

Автоматларын муеннарына аскан сакчылар әсирләрне сүгә-сүгә таш чыгара торган тау итәгендә эшләтәләр. Ябык, шыр сөяккә калган кешеләр зур-зур ташларны өч чакрымлы «казан»га ташыйлар. Монда җир асты аэродромы төзелә. Мөҗәһит тә — әсирләр арасында.

Лагерьның блок-фюреры, аның янына килеп, ясалма елмаеп, төче телләнде.

— Без,— диде ул, һаваланып,— хәрби әсирләргә сез уйлаганча ук начарлык эшләмибез.— Мөҗәһитнең эре сөякле зур гәүдәсенә күзлек аркылы карап торды да, бөеренә таянып, сүзен дәвам итте.— Аерата сезнең кебек югары чинлы Гулливерларны саклап калырга тырышабыз,— дип, черек тешләрен күрсәтеп көлде.

Бу нәрсәгә Мөҗәһит бер дә гаҗәпләнмәде. Чөнки фашистлар үтә хәйләкәр һәм явыз иделәр. Алар, шулай йомшак күңелле, кешелекле булып кыланып, әсирләрнең иң нечкә кылларына кагылалар, йөрәкләренә үтеп кереп, психологик йогынты ясарга уйлыйлар. Кайбер йомшак табигатьле кешеләр мондый мөнәсәбәткә бирелүчән була. Мөҗәһит исә бу тозакны беренче көннән үк җимерергә теләде. Кызыл буяу белән «Р» хәрефе куелган күкрәгенә төртеп, җавап бирде:

— Мин бернинди дә Гулливер түгел! Әгәр дә миннән нәрсә дә булса көтәсез икән, бик нык ялгышасыз,— дип, дүрткырлы авыр ташны күтәреп китә башлады.

Төлке кебек хәйләкәр, озак еллар буена шушы эштә эшләп, шомарып беткән фашист аңа каршы:

— Гитлер сезнең ише хәрби эшлеклеләргә аерата мәрхәмәтле,— диде.

Мөҗәһит аңа ачулы кычкырды:

— Сезгә Гитлер ул, ә миңа...

Ул сүзләрен әйтеп бетерә алмады, сакчыларның берсе автомат прикладьы белән Мөҗәһитнең аркасына шундый каты сукты, ул җиргә ауды.

Мөҗәһитне күтәреп торгыздылар. Аның хәле юк, күзләре йомык иде. Бер әсир сулы савытны Мөҗәһиткә эчерергә сузган иде, сакчыларның берсе аңа резин шланг белән сукты. Әсирләр сакчыга чәйнәп өзәрдәй булып ачулы карадылар. Немец тагын шлангысын күтәрде, ләкин әсирләрнең берсе

аны тотты. Бу хәлгә шартлардай булган кансыз палач автоматтан озын очередь бирде. Ике кеше үтерелде, өч кеше яраланды.

Немец, бу күренешкә бер дә исе китмәгән кыяфәттә бөеренә таянып, менә мин нәрсә эшли алам дигәндәй, масаеп басып торды. Аның уенча, ул гына дөньяга хуҗа иде. Әнә шулай кыргый кәперенү белән басып торганнан соң, ул таш күтәреп китеп баручы бер әсирнең кабыргалары чыгып торган ябык тәненә күрсәтеп:

— Барыгызны да шундый хәлгә төшерәбез! — диде. Тәртсәң түнәргә торган, скелетка гына калган әсир, зур күзләрен йомып, әкрен генә баруын дәвам итте. Сакчы аның тәмам җелегенә төшәргә теләде булса кирәк, шаркылдап көлә-көлә өстәде:

— Соңгы көннәрен санап атлый ул...

Мөҗәһит бераз аңга килгән иде. Ул мондый вәхшилеккә нәрсә диярге дә белмәде. Аның күз алдына туып үскән Төрекмән авылы, җырларда макталган, бормаланып ага торган Ык суы килеп басты. Әнә аның укып йөргән мәктәбе. Әнә Армиягә киткән олы юл, авыл капкасы... Армиядән ялга кайткан чакларда туган-тумачаларының аны зур хөрмәт белән каршы алулары, апасы Хаҗуафаның: «Кайттыңмы, энем, бик озак көттердең»,—дип, ике кулын сузып күрешүе, сөйгән кызы белән очрашулары, сөйгән кызының аңа карап: «Бик еракта — Урта Азиядә булсаң да, син һәрвакыт күңелем түрендә»,— дип, аның бил каешыннан тотып, серле елмаюы...

Мөҗәһит, башын түбән иеп, яшьле күзләрен сөртеп алды. Эченнән генә көрсенеп:

— Бу хурлыкны күргәнче,— диде ул,— Туган илемнең изге туфрагында һәлак булсам, никадәр әйбәт булыр иде.— Өзгәләнде, башын ике кулы белән тотып елады.— Юк шул, булмады, батырларча сугышып үлү насыйп булмады...

Мөҗәһит шундый нәтиҗәгә килде: фашизмның үз оясында кискен көрәш оештырырга!

Ул «Р» хәрефе белән үзенең номеры куелган буй-буй сызыклы пижамасына җирәнеп карады. Бу пижама аңа пакь намусын пычратып торган шыксыз кием булып тоелды. Аның бу хурлыклы киемне салып ыргытасы һәм, палачларның битләренә төкереп:

— Саф күңелле, вөҗданлы, Ватанын сөйгән чын кешеләрне сез нинди түбәнлеккә төшердегез! Европаны канга батыр-

дыгыз, миллионнарча кешеләрне кырасыз! Моның өчен җавап бирерсез! — дип кычкырасы килде.

Мөҗәһит теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгалды, аркасының авыртканлыгын сиздермәскә тырышып, тешләрен кысып, әкрен генә атлады. Лагерьның яшерен оешма членнарына ымлап кына аңлатты: «Эштән кайтканда очрашырга».

Әсирләр әкрен генә таш чокыйлар. Аларның күбесе бил тиңентен ялангач, гәүдәләре шыр сөяк. Кан тамырлары беленеп торган зур башлары аларны бик килбәтсез күрсәтә. Менә дүрт кеше җигелгән, таш төялгән арба тау куышыннан килеп чыкты. Ат урынына җигелгән әсирләр бер казылмада зур көпчәкле тупас арбаны чыгара алмый шактый азапландылар. Сакчыларның берсе алар өстенә этен өстерде. Эттән куркып төрле якка йөгерешкән әсирләргә немец автоматтан озын очередь бирде. Ул, үзенең бу җинаятен оятсыз рәвештә акларга теләп булса кирәк:

— Кая качасыз, дуңгыз токымнары?! — дип акырды. Фашист палачлары лагерьда әнә шулай варварлык иттеләр. Алар күз күрмәгән, колак ишетмәгән яңа җәзалар уйлап табалар иде.

Лагерьның сул ягыннан ике әсирне алып киттеләр. Алар — шактый таза, хәтта, башкалар белән чагыштырганда, итләч, тулы гәүдәле кешеләр. Бу әсирләрне Мөҗәһитләр барагында яхшы беләләр. Аларның берсе — француз, икенчесе — рус. Бу ике әсирне Берлиннан килгән немец врачлары сайлап алдылар. Аларны, ашатып-эчертеп симерткәннән соң, салкын су сибеп өшетергә һәм яңадан терелтергә, шулай эксперимент ясарга уйлыйлар. Үзләрен ни өчен ашатуларын бу әсирләр белмиләр иде.

Врачлар арасындагы бер хирург бу кешеләрнең язмышы турында яшерен оешманың бер членына әйткән.

Бу кешеләрне коткару өчен әсирләр зур эш алып бардылар: аларны качыру планы эшләнде, лагерьдан чыккач киендерү өчен киемнәр әзерләнде.

(Хәйретдин Мөҗәй һәм аның көрәштәшләре фашизмга каршы хатлар, листовкалар язып тараталар, немецларга каршы коралллы восстание әзерлиләр. Ләкин араларына үтеп кергән бер хыянәтче аларның бу планнарын фашистларга ача. 1944 елның 4 сентябрендә оешма әгъзалары атарга хөкем ителә... Менә автоматлардан ату тавышлары яңгы-

рый... Әле үлеп тә бетмәгән көрәшчеләрне крематорий мичендә яндыралар. Алар арасында подполковник Хәйретдин Мөҗәй дә була.

Мюнхен һәм Дахау лагерьларындагы коточкыч газаплар, кыйнаулар, ач тотулар шагыйрьнең рухын сындыра алмый. Данко йөрәкле бу кеше үлем лагеренда да батыр, куркусыз булып, Туган иленә тугрылыклы кала.)

һавалану — масаю, кәпрәю
түнү — егылу

Сораулар һәм биремнәр

1. Фашистларның кешелексезлеге нәрсәләрдә күренә?
2. Мөҗәһит ни өчен «Фашизмның үз оясында кискен көрәш оештырырга!» дигән нәтиҗәгә килә?
3. Х. Мөҗәйнең лагерьдагы тормышы турында сөйләгез. Яшерен оешма нинди эшләр башкара?
4. Ни өчен әсәр «Үлемнән көчлерәк» дип атала?
5. Әсәрне тулысынча укыгыз.

Очерк

Очерк — авторның үз күзе белән күргәнне тасвирлап сөйләп чыгуга корылган чәчмә әсәр.

Очерк кешеләрнең аерым сыйфатларын, табигать күренешләрен тасвирлау белән генә чикләнми, персонажларның эш-хәрәкәтләрен, уй-фигыльләрен, үзара мөнәсәбәтләрен дә сурәтли.

Очерк авторы чынбарлыкка тугры булырга, герой турында уйдырма язарга тиеш түгел. Мәгълүматы җитмәгәндә, әлбәттә, фараз итә ала. Ләкин бу очракта да тормышта булган ниндидер нигезгә таянып эш итә.

С. Шакирның «Үлемнән көчлерәк» очеркы Германиядәге Дахау лагеренда крематорий мичендә яндырып үтерелгән татар шагыйре, полк командиры Хәйретдин Мөҗәй һәм аның сугышчан дусларына багышлана. Автор башта фашистларның Мюнхен һәм Дахау лагерьларындагы коточкыч ерткычлыкларын фаш иткән материалларга, документларга таяна, ә аннан соң, истәлекләргә нигезләнеп, Мөҗәйнең балалык һәм яшьлек еллары турында сөйләүгә күчә.

Хәзерге вакытта очерк — газета-журналларда иң күп файдаланылучы жанрларның берсе.

Аяз Гыйләҗев
(1928—2002)

Татарстан Республикасының халык язучысы Аяз Гыйләҗев (Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев) 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туа. Бала чагы һәм мәктәп еллары Зәй районының Югары Баграж авылында уза. Унынчы сыйныфны Сарман урта мәктәбендә тәмамлый. 1948 елда Казан Дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Монда ул университет каршындагы әдәби түгәрәккә йөри, беренче иҗат тәҗрибәләре белән уртаклаша, диспут-бәхәсләргә актив катнаша. Ләкин студент егет алга таба укуын дәвам итә алмый: 1950 елның башында аны, «советка каршы коткы таратуда һәм милләтчелектә гаепләп», кулга алалар. Язучы булырга хыялланган егерме ике яшьлек егет Казакъстандагы концлагерьларда биш елга якын җәфа чигә. Аны Сталин вафатыннан соң гына ирекккә чыгаралар һәм укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирәләр.

Аяз Гыйләҗев — үзен беренче чиратта хикәя, повесть остасы итеп таныткан кеше.

«Өч аршын җир» (1962), «Зәй энҗеләре» (1963), «Урталыкта» (1969), «Язгы кәрваннар» (1972), «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» (1973), «Җомга көн, кич белән...» (1979), «Әтәч менгән читәнгә» (1979—1980) повестьларын халык бик яратып кабул итте.

Повестьлардан тыш әдипнең берничә романы да бар. «Урамнар артында яшел болын» (1969) исемле романында әхлак мәсьәләләре үзенчәлекле чагылыш таба. «Балта кем

кулында?» романында шәхес белән хакимият арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләр яссылыгында хезмәт кешесенең фаҗигале язмышы психологик нечкәлек белән сурәтләнә. «Йәгез, бер дога!» исемле роман-хатирә язучының тоткынлыкта уткәргән биш ел гомеренә багышланган.

Аяз Гыйләҗев — ике дистәдән артык драма әсәре авторы да. Аларның кубесе республика театрлары репертуарына кертелгән. Кайбер пьесалары башкорт, авар, чуваш, рус театрлары сәхнәләрендә дә куела. «Югалган бер көн» пьесасы 1977 елда Чехословакиядә словак телендә дә дөнья курә.

«Җомга көн, кич белән...» һәм «Әтәч менгән читәнгә» повестьлары өчен А. Гыйләҗев 1983 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Әдәбиятны һәм театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен аңа 1978 елда Татарстанның, 1985 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә. Ул — М. Горький исемендәге премия лауреаты да.

1994 елда Аяз Гыйләҗев Татарстанның халык язучысы дигән исемгә лаек була.

Аяз Гыйләҗев 2002 елда Казан шәһәрендә вафат була.

ҖОМГА КӨН, КИЧ БЕЛӘН...

(повестьтан өзекләр)

9

Картаюны төрле кеше төрлечә каршылый. Төрлечә кичерә. Берәүләр кинәт кенә сәламәтлеккә туймый башлый: куз начар курә («җеп сапларга кеше кирәк хәзер!»), колак томалана («и, безнең заман сарыклары «бә-ә!» дип урам тутырып кычкырып кайта торган иде, хәзерге заман малының да мәне юк, авызлары ачык, тавышлары чыкмый!»), аппетит начарлана («авызның тәме бетте, ашарга ризыгым ләззәтле тугел!»).

Икенче берәүләрнең сәламәтлегендә бер үзгәреш тә сизелми: рәхәтләнеп ашый, җеп сапларга күршеләргә йөгерми, черки безләгәнен дә ишетә, шулай да рухлары төшә, эшкә кул бармый, эш тәме югала. Элеккеге гадәтләр үзгәрә, кием-салымга мөнәсәбәт алмашына («ни кисәң дә ярый хәзер, барыбер»), кыскасы, картаю галәмәте һәркемгә төрлечә, һәркемгә

үзенчә генә килә. Я сиздерми килә, я кинәт сиздереп, күңелне өшетеп, бәгырьне суытып та куя...

Бер дә картаймас кебек йөргән Бибинур бер елны үзендә зур үзгәреш сизенде. Күзе дә әйбәт күрә күрүен, әңгердә дә нәзек энәләрне саплый ала, урамнан узган почта машинасының номерын да әллә кайдан ап-ачык абайлый, кинога барганда да алдагы рәтләргә елышмый. Колагы да сак: яз үз куәтенә кереп, карлар эреп ермакларга җырчы сулар төшә башлаганда, тәүге өлгер тургайлар килгәч, аларның язгы сәламен, гадәттә, беренче булып ул ишетә. Тургай килгәч тә тәрәзәләрнең эчке рамнарын алып куя да, өенә яктылык һәм язгы авазлар кереп тула. Алдан ук хәстәрен күреп, агач чапчакка җыеп куйган ләйсән яңгыр суы белән гөлләрен бөркепбөркеп юа да, алар үзләренең куанычлы урыннарына — тәрәзә төпләренә күчеп утыралар...

Моңарчы табигатьнең барлык үзгәрешләренә дә үтә сизгер җан иде ул: ел саен, яңа ел алдыннан числинник сатып ала да үзе аерата мөһим дип санаган вакыйгаларны, шәмәхә карандаш очы белән тырнап, шунда теркәп бара иде...

Һәм көннәрдән бер көнне бөтенесе үзгәрде. Яз көне иде. Бакчы, бөреләрне уятып җылы сулышлы җилләр килеп җитте — ә ул аларны сизми калды. Урман кары кузгалгач, таудан сугылып-бәрелеп гөрләвек ташкыннар төште, ә ул, башка еллардагы төсле, айлы кичтә, капка баганасына аркасын терәп, су тавышын тыңлап хозурланмады. Яз быел сиздермичә, канны уятмыйча, мыштым гына, астыртын гына килде, җәй дә Бибинур катнашыннан башка гына дөньяга хуҗа булып алды, болыннарны, су буйларын сихерле яшеллек белән күмде. Көзге сары яфракларга бу юлы исе китмәде аның, көз җиткәнен суык, әрсез җилләр исә башлагач кына абайлады. Беренче кар бөртекләре сихерле чәчәкләр сыман юкка гына аның тәрәзәсе алдында бөтерелеп уйнадылар, Бибинур аларга бөтенләй игътибар итмәде...

Дөнья белән алыш-биреше тәмам дип уйлау Бибинурга җиңел булмады, һич! Ике көн хатирәләр тозагыннан ычкына алмыйча мич башында боргаланып ятты. Өе тәмам суынды, тышкы кат пыялаларга катлы-катлы булып зәңгәр боз катты. Өченче көнне торды, мич башыннан төште, кочагы белән каен утыны алып керде, мич гөмбәзенә кадәр тутырып якты да, урындыгын мич каршысына тартып китереп, аңа мендәр куйды, шуңа утырды. Коры утын, гөмбәзгә сыймыйча, аңа таба

ыргылды, ул, утның мәңгелеге алдында сихерләнеп, керфек тә какмыйча байтак карап утырды...

Аннан кыстыбый пешерде.

Габдуллаҗаны кыстыбый бик ярата иде. Төпчекләре Нәҗип тә әткәсенә охшаган, кыстыбыйны бик яратып ашый иде...

Өенә җылы төшеп, ашап-эчкәч иске шәлен бөркәнде, билен яулык белән кысып буды, кар бик тирән ятканчы дип, зиратка Гайшә кабере янына китте.

Ул чакта татарлар арасында зиратка барып йөрүләр сирәк иде, карга сукмакны үзе салды.

Гайшәнең ире өчен корбан булуы, Габдуллаҗан куеныннан Гайшәнең урынын алуы Бибинурның дөньялыкта үз ихтыяры белән башкарган гамәлләренең иң олысы, иң җаваплысы иде. Яхшылык эшләдеме ул, яманлыкмы — Бибинур тулысы белән моны берничек тә бәяләп бетерә алмый иде. Шуңамы, Аксыргак кешеләреннән үзгә буларак, зиратка еш кына барып йөри, бигрәк тә язын, кар киткәч, кабер өстен чистарта, себерә, күздән җыеп куйган чәчәк орлыклары сибә иде.

Бүген менә, кагыйдәсенә каршы буларак, кар ерып бара...

Адымы чыпчык атламы кебек бәләкәй, гәүдәсе җиңел, әзе мамык карда да җиргә кадәр төшеп җитә алмый. Аның артыннан тоташ бер сай буразна сызылып барды, карасаң, адәм узган дип тә уйламассың!

Гайшәнең баш очында биш почмаклы йолдыз уелган ак таш тора, язуы да күңелне үтеп керерлек:

«Бу кабердә халык бәхете өчен
көрәш юлында һәлак булган
Гайшә Абдуллина ята».

Мәктәп балалары Беренче май бәйрәмендә чүлмәк-чүлмәк гөлләр китерәләр монда. Сабан туена кайткан авылдашлары да кайвакытта чәчәк бәйләме калдырып китәләр. Әмма Бибинурның Гайшәгә үз мөнәсәбәте, икесе аңлый торган гына олы мөнәсәбәт. Зиратта кеше-мазар булганда, ул Гайшә янына барып та тормый, кешеләр таралганны, зиратның тып-тын әрвахлар белән калганын көтә. Чөнки зиратка Бибинурны Гайшәнең фаҗигале үлеме генә түгел, бурычы, җаваплылык та йөртә. Бибинур алып калды ич Гайшәнең өч баласын! Аның өч баласын үстереп, тәрбияләп, үзенчә әзерләп олы дөньяга ул чыгарып җибәрде!

Балалары турында ул хәзер авылда беркем белән дә сөйләшми, аксыргаклыларның алар турында сүз кузгатканнарын яратмый, сөйләштерми дә. Балалар турында ул дөньяда бары тик бер кеше белән — аларны тудырган ана — Гайшә белән генә сөйләшә ала. Алар, ике ана, берсе тудырган, берсе үстергән ана, сөйләшә алалар. Сөйләшергә сүзләре дә күп була...

Бүген зират буп-буш... Тып-тын...

Гайшә кабере өстендәге куе ботаклы пар каенда пыр да пыр песнәкләр оча, кошлар берчакта да Бибинурдан курыкмыйлар, агач арасыннан җитез генә үтеп кергән декабрь җиле көмеш кар бөртекләрен бөтереп кузгата... Тик бу минутларда Бибинур карчык берни дә күрми, берни дә ишетми иде... Ул Гайшәнең баш очындагы ташка сарган кар бөртекләрен җиң очы белән сакланып кына кагып төшерде дә тирән көрсенеп сүзен башлады, Гайшәгә эндәште.

— Гайшә! — Аның калтыранган иреннәре арасыннан сүзе сынып, сытылып чыкты.— Менә ни уйладым әле мин: миңа да бу дөньяны кичеп сезнең янга килергә вакыт җитте бугай... Беләм, минем баш очыма берәү дә йолдыз кадамас, мин бик гади яшәдем, гомергә гади кеше булып калдым. Шулай да үкенмим, газапланмыйм, үз бурычымны үтәдем бугай. Беркем дә минем турыда яман сүз әйтә алмас. Беркем дә! Мин шулай уйлыйм, бәлки хаталанамдыр... Синең алда да гаебем бардыр, Гайшә. Булмый калмас. Мин шулай уйлыйм. Шулай дип беләм. Шуңа синең катыңа киләм. Аңлашыйк, Гайшә. Кешеләр сөйли, күп сөйлиләр. Балалар мине ташлады дип, аларны гаеплиләр... Кем уйлаган дөньялар болайга әйләнеп китәр дип... Шулай да мин аларны гаепләмим. Рәнҗемим мин аларга! Ата йортын ташладылар, диләр. Имеш, менә ничә еллар инде хат та язмыйлар! Ярдәм дә итмиләр, имеш! Анысы да хак, Гайшә, тик мин ярдәмгә мохтаҗ түгел, Гайшә, мохтаҗ булмадым да. Һичбер мохтаҗлыгым юк, Хак Тәгалә шаһит, пинсәм чыга. Авыл картларын да ташламый хөкүмәт, шөкер. Әйе, пинсәне күбрәк алып, балаларның үзләренә ярдәм иткәндә ярар иде дә... Анысы шулай, Гайшә, бик дөрес уйлап ятасың, сирәк-мирәк хат язгаласалар, икебезнең дә йөзебез ил алдында ак булыр иде. Аннары, нәнекәчләрем, берәр генә мәртәбә, ел да димим, ике-өч елга бер генә тапкыр Аксыргакның Сабан туена кайтсалар ни әйтер идек кана?! Синең катыңа җыйнаулашып, балалар белән

бергәләшеп килә алсак, ни сөенеч булыр иде дә... Әнә бит кайлардан кайталар! Беркем дә кайтмаса, кайтмый башласа, ул Сабан туеның ни яме калыр? Онытылып бетәр ул, туганнар кайда очрашып сөйләшер? Үзләренең тамырлары кайда икәнне ничек белерләр? Кем сөйләр аларга барын да? Баланың баласы — балдан татлы, диләр. Шулайдыр. Балаларның балаларын күрү насыйп булмады. Синең дә күргәнең юк! Үзем чыдар да идем, менә син анда рәнҗеп, үпкәләп ятасыңдыр сыман... Барын эшләдем мин, Гайшә, тир дә түктем, елга-елга яшь тә агыздым, тынмадым, тау-тау иген үстердем, көтү-көтү колын тәрбияләдем, бары да булды, җаным, үземә язганнан канәгать, Ходайга шөкер, мәгәр бик олы үкенечем калды — бала сөеп туймадым. Балаларның балаларын күрмәдек без синең белән!.. Балаларыбыз начар дип кеше юкка сөйли, кыенсынып ятма! Мин дә кыенсынмыйм, рәнҗемим дә. Түзик... Кеше хәлен кеше беләмени?.. Менә олы кызыбыз Хәтимәне генә алыйк... Баштан ук мәшәкатьле яши башладылар бит. Бухгалтерлар курсында укып кайтып, колхозда әйбәт кенә эшли башлаган иде. Писмәнгә, нифтегә киткән егеткә кияүгә чыкты. Яңа урында оя кору җиңелме әллә? Келәтне сүтеп саттым, бар акчасын аларга бирдем. Тимерле агач сандыкны алып киттеләр, ике пар, бәрән йонынннан гына басылган ике пар киез итек бирдем аларга, дүрт мендәр... Көзен... юган ак йоннан сырган юрган илттем! Нигә иде безгә келәт? Сиңа кирәкме, миңамы?.. Алар Писмәндә насыпушка дигән өй салып керделәр, аннан яңа өйгә күчтеләр, аннан хөкүмәт таш пулаттан аларга фатир бирде. Иске өйләрен сатып матай алдылар. Матай да эшләгән кешегә бик кирәк әйбер, хәзер җәяү йөрүләр тәмам бетте, ярты акчасын мин түләдем. «Акча күп төшә!» — дип, кияү берзаман Себергә үк күчте, анда да нифте тапканнар икән... Сабирга килгәндә, аның да үз тормышы! Аксыргак авылыннан чыгып, ташкалабыз Казанның үзендә, шәһәрнең кап уртасында өч бүлмәле квартир алып тормыш көтә башлау ансатмы әллә? Башта шкафлары фанер төсле аксылдан иде, соңрак Рига каласыннан ук диңгез буеннан кайткан караңгы шкафлар алганнар. Киленгә анысы да ошамаган. Сабир бик нык йөреп, әллә кемнәрне майлап, әллә кемнәрне җайлап чикләвек агачыннан ясалган кыйбатлы да, затлы да шкафлар, диваннар алып кайткан... Урындыкларын күрсәң син, кәкре аяклы, кәкре аркалы, утырырга куркыныч, егылып муеның сындырырсың,

икмәктер менә, Гайшә!.. Кешедән артта калсынмыни, сүзем юк, министрның памушнигы булып эшли бит Сабирыбыз, Гайшә! Барыбызга да нинди олы куаныч! Бөтен Аксыргак шакката инде, үстердең малайны Бибинур дип, бөтенесе мактый. Аннан Идел буенда дача салдылар. Дача дигәннәре хикмәт икән аның, шулкадәр кыйбатка төште, ике ел тоташ акча салып тордым. Ике ел ай саен утызар тәңкә салдым, Гайшәкәем, җәлләмәдем! Дачалары да Идел буенда бер икән шул аларның хәзер!.. Аннан машина сатып алдылар, машинага тимер түбәле, биш йозаклы таш оя кирәк икән, аңа киткән акчаны санарга куркыныч, Гайшә!.. Әле ярый, шөкер, районыбызда музей дигән бернәрсә ачтылар. Кыз чагымнан килгән ашъяулыкларны, тастымалларымны, кашагаларны, түрләмәләрне, чиккән сөлгеләремне, аякчуларны, паласларны, энҗеле калфагыма тиклем шунда илтеп саттым. Шул чүпрәк-чапракка да акча түләрләр икән! И куанды Сабир! И сөенде килен! Хат язалар да язалар болар, рәхмәт укыйлар. Алар сөенә, мин сөенәм! Музейдан килгән акчага Нәҗипкә дә өлеш чыгардым. Төпчек бала — әнкә иркәсе, баш бала — ата ярдәмчесе... Яратты бит Нәҗип диңгез буен! Ел саен бара. Элгәре ялгыз башы йөрде, өйләнгәч, хатынын алып бара башлады, кызы тугач, өчәүләшеп үк бара башладылар. Йөрсеннәр, Гайшә, күрсеннәр, замана аларныкы... Элек барына да өлгерә идем, ат та карыйм, йортта кош-кортын, терлек-туар асрыйм, җөй дә тегә идем. Теге, кылый Гомәр хатыны Мөһәлилә белән ярыша-ярыша тегә торган идек! Карчык-корчыкка гына түгел, яшь-җилкенчәккә дә бик күп тектем мин күлмәк-күнчекне, мудысын белмәсәм дә, яраталар иде, акчасы да килә иде... «Зингер» машинам бик әйбәт иде, Гайшә, арыган күңелне дә келтер-келтер күтәреп утырыр иде. Хәзер машинам юк, сөйләгәнмендер инде мин сиңа аларын, әллә нигә тагын яңабаштан кабатлап кына азапланам...

Балалар һөнәр алдылар, йортлы-җирле булдылар, машиналар алынды, гаражлар да төзелде, диңгез буйларында да рәхәт чиккәч, бер елны өчесе дә Сабан туена кайттылар...

Кияү дә, килённәр дә, балалары да юк иде мәгәр... Сөенешеп күрешкән дә идек юкса, хәерлегә булмаган икән, яңадан Аксыргакка кайта алмадылар мескеннәр... Минем тормышны яратмадылар... «Келәтне кая куйдың?» — диде Нәҗип... «Тегү машинасын ник бирдең?» — ди Сабир. «Өйне шып-шыр калдыргансың»,— ди Хәтимәм.

Бер сүз дә әйтә алмадым...

Син авылдашларга рәнҗеп ятма, Гайшә, алар болай гына, яратып, үз итеп кенә искә алалар безнең балаларны. Ятим үссәләр дә, кеше булдылар, машиналары бар, әйтәм бит, дачалары бар. Аксыргакта, Ташлыяр буенда ни кызык тапсыннар алар?.. Үз тормышлары бар, без шуңа бик риза Гайшә, икмәктер, бик риза!

Фани дөньядан бакый дөньяга мәңгелеккә күчәр көннәрем җитә бугай, Гайшә... Сизәм, бу дөнья белән алыш-бирешем күп калмаган. Ул миннән башка да бик күңелле яши. Син ачуланып ята күрмә анда, мине караңгы чырай белән каршылама! Кыямәт көнне очрашырбыз, иншалла, Габдуллаҗан да шунда булыр. Юк, юк, ул синеке!.. Синең өлешеңә кермәм, һич тә рәнҗемичә читтән генә карап торырмын. Шулай да бер тапкыр күз тутырып карарга рөхсәт итәрсең инде, Гайшә? Габдуллаҗан сиңа булыр. Миңа караганда синең хакың күбрәк, олырак! Күбрәк, Гайшә! Мин шуны белеп, минут та онытмыйча яшәдем. Мин ни биргән аңа! Син өч бала тудырдың! Син аның өчен корбан булдың. Ул ил өчен корбан булды, сез икегез дә оҗмахлылар... Син рәнҗеп ятсаң, син каргасаң, миңа тәмуг газапларын татырга туры килер. Газаплардан курыкмыйм, сине, Габдуллаҗанны очрата алмам дип кенә җаным кыйнала... Очрата алмасам, каян белим: бәхиллисеңме син мине, юкмы?! Әйе, минем өлешем бик кечкенә булды. Мин читтән ябышкан бер кыерчык кына. Балалар мине ташласа да урынында, тик сине онытып бетерүләре генә җанны кыйный бераз. Печтек кенә кыйный, Гайшә.

Я, хуш. Бездә инде кыш. Аякка таракан керә башлады. Әрвахлар, сез дә хушыгыз. Озакламый мин дә сезнең катыгызга мәңгелеккә килермен!

Ул тагын да бәләкәйләнә, адымнары тарая, гәүдәсе җиңеләя, баягыдан да сайрак буразна сызып, ул яңа сукмактан туп-туры зират капкасына таба бара башлый... Әле баш очыннан, әле яннан очып песнәкләр аны агачлыктан чыкканчы озатып баралар...

мөнәсәбәт — караш
эңгер — ярым караңгы вакыт
ермак — чокыр
хәстәрен кору — әзерләү

агач чапчак — зур агач савыт, кисмәк
абайлау — күрү
гамәл — эш

Сораулар һәм биремнәр

1. Бибинур кем ул? Аның олы яшьтә булуын каян белеп була? Ул үзендә нинди үзгәрешләр тоя һәм аларны нәрсә белән аңлатырга тырыша?
2. Бибинур зиратка ни өчен килә?
3. Бибинурның Гайшә белән сөйләшүеннән нәрсә аңладыгыз? Габдуллаҗан һәм Гайшә кемнәр алар? Балаларның әниләренә мөнәсәбәте ничек?
4. Бибинурдагы кешелеклелек сыйфатлары тасвирланган урыннарны табып укыгыз.
5. Гомере буе кешеләргә яхшылык эшләгән Бибинур *бәхет* төшенчәсен ничек аңлый?
6. Өзектән туры сөйләмнәрне табып укып күрсәтегез.

11

Менә, ниһаять, җомга да килеп җитте.

Тагын бер сикерәсе дә шимбәне узасы, аннан — якшәмбе. Базар көн. Урыс атнасы. Төрле-төрлечә атап йөртәләр ул көнне. Якшәмбедә — Сабантуй. Бүген кунаклар нygытып кайта башлыйлар. Самолетлар бүген Аксыргакка карап оча. Поездлар Кәҗә башы урамына караган юлда кабалана. Пароходлар Ташлыяр елгасына юл тота...

Бибинурның гына көтәсе дә, китәсе дә юк...

Их, менә шулай йокымсырап утырганда гына тирбәлә-тирбәлә мәңгелек елгасына кушылып китеп агасы иде! Күзгә җылы кояш төшеп торсын. Янәшәндә агачлардан төшкән чуар күләгәләр биешеп ятсын. Җылы, татлы җил иссен. Агасы да агасы иде... Оеп, тынычланып йокымсырады Бибинур. Кемдер аның исемен атап та дәшкәч, чәчрәп уянды. «Әҗәле килеп җиттеме әллә?» Сискәнеп, аягын тотып карады—каплайнар, сулышы да тигез, куркып уянган йөрәге генә шашыпашкынып тибә. «Бибинур әби-и!»

Аны чакыралар ич! Ул, кулын каш өстенә куеп, почта тәрәзәсенә карады. Кабаланмады, ашыкмады. Ачык тәрәзәдән үрелеп, Миңлегөл кул болгады.

— Килче монда, Бибинур әби!

Йөрәге жу итеп китте: кайсысы?! Кайсысы кайта? Телеграмма бармы? Хатмы? Хәтимәме? Сабирдыр әле. Әллә Нәҗипме? Төпчеген уйлагач, ана күңеленә җылы йөгерде.

Бик озак узды ул бакча эскәмиясе белән почта арасын, бик авыр атлап. Миңлегөл ишек катына чыгып ук аны көтеп тора иде.

— Син тәгаен мине чакырдыңмы?

— Сине, Бибинур әби. Йоклап киткән идеңме әллә?

— Оятлы булдым.

— Яныңа барасым калган да, эш бик тыгыз. Бәйрәм алды бит.

— Зыян юк, Миңлегөл, зыян юк.

— Менә болай иде, Бибинур әби...

— Белмим, нәрсәдер бит,— диде ул каушап.

Миңлегөл чак кына сабыр итеп торды.

— Синең, көн туды исә, почта янына төшеп утырганыңны күреп, барыбызның да йөрәге әрни, Бибинур әби.

— И-и,— диде әби, елмайгандай итеп.— Эше юк кеше кая барсын? Мин почтага төшмим лә, бакчада гына утырам. Элек каравыл өенә җыела торган булганнар, хәзер, шөкер, бакчабыз бар.

Миңлегөл аның бер мәлдә сүрелеп киткән күзләренә карап башын чайкады.

— Болай гына төшмисең, алдашма, Бибинур әби!

— Алай ук каты әйтмә инде, Миңлегөл.

Миңлегөл ашыгыбрак сөйли башлады:

— Балаларыңнан хәбәр көтәсең син, әйеме? Ә алардан бер хәбәр дә юк. Без аларга хат язып карадык. «Әнкәгез бик тилмерә, ялгызлык яман нәрсә, ник аны оныттыгыз?» — дип сорадык.

— Кирәкмәс иде.

— Җиһангир абый кушты.

— Җиһангир?

— Әйе, ул. Сине быел ул яңа йортлы да итмәкче иде, Бибинур әби. Әллә нигә бик якын күрә иде үзеңне.

Карчыкның керфекләре яшькә чыланды.

— Балаларга кагылмаска иде!

— Сине генә түгел, бөтен авылны рәнҗетте ич алар!

— Рәнҗиләрме? — Бибинур шаккатты.— Дөрес әйтәсеңме?

— Сине җәллиләр, шуңа белдермиләр.

— Ник җәлләргә? — диде карчык җәберсенеп.— Үз көнемне үзем күрәм. Тамагым тук, өстем бөтен.

— Үзең күрәсең шул! — диде Миңлегөл кискен генә итеп.— Мин синең балаларыңның шул яманлыгы хакында газетага язган идем, редакциягә.

— Редакциягә?

— Өчесе дә әйбәт урында эшлиләр, акча алалар, әнкәләренә кулъяулык та сатып алып биргәннәре юк, дидем. Саран бакалар! Эшләгән җирләрендә аларның кемлеген белмиләр булыр, әнкәләренең соңгы самавырына тиклем талап алып киткәннәрен ишеткәннәре юктыр! Ак булып түш киереп йөриләрдер, акыл өйрәтеп! Фельетон басылып чыккач, сикерешерләр, эссе табага басарлар әле!

Тарта Бибинурның керфеге, үтереп тарта. Колагы шаулый, башы әйләнә, күз төпләре чамасыз кычыта!

— Ничек дидең син, ничек? — Ул кечерәеп, йомарланып болдырга барып утырды.— Кабатла әле!

— Эссе табага бастырам мин аларны,— дим!

— Кирәкмәс иде, хата кылгансың,— дип кабатлады ул, тәмам хәле китеп.

— Әле генә Казаннан шалтыраттылар. Иртәгә редакциядән корреспондент килеп җитәчәк.

— Ни өчен?

— Асылда ул безнең Аксыргак Сабан туен газетага язачак. Берочтан сезнең аянычлы хәлне дә тикшерәчәк.

— Мин нишлим ди инде хәзер?

— Өеңдәрәк тор, Бибинур әби. Шул гына. Бер кыздырыйк әле шул кансызларны, башкаларга да сабак булыр, кыздырыйк! Күптәннән кулым кычытып йөри иде инде! — Миңлегөлгә «кыздыру, биетү» бик хуш килергә тора иде, ахрысы, ул кемнәрнедер күз алдына китереп көлеп җибәрде.— Бирешмә, Бибинур әби!

Гаҗәп, инде тормыш белән алыш-бирешең бетте дип тынычланганда гына тагын бер мәрәкәсе килеп чыга! Бу мәрәкәсе башкаларына караганда куркынычрак булмагае әле: бусы аның үзенә түгел, балаларына яный!

Кичә, өченче көн, атна буе үз хәле хәл булса, бүген балалар турында уйларга кирәк. Алар турында аннан-моннан гына уйларга ярамый, җиңел генә уйлап булмый, Бибинур балалары турында җиңел уйларга гадәтләнмәгән дә! Балаларының һәр адымын ул сагаеп күзәтте, аларның һәрчә

теләкләрен үтәргә әзер торды, кулыннан килгәнне үтәде дә... Хәзер генә, башына ялгыш авыр әйбер төшкән кебек, ияге түшенә тиде, арт чүмече сулык-сулык килеп сызлады, колагында ниндидер ят тавыш быжан выжлаган кук, бимазалап тора башлады...

Ул ашыга-ашыга өенә кайтты, нигәдер капка биген элде, ишеккә таяк терәү салды. Түргә узды, өстәл янына утырды, терсәген өстәлгә, кайнар яңагын учына куйды...

Кинәт күк күкрәде, үз уйларыннан үзе каушап төшкән Бибинур тагын ләхәүләсен укыды, идәнгә чүкте. Күк түгел лә, капка кагалар икән! Әнә ич шакылдаталар! Кайсыгыз йөри анда, тагын кемгә ни кирәк? Ник онытып тормыйсыз аның дөньяда барлыгын! Бер бүгенгә генә булса да онытыгыз! Юк бит ул, күбәләктәй җаны очып чыгарга талпына! Сәкесенә менеп ята да, кулларын түшенә кушырып, күзләрен йома. Бетте. Вәссәлам! Җиһангир оланның җанын вакытсыз кыйган әрсез әҗәл, син кайда йөрисең? Нигә буташтырып керәсең син ишекләрне? Нигә? Сан өчен генә булса, нигә Бибинурның актык гомерен аңа бүләк итмәдең? Бу көннәрне ул күрер иде, ул!.. Бибинурга нигә бу көннәр? Аның катына әҗәл түгел, иртәгә Казан кешесе килеп керер. Төпченер. Казыныр...

Ул сөрлегеп, алга иелеп ишегалдына чыкты.

— Карчык, капкаң нигә бикле?

— Ә, бая, күк кинәт күкрәгәч, онытылып бикләп кергәнмендер шул.

Ачык капкада Зәкия карчыкның бөтен җыерчыклары нур белән тулы чырае балкыды.

— Карчык, олы улым кайтып төште. Бүген берүк кичкә чәйгә керергә онытма. Менә сиңа күчтәнәче дә бар.

Зәкия күршесе, юка, шома кәгазьне сүтеп, Бибинурның калтыранган ябык кулларына күз явын алырлык мәк чәчәкләре төшкән күлмәклек китереп тоттырды.

— Бисмилла!.. Җылы тәнеңдә тузсын, күрше. Ә бусы үземнән.

Күлмәклек өстенә шыгырдап торган өчлек ятты.

— Кайтарырга бүләгем юк бит,—дип каударланды Бибинур.— Рәхмәт, Зәкия, барыгызга да. Олыладыгыз.

— Үзе дә кермәкче иде, кая ул, бөтереп алып чыгып киттеләр. Кайта кунак, кайта кунак!.. Бу кадәр ишле кунакны күргән дә юк иде. Керер, керми калмас, боерган булса!

— Рәхмәт яусын, күрше.

Кунак, кунак... Зәкиянең олысы кайткан. Ул да укыр гәҗитне, башкалар да. «Бу Бибинур карчыкка ни җитмәгән тагын, зарланып гәҗиткә язган!» — дип уйлар халык, һәммәсе шулай дияр. Һәммәсе бер сүздә булыр. Димәк, гәҗиткә яздырмаска кирәк, корреспондент дигәннәрен Аксыргакка бөтенләй якын китермәскә кирәк, дип уйлады ул. Уйлады да тагын аптыраштa калды: юлга чыккан кешене ничек туктатасың ди инде? Бер синең өчен генә йөрми, потың бер тиен. Аксыргакның атаклы Сабан туен мәңгеләштерергә килә! Кәрточкегә төшерә торгандыр, я булмаса киногa, аннан телевизор аша бөтен дөньяга күрсәтерләр. Анда да: «Ә, бу теге Аксыргакмы әле? — диешерләр кешеләр.— Гәҗиткә дә яздылар ич аларны! Бибинур исемле корткага һаман нидер җитми икән!» Шулай диячәкләр, Бибинур аркасында шулай дип кенә беләчәкләр. Килүчене туктатып булмый, сүз дә юк. Киләчәк ул, киләчәк тә туп-туры Бибинурның йортын эзләп табып, түренә үк узачак. Чәй куяр иде — самавыры юк, «балаларым ярдәмнән ташламый!» дияр иде — өй эче шып-шыр...

Ярый, мәк чәчәкле күлмәклекне: «Хәтимә кызым бәйрәмгә салды» дияр... «Ал яулыгым да бүләк, анысы олы улымныкы!» дисәң дә, ышана инде ул килгән кеше! «Балаларым ташламады!» дип ышандырыр... Бер уйласаң, алай әйтергә дә уңайсыз шул! Хәзер кемгә барып керма, кукраеп ап-ак холодильник утыра. Стеналарда гына түгел, идәннәрдә дә кыйммәтле келәмнәр. Ялтыр-елтыр шкафлар. Кемгә Берлиннан кайткан, кемгә Бухаресттан. Казан чыгарганын алып ваксынмый хәзер авыл халкы! Ялтыр-елтыр шкафларда алтынкөмеш путалы чынаяклар, бәллүр чәркәләр. Көмеш кашыклар, көмеш чәнечкеләр. Итне дә кул белән ашау бетте, көмеш чәнечке очына гына эләктерәләр.

Ә Бибинурның ние бар? Түрендә шымытыр башы, кече ягында буш күәсе дә ярык тагарагы. Үлемтек, кәфенлек тутырган сандыгы.

Килгән кеше — йөргән кеше, очлы күз бер карауда барын аңлап алачак. Ни диде әле Миңлегөл: «Соңгы әйберләреңне талап алып киттеләр!» — дидеме? Гәҗиткә шулай дип язгандыр әле ул чытлык! Ай башсыз, ай сантый! Килүче: «Габдуллаҗан солдаттан мирас булып калган Тула самавыры кайда?» — дип сораса, ни диярсең? «Гайшә апаның төсе булып сакланган «Зингер» машинасын да күрәсе иде»,— дисә, ни дип җавап бирерсең?

Килер, язар, хәзер аны берничек тә тыя торган түгел, моннан соң Аксыргакта, авылдашларына аралашып, Габдуллаҗан белән Гайшәне белгән кешеләр арасында ул ничек яшәр? Чакырып китергәнгә әҗәл йөрми, ничек гомер итәр Бибинур?!

Димәк, бары бер генә юл кала, бары тик бер генә әмәле бар — гәҗиттән килгән корреспондентны ничек тә җайларга кирәк. «Ир кеше килсен иде,— дип теләде ул,— хатын-кызның өй эчендә күзе үткенрәк була».

Тик менә ничек җаен табарга, җаен! Акча төртсәң — алмас. Үтенеп сорасаң — тыңламас. Әмәлен табарга иде дә, кайда соң аның кулай әмәле? Әмәлен тапсаң да, өең буп-буш, самавыр очкан, җөй машинасы юк, аларсыз Бибинур — ике кулсыз!

Җиһангир нәнәм, Бибинур әбиеңнең шушы көнгә төшәсен алдан уйламадыңмыни? Әгәр син исән булсаң, баш орып синең катыңа гына барыр иде ул! Тик бүген син юк, син кузгатып җибәргән авыр мәсьәлә генә бар... Рухың да дәшми ичмасам! Тып-тын! Буаң шаулый да, яшь каеннарың нидер сөйләшә! Күтәрешсеннәр иде ак каеннар аның хәсрәтен! Тик Бибинур карчык алар ымын да аңларлык хәлдә түгел шул бүген. Эш сүздән узган, иртәгә тып итеп корреспондент килеп төшәчәк. Их, Миңлегөл, башсыз!.. Нишләргә? Әгәр түрдә самавыр балкып утырса... «Зингер» машинасы күренсә... Тегендәмонда төрле-төрле чүпрәк, эленкеләр өй эчен бизәп торса... Ул чагында аяк терәп сөйләшә ала инде Бибинур!.. Үз сүзен алга да чыгара алыр иде... Кыскасы, самавырын да, җөй машинасын да табарга, вакытлыча гына юнәтергә кирәк!.. Башка чара калмаган...

Аксыргакта бармы икән ул борынгы Тула самавыры? Калган булырга тиеш ул шәп самавыр. Капкачына һәм подносына бер төрле тамга салынган: «Тульский оружейный завод. 1926 год». Саклангандыр, нибарысы илле ел узган ич! Җөй машиналары да булырга тиеш әле, нык иде, чыдам иде ул «Зингер» машиналары! Шәйхуллаларда бар бугай, тик аларныкы аяклы машина... Миңкамалларда барын-бар, тик моңарчы йомышка йөрешмәгән кешедән ничек сорап торасың? Бәйрәм арасында эш тотам дисәң, рәнҗерләр... Кунак өстенә кунак кайтканда, кем сиңа самавырын биреп торсын!

Бибинур нәкъ үзләренеке төсле самавыр белән җөй машинасын тагын кайдадыр күрде бит... Әйе, шушы арада гына

күрде... Әһә, Җиһангирны соңгы юлга озата баргач, аларда, әтиләрендә, кызыл сакаллы Вәли картларда күрде.

Аларда сакланган әнә, Бибинур гына саклый алмады. Җырлый торган үтә борынгы сәгатьләре дә бар иде. Аны да алып киттеләр. Керосин лампасын да калдырмадылар. Пыяладан койган озынча ике ваза бар иде, чәчәк кадап куя иде Бибинур, аларын Хәтимә бик ошатты. Күзләренә ни күренсә, шуны йомдырдылар. «Иске әйберләр модада!», имеш. Менә хәзер каһәр суккан мода аркасында балтасы суга төшкән кеше күк аптырап утыр инде! Әнә Вәли карт ярма ташына тиклем саклаган. Киленнәре, усал булса да, бер нәрсәне дә алып китмәгән бит.

Ишекле-түрле байтак исәнгерәп йөргәннән соң, Бибинур бер акылга килде: «Әйе, мин аларга серне ача да алам, әйберкараларын бер көнгә сорап тора да алам. Вәли картта башка әйберләр дә булырга тиеш. Җиһангирның әткәсе мине бу бәладән йолып алачак!»

Үз тапкырлыгына үзе сокланды бүген Бибинур, сөенеченнән хәле җиңеләеп китте, күз карашы гына түгел, адымнары да мәгънә алды — сабыр гына, барын уйлап, бөртекләп очына чыгып. Тегәрҗеп авылына барырга әзерләнә башлады.

тәгаен — төгәл, ачык, анык
җәберсенү — үпкәләү, кимсенү, рәнҗү
мәрәкә — гаҗәп хәл; мәзәк
быжан — бөҗәк (шершень)
бимазалау — тынычсызлау, борчу
әҗәл — үлем
каударлану — ашыгу, кабалану
бәллүр — хрусталь
чәркәләр — савытлар
күәс — камыр әчетү өчен савыт
исәнгерәү — аңгыралану, аптырап калу
йолып алу — коткару

Сораулар һәм биремнәр

1. Бибинур карчык ни өчен көн дә почтага килә?
2. Миңлегөл аңа нинди хәбәр әйтә? Бибинурга бу хәбәр ничек тәэсир итә? Ни өчен Бибинурның корреспондентны китертәсе килми?
3. Күршеләре Бибинурны хөрмәт итәләрме?

4. Ни өчен Бибинур самавыры һәм җәй машинасы юклыкка борчыла? Ул нинди карарга килә?
5. Әсәрне тулысынча укыгыз.
6. Мәкальләрне укыгыз һәм мәгънәләрен аңлатыгыз.

1) Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен.

2) Картлык шатлык түгел.

3) Картларга юл куй, үзең дә картаерсың.

4) Бала чакта олылардан курыксаң, олайгач, балалардан куркырсың.

Илдар Юзеев

(1933—2004)

Татарстан Республикасының халык шагыйре Илдар Юзеев (Илдар Гафур улы Юзеев) 1933 елның 3 гыйнварында Башкортстанның Яңавыл районы Ямады авылында укытучылар гаиләсендә туа. Шунда урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1950—1954 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала. Хезмәт юлын журналистикадан башлый: башта «Пионер» (хәзерге «Ялкын») республика балалар журналының җаваплы секретаре, аннары «Чаян» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. «Казан утлары» журналының шигърият бүлегенә җитәкчелек итә.

Илдар башлангыч сыйныфларда укыганда ук шигырьләр яза башлый. Мәктәп чоры шигырьләре Уфада чыга торган «Әдәби Башкортстан» (хәзерге «Агыйдел») журналында, «Кызыл таң» газетасында басыла.

Илдар Юзеев, үзенчәлекле шагыйрь буларак, илленче-алтмышынчы елларда формалаша. Аның шигъри таланты аеруча поэма жанрында ачыла. Ул — ике дистәдән артык поэма авторы. Аның «Тормыш җиңә» (1951), «Таныш моңнар» (1955) исемле беренче әсәрләрендә сурәтләрдәге аһәңлелек, лирик моң, ихласлык, тирән кешелеклелек сыйфатлары ачык төсмерләнә.

Шагыйрь шуннан соң язган шигырь һәм поэмаларында («Әнкәй» (1959), «Фәрит — Фәридә» (1959), «Язылмаган поэма» (1964), «Соңгы сынау» (1968), «Канкай угылы Бәхтияр» (1970), «Таш диварлар авазы» (1973), «Өзелмәс кыллар» (1977) һ. б.) тарихи үткәнгә мөрәҗәгать итә, кеше рухының

бөеклегенә, туган җире, халкы белән какшамас бердәмлегенә дан җырлый, һәртөрле явызлыкка, шәфкатьсезлеккә, ялганга каршы нәфрәт хисләре гәүдәләндерә.

Шагыйрьнең бик күп шигырьләренә көй язылган. Халык арасында киң таралган «Яшь наратлар» (Җәүдәт Фәйзи музыкасы), «Бөркет турында баллада», «Кайтам инде» (Сара Садыйкова музыкасы), «Мәтрүшкәләр» (Азат Гыйләҗев музыкасы), «Кыр казлары артыннан» (Мәсгут Имашев музыкасы) һәм башка күп кенә җырлар И. Юзеев иҗатының үзенчәлекле бер тармагын тәшкил итә.

Илдар Юзеев драматург буларак та таныла. Җыр кебек моңлы, шигырь кебек тирән мәгънәле «Янар чәчәк», «Кыр казлары артыннан», «Кайтмый калсам, көтәрсеңме?» пьесалары үзешчән һәм халык театрлары сәхнәләрендә күп тапкырлар куела.

Шигырьләре һәм поэмалары, театр сәнгатен үстерүдә куйган хезмәтләре өчен Илдар Юзеевка Татарстан Республикасының Муса Җәлил исемендәге яшьләр һәм Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре, Татарстанның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә.

1993 елда Илдар Юзеев Татарстанның халык шагыйре исеменә лаек була.

Илдар Юзеев 2004 елның 21 декабрендә Казанда вафат була.

ТАНЫШ МОҢНАР

(поэмадан өзекләр)

Институтка бер кыз килде

...Август иртәсендә
Институтка
Бер кыз килде.
Сумка — кулында.
Ак күлмәктән.
Гүя бер күбәләк,
Очып килеп зәңгәр болыннан,
Карап тора:
Кунып булыр микән,
Ай-һай биек, диеп бу чәчәк.

Юк,
Бу — чәчәк түгел,
Бу — куаныч,
        шатлык,
                яшьлек,
                        бәхет, киләчәк!
Ул студент булыр,
Әнисенә
Сөенә-сөенә язар хатларын:
«Әнкәй бәгърем,
Мин бәхетле бүген —
Институтка таба атладым».
Тик, нигәдер,
Кайчак шундый моңсу булып китә...
Нәрсә җитми аңа,
            ни җитми?
«Көлемсерәп карауларың
Күз алларымнан китми».
Кара чәчле, кыска буйлы егет
Көлемсерәп басып тора да
Әллә кая китеп югала.
Югала...
Үзе Резидәнең йөрәгенә
Ефәк тасма булып урала.
Тик шул чакны трактор гүли башлый.
Тузан чыга...
Ул егетнең
Ак тешләре генә күренә.
Бер минутка гына Резидәнең
Мәхәббәте тагын сүрелә.
Кем гаепле? Белмим...
Нигә? Нигә
Һаман бергә барып булмады?
Аерылдык. Инде төрле якка
Алып китте тормыш юллары.
...Резидәбез менә имтиханда,
Каушый-каушый ала билетын,
Билет, билет,
Бик үк авыр булма —
Якынайт син бәхет минутын.

В. Е. Булатов рәсеме

...Ул бит бүген соңгы имтиханын
Биреп чыгар.
Шундый арылган,
Йөрәк чәчәкләрнең хуш исләрен,
Август матурлыгын сагынган.
Көләргәме хәзер,
Еларгамы?
Нигә күңел шулай ашкына?
Йокламаган төннәр, зур хыяллар
Хәл ителер тиздән барсы да.
Кил син, бәхет,
Кил син,
Озаклама,
Йөрәк көтә сине, чакыра.
Кил син, бәхет,
Бөреләнгән яшьлек,
Якты киләчәгем хакына.
Резидәбез әле көлеп ала,
Әле маңгаена тотына,
Әле йөри,
Әле зур залдагы
Урындыкка килеп утыра...
...Менә Резидәбез, дулкынланып,
Билет алды.
Билет алды да
Тетрәп куйды,
Ап-ак чәчле
Бер абыйны күргәч алдында.
Күзләреңә карап, укытучы
Җавап көтә әнә үзеңнән.
Ә син...
Нигә бераз гына сөйләдең дә
Телсез калдың?
Әллә...
Резидә!
Каушама, Резидә,
Күтәр башың,
күтәр югары!
Канатланып вузга килүеңне,
сынау бирүеңне
оныттыңмы әллә?

Калдыңмы әллә кинәт югалып?
Дәшмисең...
Укытучы синнән җавап көтә.
Сөйләшмисең,
Нинди хәсрәт алсу йөзеңдә?
Тып-тын бүлмә
тирән уйга калган.
Нишләдең син,
Нишләдең син, сеңелем Резидә?..
Ул өстәлдән башын күтәрде дә
Яшь аралаш өзелеп карады:
«Белмим... абый...
бу сорауны белмим...»
Күзләр... күзләр...
Аермыйлар акны-караны.
Томан басты гүя,
Күзләренә
Шуып төште маңгай чәчләре,
Иптәш кызы нидер әйткән иде...
Дәшмәде.
Кызлар, дәшмәгез.
Кызлар,
Юатмагыз,
Хәзер соң инде...
Борылды да, башын түбән иеп,
Ул урамга чыгып йөгерде.

моңсу — күңелсез
көлемсерәү — елмаю
имтихан — сынау
хәл ителү — чишелү
дулкынлану — нык борчылу
тетрәп кую — *монда:* куркып китү
хәсрәт — авыр кайгы

Сораулар һәм бирем

1. Резидә институтка нинди максат белән килә?
2. Кыз шәһәрдә үзен ничек хис итә, ни өчен моңсулана?
3. Резидәнең соңгы имтихан бирү вакыты турында сөйләгез. Бу имтиханын бирә алмау кызга ничек тәэсир итә?

Зөфәрнең Резидәгә язган хаты

Тракторым гөрли,
Син, Резидә,
Яратмыйсың аның тавышын.
Шушы авыл мине алга әйди,
Шушы тавыш мине алга әйди,
Баса төшә сөю сагышын.
Теләкләрем буразналар булып
Уелып кала туган җирләрдә,
Хыялымда инде ишелеп уңган
Ашлык дулкыннары тирбәлә.
Нинди рәхәт гади эшең өчен
Кешеләрдән рәхмәт ишетү
Һәм үзеңне бу тормышта, җирдә
Кирәк кеше диеп хис итү!
Сокланам да кайчак карап торам
Күпереп яткан чиксез кырларга,
Күңел тула шулчак шатлык белән,
Күңел куша ярсып җырларга.
«Резидәкәй» дигән матур көйне
Йөрәгемдә саклап йөртәм мин.
Өй артында үскән сиреньнәргә
Төсең итеп карап үтәм мин.
Менә рәсемең синең,
Стенадан
Карап тора уйчан күзләрең.
Резидәкәй матур, ник дәшмисең,
Юкмыни соң әйтер сүзләрең?..
Күз алдыма килә:
Горур атлап,
Вуз ишеген ачып керәсең,
Киләчәгең синең үз кулыңда —
Елмаясың шуңа, көләсең.
Бер куаныч миңа булыр иде,
Рөхсәт итсәң хатлар язарга.
Бәлки очрашырбыз,
Смотрга
Мин дә барам тиздән Казанга.

сагыш — юксыну, сагыну хисе
уелып калу — онытылмаслык булып истә калу
ярсып җырлау — йөрәк хисе белән дәртләнеп җырлау

Сораулар һәм биремнәр

1. Зөфәрнең башкарган хезмәтенә мөнәсәбәте турында сөйләгез.
2. Зөфәрнең туган җиренә мәхәббәтен кайсы юллардан күреп була? Туган җиргә мәхәббәтне сез ничек аңлыйсыз?
3. «Нинди рәхәт гади эшең өчен
   Кешеләрдән рәхмәт ишетү
   Һәм үзеңне бу тормышта, җирдә
   Кирәк кеше диеп хис итү!» —
   дигән юлларның мәгънәсен аңлатыгыз.
4. Өзекне сәнгатьле итеп укыгыз һәм эчтәлеген сөйләгез.

Резидәнең әнисенә язган хаты

Әнкәй бәгърем, син рәнҗемә,
Сизә күңелем,
Сөйгән Резидәңнең сүзләренә
Йөрәгеңнең риза түгелен.
Дуслар чакыралар үзләренә.
Күп уйладым,
Белмим нишләргә.
Ахыр чиктә инде риза булдым
Бер заводка кереп эшләргә.
Бу заводта бер ел гомеремне
Ничек кирәк алай үткәрим.
Әнкәй, зинһар,
　　　　тыңла инде, яме!
Калмыймын бит монда күпкә мин.
Мин оялам.
Кызлар көлә генә.
Алар инде эшләп өйрәнгән.
Ә син, әнкәй, анда:
«Минем кызым
　　　　эшче хәзер»,— диеп сөйләмә...

Күзләр җитте инде,
Тик бер кышка
Ничек кенә булса түзәрмен,
Түзәрмен дә тагын институтка...
Шунда гына, әнкәй, мин үземне
Чын бәхетле итеп сизәрмен...

«Әйдә, сеңелем, башла...»

Куркамын да кебек,
        курыкмыйм да
Станокка якын барырга.
Өйрәтүчем — мастер Хәмит абый —
Көлемсерәп тора янымда.
«Бик катлаулы нәрсә.
Акылың җитми,
Исең китеп карап торырсың.
Ә белемле кеше җиңел аңлый
Машинаның һәрбер сулышын.
Әйдә, сеңелем, башла,
Шушы булсын
Зур тормышка аяк басуың...»
Ник куркырга сабый бала кебек,
Үз-үземә килә ачуым.
Станокка кулым тию белән,
Салкын тирләр чыкты маңгайдан.
Мин бит монда әле яңа кеше,
Оялтмагыз мине, малайлар!
...Мин торакка кайттым.
Их, дусларым,
Деталемне ясый алмадым.
Боздым, барысын боздым,
Ничек басыйм йөрәк янганын?!
Торасыз да: «Ник күңелсез?» — дисез,
Мин күңелсез — авыр уйлардан...
Эшче булу — вак эш, дигән идем,
Мин эшче дә, ахры, булалмам...
Мөлдерәтеп моңлы күзләремне,
Сезгә таба, дуслар, карыйм мин,
Әйтегезче, тормыш юлларында
Урынымны ничек табыйм мин?

Юаталар:
— Дускай, деталь эшләү
Әллә җиңел генә дисеңме?
Барып чыкмый икән, һәр яшь кеше
Горур башын түбән исенме?
Юк, Резидә, эшче булу өчен
Иң кирәге — ныклык, сабырлык.
Шул вакытта гына син ясаган
Деталь булыр таңга калырлык.
Кәгазь-каләм ал да, эшкә башлыйк,
Начар беләсең син сызымны...
Мин, оялып, күзне читкә алам,
Ә йөземдә инде — кызыллык.
Иркен сулыш алдым җиңеләеп,
Яктыргандай булды күзләрем:
— Өйрәтегез, кызлар, авыр булса,
Тешләремне кысып түзәрмен.

Шундый рәхәт миңа

Маңгаемнан кайнар тирләр ага.
Арыганмын,
Талган кулларым,
Әмма
Шатлыгымнан елмаям мин,
Шундый рәхәт миңа, дусларым!
Кулбашларым сызлый, баш әйләнә,
Кара таплар алсу йөземдә.
Шул вакытта әйтеп бетергесез
Көч артуын тоям үземдә.
Станоклар шавы уртасында
Басып торам.
Дуслар, килегез!..
Үз хезмәтем кергән иң беренче
Деталемне минә күрегез!
Җыелдылар дуслар, иптәшләрем,
Минем өчен алар шатланган.
«Болай булгач була!» дигән кебек,
Хәмит абый сөя аркамнан:
— Кыенлыклар алда бик күп әле,
Син шуларга, кызым, әзерме?

Бүгеннән соң синең һәр минутың
Завод өчен кыйммәт, кадерле.
Бөтен цехка кычкырасым килде:
(Кычкырсам да гаеп итмәсләр!..)
Мин булдыксыз түгел,
Мин эшләрмен,
Ышаныгыз миңа, иптәшләр!..

мөлдерәтеп карау — төбәп, тутырып карау
таңга калу — бик нык гаҗәпләнү
кулбаш — беләкнең калак сөягенә тоташкан урыны (плечо)

Сораулар һәм биремнәр

1. Резидә әнисенә нинди әчтәлектәге хат яза?
2. Заводта эшли башлавын Резидә ничек кичерә?
3. Беренче хезмәт җимешен күрү Резидәдә нинди хисләр уята?
4. Эшче булу өчен, нинди сыйфатлар кирәк? Бу сыйфатларның кайсыларын үзегездә булдырыр идегез?
5. Эшчеләрнең үзара дуслыгы, бер-берсенә ярдәм итәргә әзер торулары турында сөйләгез.
6. Поэманы тулысынча укыгыз һәм эчтәлеген сөйләгез.

Поэма

Поэма — зур күләмле шигъри әсәр. Шигырьдә сүз, нигездә, нинди дә булса бер эш яки күренеш турында барса, поэмада исә шагыйрьнең хисләре, уйлары күпкә катлаулырак була. Әгәр поэмада хис-кичерешләр өстенлек итсә, аны **лирик поэма** диләр. Мәсәлән, С. Хәкимнең «Шагыйрьнең балачагы», «Пар ат» әсәрләре. Күпчелек поэмаларда вакыйгалы сюжет була. Алар лиро-эпик поэма дип йөртеләләр. М. Җәлилнең «Хат ташучы» әсәре моңа мисал була ала.

Бүгенге көн шагыйрьләре дә поэмага еш мөрәҗәгать итәләр. Шундыйлардан И. Юзеевның «Язылмаган поэма», Ф. Яруллинның «Нәсел агачы», «Җан авазы» һ. б. китерергә мөмкин. Поэма жанрының үсү дәрәҗәсе шигъриятнең көчен билгели.

ГАШЫЙКЛАР ТАВЫ

(повесть-поэмадан өзекләр)

Элекке дәверләрдә Гашыйклар тавында түгәрәк тирән күл булган, диләр. Күлгә туган җирләрен сагынып, тезелешеп, язларын киек кошлар кайтканнар. Көннәрдән бер көнне шул якның сунарчысы, нәни балалары белән күлдә йөзеп йөргән кыр үрдәген аткан да, пешереп ашарга ниятләп, казанга салган. Бер көн кайнаган үрдәк, ике көн, өч көн... Һаман пешми икән. Җиденче көн дигәндә, Серле үрдәк, казаннан күтәрелеп, зәңгәр һавага очкан...

Шул көннән соң Гашыйклар тавының матурлыгы күзгә күренеп сулган, күле корыган.

(Борынгы риваять)

1

Бу юлы командировкам мине Себергә, Юрга каласына китерде. Себер дигәч тә, табигатьнең бездән әллә ни аермасы юк: нәкъ бездәге шикелле яшькелт-сары яфракларын кояркоймас утыручы ак каеннар, бакчаларда — күз явын алырлык август чәчәкләре... «Анда суыктыр» дип алган җылы курткамны салып кулга тотарга туры килде. Каршы алырга төшүче өлкән яшьтәге Хәнәфи ага мине кунак йортына урнаштырды да үзенә алып китте. Хатыны Сәлимә апа бик җылы каршылады. Икесенең дә туган ягы шушында. Хәнәфи ага шуннан сугышка киткән, яраланган, тагын үз заводына эшкә кайткан: «Туган туфрак үзенә тарта, шунда тудым, шунда үләрмен дә инде»,—ди. Сәлимә апа яратып, шаяртып кына, кул селтәгән була:

— Әй картлач, әллә ничә тапкыр үлдең инде... Хәзер чынлап үлсәң дә ышанмыйм.

Чыннан да, Сәлимә апа ике тапкыр «Ирегез Хәнәфи Вафин геройларча һәлак булды» дигән хәбәр алган, өметен өзмичә көткән.

Мин, шәһәр советы тарафыннан рәсми чакырылганлыктан, кичен халык белән очрашуга бардым. Язучы буларак, үземнең әсәрләремне укыганнан соң, күп кенә сорауларга җаваплар бирергә дә туры килде. Әмма иң кызыгы алда иде әле. Шушында, Татарстаннан бик ерак Себер шәһәрендә, татар

яшьләре ансамбль оештырганнар: алар бергәләп сөенәләр, бәйрәм итәләр. Үзара кайгыларын уртаклашканда да җырлыйлар, үз моңнарын кичен мәдәният сараенда халык белән дә уртаклашалар. Хәнәфи ага исә үзе — җитәкче, үзе — менә дигән конферансье. Ансамбльнең исеме дә җанга ятышлы — «Сагыну». Әллә кайчаннан таныш безнең як көйләре биредә бигрәк тә ягымлы ишетелә икән. Тукта... Ә монысы нинди җыр? Мин ишетмәгән-белмәгән, безнең якларда җырланмаган көй. Озын кара толымлы, кара күзле кыз җырлый:

Кыр үрдәген аттым очкан чакта...
Җаным әрни көн-төн — ник аттым?
Хәзер үзем яралы кош сыман:
Кайтыр юлларымны югалттым.
«Туган якларыңа кайт! Кайт!» — диеп,
Киек кошлар тезелеп киткәндер...
«Кайта!» — диеп өзелеп көткәндер дә
Көтә-көтә түземе беткәндер.
Яралы кош, бәлки, кайтып җитәр...
Мин язмыштан инде ычкынмам.
Танырсыңмы, юкмы — мин булырмын
Кош тавышы белән кычкырган...

Кичә тәмамланды. Ансамбль яшьләре мине кунак йортына озата киттеләр. Мондый җылы август төнендә җәяү йөрүгә ни җитә,— трамвайга да утырмадык. Алар, шул җырны җырлап, төнге урамнар буйлап баралар:

Танырсыңмы, юкмы — мин булырмын
Кош тавышы белән кычкырган...

Хәнәфи агадан ипләп кенә сорыйм:

— Нинди җыр бу? Кем язган?

— Аның исеме юк иде. Без аны «Яралы кош» дип атадык. Аның авторы — шушы ансамбльне оештыручы. Мин аның шәкерте генә.

— Үзе кайда соң? Исәнме?

— Исәнлеген исән... Килә алмый...

Яшьләр мине кунак йортына кадәр китерделәр дә, тыныч йокы теләп, өйләренә таралдылар. Икәүдән-икәү генә калгач, Хәнәфи ага башлаган сүзен дәвам итте:

— Казаннан икәнегезне белгәч, җырның авторы Сезне бик күрәсе килүен әйтте. Сез иртәгә ничек тә вакыт табыгыз инде, үзем илтеп куярмын. Хәерле төн!

Бу төнне бик озак йоклый алмый яттым. Нинди сере бар бу җырның? Көен дә, сүзен дә чыгарган диләр. Мондый җыр ниндидер авыр хәлләр кичергән кешенең йөрәгендә генә туа ала. Нинди язмыш аны туган җиреннән аерган икән?

Икенче көнне Хәнәфи ага, машинасына утыртып, мине Юрга урамнары буйлап алып китте. Шәһәр әллә ни зур түгел, халык берән-сәрән генә күренә. Урамнар иркен, шоферга мондый юлларда йөрү рәхәттер. Биш катлы өй янында машинасын туктаткач, Хәнәфи ага мине икенче каттагы квартирага алып менде. Звонок шалтыратты, ишекне ачып, өй эченә атлады, ымлап, мине дә артыннан ияртте. Хуҗаның үзен күргәч, мин аның «Керегез!» дигән карлыккан тавышын ишеттем. Ак күлмәк, кара чалбар кигән, кыска буйлы, ябык чырайлы кеше коляскада утыра иде. Сүзсез генә чишендек. Сул кулы белән коляска тәгәрмәчен тәгәрәтеп, хуҗа түргә юнәлде:

— Узыгыз!

Хәнәфи ага, ымлап, креслога күрсәтте дә:

— Берәр сәгатьтән килеп алырмын,— дип китеп тә барды. Сүзне нидән башларга белмичә, икебез дә аптырабрак тордык. Бүлмә тулы ал гөлләр: тәрәзә төпләрендә дә, өстәлдә дә, стенадагы асылмалы чүлмәкләрдә дә... Бер кырыйда — вак балыклар йөзеп йөргән аквариум. Эчендә — камыш сабаклары... Хуҗаның игътибар белән күзәтүен тоеп, мин уңайсызланып киттем. Ниһаять, ул, телгә килеп:

— Мин Сезне көттем,— диде. Шулвакыт авызының бик авыр ачылуын шәйләп, бу сөйләшүнең аңа җиңел түгеллеген абайладым. Аның ярты гәүдәсе хәрәкәтсез иде...

— Сез Татарстаннан бит, шулаймы?

— Әйе. Тумышым белән Башкортстаннан.

Ул коляскасын миңа якынрак тәгәрәтте.

— Шулаймыни? Кемнәрегез бар анда?

— Әни. Әти.

— Димәк, кайткалыйсыз?

— Сагынган саен. Моннан кайтышлый да кереп чыгарга исәп.

— Таллыкүл авылын белмисезме?

— Белмим шул.

— Гашыйклар тавы турында ишеткәнегез бармы?

— Гашыйклар тавы?.. Безгә әллә ни ерак түгел ул. Аның легендасын безнең тирәдә дә сөйлиләр... Җиде көн казанда кайнагач очкан кыр үрдәге...

— Әйе... Әйе! Ул легенда... чындыр, бәлки...

Ул, зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп, миңа карады:

— Таллыкүл авылы Гашыйклар тавына терәлеп тора... Әгәр мин әманәт тапшырсам... Сез анда бара алмассызмы?

— Нинди әманәт бит?!

— Сез кичә «Яралы кош»ны тыңладыгызмы?

— Әйе. Аны Сез чыгарган диләр, дөресме?

— Дөрес.— Ул, башын иеп, арыган кыяфәттә, бераз дәшми торды.—Әманәтем шул: «Яралы кош»...

— Кемгә тапшырырга?

— Таллыкүл: Мөнирә Идрисовага.

— Ничек?

— Менә сезгә магнитофон. Тасмасында—«Яралы кош». Үземнең тавыш. Мөнирә җырны ишетсен иде. Кем икәнне әйтмәсәгез дә, җырымнан мине — Сәет Зилаеровны таныш алыр...

— Аңладым. Тасмасын гына бирегез. Үз магнитофоным бар.

— Рәхмәт, якташ.

— Белергә яраса, кем соң ул Мөнирә?

— Сөйләве авыр...

Сәет ага үзенең коляскасын читкәрәк тәгәрәтте, аквариум янында туктап, эчендәге балыкларның кагылуыннан талгын гына тирбәлеп-тирбәлеп куйган камышларга текәлде.

— Сез мине аңларга тырышыгыз... Беренче тапкыр мин аны урманда күрдем. Их безнең Таллыкүл урманнары! Ярты дөньяны әйләндем, дигәндәй, юк андый урманнар беркайда! Урманчы әтием үлгәч, Таллыкүл участогына мине, унтугыз яшьлек егетне куйдылар. Киләм бер заман шулай урман буйлап, үз уйларыма бирелеп, кошлар тавышын тыңлап... Шулчак, колакка ялгыш ишетеләме дисәм, юк, чыннан да, кемдер нечкә генә, көйле генә тавыш белән аваз бирә:

— Ау-у-у!

Андый хәлләрне күргәнем бар, кемдер адашкандыр. Үн чакрымга ишетелерлек тавыш белән җавап бирәм:

— Э-һе-й-й!

Сез мине аңларга тырышыгыз, урманда туган баланың колагы сак: кошлар әнә шулай бер-берсен эзлиләр. Барып чыктым йөгерә-йөгерә түгәрәк болынга, күрәм: кәрзин тоткан, зәңгәр күлмәк кигән, яланбашлы кыз каен төбенә утырган.

— Нишлисең син монда?

— Күрмәйсеңмени, ния, адаштым ич...

Безнең якта шулайрак, көйләбрәк сөйләшәләр. Сез аңларга тырышыгыз, кызның җыр кебек сүзләре, беленер-беленмәс кенә тибрәлгән йомры күкрәкләре, яндырып ала торган коңгырт күзләре әллә нишләтте дә куйды...

— Кем кызы соң син?

— Кара, танымыйсыңмыни, Сәет абый, Түбән оч Мөнирә ич мин.

— Сафа абзый кызымы?

Ул, таныганга сөенеп, сикереп үк торды:

— Әйе... Тугызынчы класс укучысы Мөнирә Идрисова...

Бу сүзләре белән кыз минем дөрләгән хисләремә бозлы су сиптемени: иреннәре җиләктән алсурак тоелган сөйкемле кыз — укучы бала гына икән...

— Әйдә, өеңә кайтарып куям...

Нәни генә, йомшак кына кулларына кагылгач, йөрәгем сулкылдап, тәнем дерелдәп китте. Ул, куркынып, кулларын тартып алды да, поши баласы сыман, читкә ыргылды:

— Тотмагыз! Үзем дә кайта беләм!..

Һәм китте... китте урман сукмагыннан. Беркем дә белмәгән, үзе генә йөргән сукмаклардан. Мин тукталмакчы булдым, юк, мөмкин түгел, үземнән үзем аның каен җилендә җилфердәгән зәңгәр күлмәгенә тартылам, ияләм.

— Мөнирә... тукта, сеңелем...

Туктады Сафа кызы Мөнирә. Кинәт кенә борылды да мин генә ишетерлек итеп пышылдады:

— Мин... адашмадым...

— Кара урманда ялгызың нишләп йөрисең соң болай, сеңелкәш?

Ул, кызарып, башын түбән иде дә:

— Мин сезне яратам, Сәет абый,— диде. Шуннан йөзен куллары белән каплады да урман эченә кереп югалды. Сез аңларга тырышыгыз, якташ, минем нинди хәлдә калганны. Уналты яшьлек кыз сиңа мәхәббәтен ачыктан-ачык белдерсен әле... Юк, балалыктан күчү чорының хыялый бер җилпенүе-дер бу дип, үземне тынычландырам. Әмма зәңгәр күлмәген тибрәндереп, күз алдыма Мөнирә килеп баса. Әллә инде үзем дә гашыйкмы? «Юк, ярамый, син олырак кеше, тыел!» — ди акылым. Ә йөрәк буйсынмый: «Кызның яшьлек тилерүе генә булмаса ярар иде»,— ди. Үземне тиргим, аны онытырга тырышам. Әмма хыялымда — Мөнирә. Ул узган сукмакларда, болыннарда йөрим, иреннәрем: «Мөнирә, Мөнирә»,— дип

кабатлыйлар. Тагын килеп чыкмасмы дигән өмет мине шул кадерле урыннарга китерә. Таллыкүл урамнарыннан, мәктәп яннарыннан урыйм, ул яшәгән өй яныннан узам. Тәрәзә төпләрендәге ал гөлләре арасыннан зәңгәр чәчәгемне күрермен дип хыялланам. Аңлыйм: хәзер ул үз хисләреннән, мәхәббәтеннән качып йөридер.

Икенче тапкыр мин аны клубта укучылар концертында күрдем. Араларында гармунчы булмаганлыктан, мине чакырдылар:

— Бер укучы кызыбызны җырлат, зинһар, коткар,— дигәч, әлбәттә инде ризалаштым.

— Концертыбызның чираттагы номерында Таллыкүл яшьләренең яраткан җыры: «Җиләккә бармам инде». Җырлый Мөнирә Идрисова. Гармунда Сәет Зилаеров!

Гармунымны күтәреп сәхнәгә чыгам. Әллә инде тез буыннарым калтырый, үз хәлемне үзем генә беләм. Янымда гына ап-ак күлмәк кигән, аккош сыман озын ак муенлы Мөнирә. Ул бит минем белән җырлыйсын белмәде. Нишләр? Оялып, сәхнә артына кереп качмасмы? Көйне ахырынача җырларга үзендә көч табармы? Гармун телләренә башта курка-курка гына кагылам, аннан әллә гармуннан, әллә тирәннән — күңел түреннән — сихри авазлар агылуын тоеп кыюланам, үзем дә көй дулкынында тирбәләм.

Җиләккә дип барган идем,
Юри генә адаштым.
Сине күргәч, сүзсез калдым,
Адаштым дип алдаштым.

Синең йөргән юлларында
Җиләкләрем түгелде.
Кырын каравыңны белгәч,
Күңелләрем сүрелде.

Җиләклеккә бармам инде,
Бармам инде, адашмам.
Карурманда адаштым дип,
Инде бүтән алдашмам...

Җыр тәмамлануга, без сәхнәнең ике ягына ташландык. Әйе, ташландык. Мин, шашкан адәм кебек, әллә сөенечтән, әллә көенечтән туп-туры урманыма чумдым. Хәзер мине аңласа бары тик караңгы урман гына аңлый. Үземнең кайда-

лыгымны таң аткач кына белдем: күлдә йөзеп йөргән кыр үрдәкләренә карап утырам икән, үзем һаман җырлыйм:

Өлгергән ич димәгез,
Җиләкләргә тимәгез.
Миндәй дивана булырсыз,
Яшь кызларны сөймәгез!

Сез су эчә-эчә тыңлагыз, якташ...

(Сәет ага өстәл янына тәгәрәп килде, сусавын тоеп, аның тустаганына су салдым.)

Аннан соң... мин салкыннан калтыранган тәнем белән янымда Мөнирәнең кайнар сулышын сиздем.

— Сәет абый... беләм... Сез мине яратмыйсыз... мине бала дип уйлыйсыз... Сау булыгыз... мин башка килмәм...

Аны әллә кулларым, әллә тыннарым белән тартып алдым, әллә үз кочагыма үзе килеп керде, әллә ике омтылыш бергә туры килде, хәтерләмим, шулай ук тыпырчынып, кочагымнан ычкынганчы, әйтеп өлгердем:

— Мөнирәм... яратам...

Сез мине аңларга тырышыгыз, якташ, шундый сафлык, пакьлек, гөнаһсыз сак хәрәкәтләр...

Гөнаһ шомлыгына Сафа абзый, нидәндер шикләнеп, кызы артыннан күзәтеп, эзләп килгән икән. Мин аның ямьсез тавыш белән:

— Эт сөйрәгере кыз! Менә син нишләп йөрисең икән! — дип акыруыннан айнып киттем һәм Мөнирәнең урман эченә кереп качуын күреп калдым.

Аңласагыз иде, якташ, хәлләремне... Мине, балигъ булмаган кызны ялгыш юлга юнәлтүдә гаепләп, комсомол секретаре вазифасыннан азат иттеләр. Ярый, анысы түзәрлек. Мөнирәне каты куллы атасы чыбыркы белән кыйнаган, әнисе якламаса, тагын да яманрак буласы икән. Әмма бернинди чаралар да безне аерырлык түгел иде инде. Без, бик сирәк кенә, яшеренеп кенә, урман сукмакларында очрашуларны дәвам иттек. Их якташ, нигә соң мин шагыйрь булып тумаганмын, язып бирер идем мин сезгә... тел юк... тел!

Сугыш башланган айны аңа унсигез яшь тулды. Яуга китү хәбәрен көз көне алдым. Ни өчендер, Таллыкүлнең киек кошлары киткәч кире әйләнеп кайттылар. Мөнирәнең күзләрендә — шом.

— Сәет абый, кошларның кире әйләнеп кайтуы хәерлегә булыр микән... әллә нинди уйлар килә...

Шома чәчләреннән сыйпап, юатам:

— Бер дә борчылма! Юлларында ни дә булса очрагандыр... Сугыш, афәт!

— Юлларың уң булса ярар иде, Сәет абый...

— Безнең сәгать сукты, Мөнирә, әйдә Гашыйклар тавына!

Мин сезгә Гашыйклар тавы турында сөйләмәдем бит әле. Авылның югары очыннан, күл яныннан күтәреләсең. Элек-электән килгән гадәт: гашыйклар, шул тау башына менеп, туган җиргә карап, бер-берсен ташламаска, мәңге тугры булырга, шушы урында кабат очрашырга вәгъдә бирешәләр. Кем дә кем антын боза, күр дә тор, аңа нинди дә булса бәла-каза килә: я авырый, я үлә, я бәхетсез язмышка дучар була... Айһай, белмим, риваять кенә микән?.. Без дә, ике гашыйк, таңны каршыларга дип, Гашыйклар тавына күтәрелдек. Аста, бихисап төсләр белән таң нурында җемелдәп, Таллыкүл ялтырап ята. Анда —юллары бүленгән, китәлми калган киек кошлар... Ул, кочагыма сыенып, үзендә шаярырлык көч таба:

Мөнирә. Кара аны, үлеп-нитеп калсаң, өйгә кайтып кереәсе булма!

Сәет. Синең янга кайтмыйлармыни, Мөнирә! Яз җиткәч, кошлар белән кайтып җитәрмен.

Мөнирә. Вәгъдәме?

Сәет. Вәгъдә, кадерлем. Менә син шушы яшьлегең, чибәрлегең белән ятларга карамассыңмы, көтәрсеңме мине?

Мөнирә. Көтәрмен, Сәет абый, кайта гына күр. Юлларың бүленеп, озаграк кайталмый торсаң да, гел-гел көтәрмен.

Сәет. Көт, Мөнирәм, көтсәң, мин үлмәм, һичшиксез кайтырмын!

Мөнирә. Безне бернинди дошман да, сугыш та аера алмас, Сәет абый...

Сәет. Мөнирәм, әйтмичә китә алмыйм. Мин кичә кыр үрдәген аттым...

Мөнирә. Аттың? Кыр үрдәген? Сәет абый, нишләдең? Нигә? Ни өчен?

Сәет. Мин урманчы гына түгел, аучы да... Кыр үрдәге белән сыйланып, төне буе Гашыйклар тавында синең белән утыру иде исәбем...

Мөнирә. Хараплар иткәнсең, Сәет абыкаем... Үтердеңме?

Сәет. Үлмәде бугай. Күлгә килеп төшкәч, эзләгән идем, табалмадым. Мөгаен, яраланган гынадыр... Ана үрдәк булды бугай... Балалары...

М ө н и р ә. Риваятьне оныттыңмы әллә, Сәет абый?

С ә е т. Әй, ышанма иске йолаларга... Берни дә булмас!

М ө н и р ә. Хәерлегә юрыйк... Нигәләр аттың, Сәет абый?! Үзең кошлар белән кайтып җитәрмен дисең...

С ә е т. Кайгырма, Мөнирә, бер үрдәген югалтканнан Таллыкүл корымас. Без язмыштан өстен яңа чор кешеләре! Оныт... Кара минем күзләремә... Сөясеңме мине, әйт Таллыкүл буйлары ишетерлек итеп!

М ө н и р ә. Сөям, Сәет абый, мин — мәңгегә синеке!

С ә е т. Алайса, сөюебезне җыр белән раслыйк!

Әкрен генә гармунымны сыздырып җибәрдем — без, икәүләп, әтиләр-әниләр телендә дә тибрәлгән таныш көйне җырладык:

Ниндидер моңнар бар,
Ниндидер шомнар бар
Каеннар, имәннәр шавында;
Онытыйк шомнарны,
Каршылыйк таңнарны
Бергәләп Гашыйклар тавында.

Без — тауның башында,
Мәңгелек каршында —
Гашыйклар очрашкан урында.
Җанда — Ай нурлары,
Хисләр — саф, югары:
Биектә — Киек Каз Юлында.

Син әле янымда,
Хушлашу таңында
Сүз бирик изге җир алдында:
Аерылган көннәрдә
Булыйк гел үрләрдә,
Булыйк гел Гашыйклар тавында!

Ул төн җыр булып күңелдә уелып калды. Икенче көнне без авыл советына барып языλыштык. Бер атнадан мин фронтка киттем.

сунарчы — аучы
сулган — матурлыгын югалткан
абайлау — сизү, чамалау
балигъ булмау — балалыктан чыгып җитмәү

Сораулар һәм биремнәр

1. Әсәргә нигез итеп нинди риваять алына? Бу риваятьнең мәгънәсен ничек аңлыйсыз?
2. Себер татарларын берләштерүдә ансамбль оештыруның нинди әһәмияте бар дип уйлыйсыз?
3. Хикәяләүче Себердә кем белән очраша? Ул аңа нинди аманәт тапшыра?
4. Сәет белән Мөнирә язмышы турында сөйләгез. Сәет ни өчен авылга кайтмый? Туган ягыннан, сөйгәненнән аерылу аңа нинди газаплар китерә?
5. Бүлекне тулысынча укыгыз һәм эчтәлеген сөйләгез.
6. Өзектән чагыштыруларны табыгыз һәм дәфтәрегезгә языгыз.

2

Мин утырган поезд, Себер карурманнарын, үзәннәрен, тау-елгаларын артка калдырып, ярсулы тавыш белән таныш урыннарын сәламли, алга чаба. Тәгәрмәчләр бары мин үзем генә тойган көйгә тәгәриләр. «Әйләнеп кайтам, әйләнеп кайтам» дип кабатлыйлар шикелле. Тышта җылы, кояшлы сентябрь, әле табигать саргаерга өлгермәгән. Мин башта үземнең туган районыма — Яңавылга туктарга, аннан Таллыкүлгә барып килергә уйладым.

Туган як!

Шаян колындай уйнап яшел болыннарда яланаяк чапкан бала чагың, татлы сөю газаплары белән яндырып акылдан шаштырган хыялый яшьлегең ак томаннар, күксел таулар артына китеп ерагайган саен,— үзең торган, күнегелгән җирендә гаилә корып дус-ишләр тапсаң да, бәхетле чагыңда да, иң авыр минутларыңда да гел сиңа, сиңа тартыласың. Эре-эре җиләкләрең, әчкелтем-төчкелтем кузгалакларың, тәмле балтырганнарың белән сыйлаган кунакчыл урманнарың, өздереп сайраулары белән дәрт-дәрман уяткан кошларың,— төнлә төшеңә керсәләр дә, чиксез рәхәтлек кичерәсең. Һәркемнең үз ягы, үз төбәге үзенчә кадерле, үзенчә газиз.

Мин, язмыш зилзиләсе туган ягыннан аерган кешенең аманәтен алып, ул яшәгән, үскән, гыйшкы кабынган җирләргә барам. Яңавыл станциясенә иртә-таң белән төшеп, эти-әниләрне сөендердем дә кайтышлый тагын керергә сүз бирдем һәм Таллыкүл ягына юнәлгән автобуска утырып киттем. Миңа ничек тә Мөнирә Идрисованы табарга кирәк. Ике сәгать чамасы асфальт юлдан баргач, шофер машинасын туктатты:

— Таллыкүл! Сулга китегез!

Плащымны кулга алып, кыр буйлап сузылган юлга каерылдым. Басулар бушап, салам эскертләре генә өелеп калган. Барам-барам да, туктап, алга карыйм: бер генә җан иясе дә күренми — мондый вакытта олысы-кечесе бәрәңгедәдер. Тимер канатларын җилпеп утыручы нефть скважиналары тирәсендә дә кешеләр юк. Борылмалы юлдан атлый торгач, тагын асфальт юлга чыктым. Сәет ага сөйләгән Гашыйклар тавы кайда соң? Киек кошлар йөзәрлек күл кайда? Җиләккә барсаң адашырлык куе урманнар кайда? Ниһаять, алда әллә ни зур булмаган тау күренде, аннан да ерактарак күгелҗем-карачкыл урман төсмерләнде. Мөгаен, Таллыкүл буйлары шулдыр. Выжылдап, «Москвич» узып китте — туктатмадым, җәяүлеләр очрар әле. Авылга килеп кердем. Бу — үзәк урам, ахры. Сул якта — зур гына кибет, аннан ары — өр-яңа мәдәният сарае. Туктадым, кызыл хәрефләр белән язылган белдерүгә игътибар иттем: «Бүген яшьләрне озату кичәсе! Гашыйклар тавында кичке сигездә көтәбез!» Таштан салынган ике катлы колхоз идарәсе. Хәзер мине аякларым түгел, уйларым алып бара: берән-сәрән очраштырган кешеләрдән дә сораштырмыйм, авыл белән үзем танышасым килә. Монысы — бакча. Эчендә — түрдә — Ватан сугышы корбаннарына һәйкәл. Ташка уелган йөзләгән исемнәр... Тукта, ни бу? «Зилаеров Сәет»... Бу — мин күргән, миңа аманәтен биргән Сәетме әллә? Бәлки, исем-фамилиясе туры гына килгәндер...

Урамга чыккач, беренче очраган кыздан сорадым:

— Әйтегез әле, сеңлем, бу — кайсы авыл?

— Зирекле.

— Зирекле? Мин ялгыш килдем микәнни?

— Сезгә нинди авыл кирәк, абзый?

— Таллыкүл, Гашыйклар тавы.

— Ә-ә, шулай диләр аны. Нәмә сразы әйтмәй торасыз... Әнә Гашыйклар тавы... күренеп тора.

— Сеңлем, сез Таллыкүлдән Мөнирә Идрисованы белмисезме?

— Әллә, белмәем,— диде дә кыз ашыгып идарәгә кереп китте. Ә миңа рәсми йортка керү кирәк түгел,—эшем бик тә шәхси, бик тә нечкә... Мин — аманәт иясе, язмышлар илчесе.

Зирекленең озын киң урамын үтеп, авыл читенә чыгуга, як-ягында сирәк-мирәк агачлар үскән, нефть скважиналары тирәсендәге бормалы юлга һәм алдымда пәйда булган тауга игътибарым юнәлде.

Гашыйклар тавы, мөгаен, шулдыр. Таллыкүл авылы кайда соң? Тау артындамы? Тирә-якта каен, чыршы, юкә агачлары күренгәли. Урман дип һич тә әйтерлек түгел. Керсәң, адашырлык калын кара урманга кайчан җитәрмен? Сәет ага урманны Таллыкүлгә терәлеп тора дигән иде югыйсә... Көз җылы килүгә карамастан, агачлар җәйге киемнәрен салалар, яшькелт-сары яфракларын коялар. Әнә якында гына берничә яңа өй. Алар артында гел иске йортлар бугай.

Шулчак ерак та түгел, каеннар ешлыгыннан таныш җыр ишетеп, сагаеп, туктап калдым. Әллә Мөнирәме?

Җиләккә дип барган идем,
Юри генә адаштым.
Сине күргәч, сүзсез калдым,
Адаштым дип алдаштым.
Әй-й-й!

Сөенечтән нишләргә дә белмичә, җыр ишетелгән якка талпынырга да өлгермәдем, икенче яктан мотоцикл дөбердәве, бераздан мотор тавышы тынып, бер егетнең җыры ишетелде:

Җиләккә барма инде,
Барма инде, адашма.
Карурманда адаштым дип,
Инде бүтән алдашма!
Эһе-й-й-й!

Җыр авазлары тынуга, мотор тагын кабынды. Урман юлыннан джинс чалбар кигән егет белән кыз утырган мотоцикл килеп чыкты. Мин хыялда тудырган табигать баласы Мөнирә түгел, бөтенләй башка, ят кыз иде ул. Күрәсең, мин һаман да әле Сәет агай хисләреннән аерылмаганмын... Мөнирә хәзер алтмыш яшьләр тирәсендәге, Сәет ага күрсә, үзе дә танымаслык ханымдыр...

Егет мотоциклын бик оста гына борды, кыз нидер әйтте дә, егетне кочаклап, артка утырды. Һәм шул ук мизгелдә алардан җилләр исте. Димәк, аларның да тоткан юлы — Таллыкүл. Димәк, бу көйне яшьләр дә онытмаган. Сәет аганың сөйләп, көйләп бирүеннән мин Мөнирәнең җырында оялчанлык та, тирәнгә яшеренгән мөлдерәмә зәңгәр сагыш та сизгән идем. Ул кыз да, егет тә сагыш-моңны күтәренке рух һәм шаянлык белән алыштырганнар... Шул ук көй, бөтенләй башка яңгыраш... Охшашлык тик яшьлектә... кайнарлыкта.

Әкрен генә атлап, мотоциклга кунаклаган яшьлек артыннан иярдем.

үзән — уйсу җир
төбәк — туган-үскән җир
идарә — җитәкчелек урнашкан бина
пәйда булу — барлыкка килү
сагаю — сизгерлекне, игътибарны көчәйтү
мизгел — бик кыска вакыт арасы (миг)

Сораулар һәм биремнәр

1. Туган якны ярату хисе әсәрдә ничек күрсәтелгән? Шул урыннарны табып укыгыз.
2. Ни өчен Гашыйклар тавы элеккеге серлелеген югалткан? Моның сәбәпләрен бүгенге көн белән дә дәлилләп сөйләгез.
3. Мөнирәнең яшь чакта җырлаган җыры хәзер башка яңгыраш алган. Моның сәбәпләре нидә дип уйлыйсыз?
4. Бүлекне тулысынча укыгыз һәм эчтәлеген сөйләгез.

3

Яшьлек! Әллә син хыялый бер әкият кенәме? Яшь Сәет Зилаеровның күзләрендә мәңгегә шәүләсе калган зәңгәр урманнар кайда? Ыгы-зыгылы көндәлек тормышка ямь биреп йөзүче, дулкыннар таратып уйнаучы кыр үрдәкләре кайда? Нигә сез туган күлегезгә кайтмадыгыз, юлларыгызны өермәләр бүлдеме әллә? Менә минем очар канатларым да юк, мин кайттым, Сәет Зилаеровның хыялы булып кайттым. Сәлам сиңа, киек кошларсыз боегып калган Таллыкүл! Сәлам сиңа, яшьлек төсмерен җуйган, тешләре коелган карт сыман, серлелеген югалткан гап-гади урман! Әллә минем күзләремә генә шулай күренәсезме? Сәлам сиңа, Мөнирә ханым, янар яшьлегеңнән! Мин сине үзем эзлим, күрәсем дә килә, олыгайган, урман-күл шикелле, күркәмлеген югалткан хәлдә күрсәм, күңелдә авыр хис калудан куркам да... Исәнме, Гашыйклар тавы! Сәет аганың сөйләвенә караганда, син бик мәһабәт, биек булып ерактан ук балкырга тиеш идең... Барлык гашыйкларны әсир иткән, үзенә тарткан-чакырган зәңгәр ераклыгың, якын ямьлелегең кайда?

Бөтенләй диярлек Сәет Зилаеровка әверелеп, мин Таллыкүл авылына керәм. Әмма алдымда хәрабәләргә әйләнгән нигезләр, тәмам картаеп, янтайган-егылган өянкеләр, тупыллар күрәм. Йөри-йөри аңладым: кешеләр яшәгән нигезләрен калдырып, каядыр киткәннәр, күченгәннәр. Адәмнәрнең шат авазлары урынына — каргаларның хәсрәтле, ялыктыргыч,

карлыккан бертөрле тавышы... Яшьлегеңнән бер аваз бирсәнә, Таллыкүл! Әллә мин эзләгән Мөниръне дә узган яшьлегеңдә калдырдыңмы?

Ташландык нигезләр яныннан уза торгач, алдымда заманча салынган таш йорт күренде. Өр-яңа рәшәткәләр белән уратылган өйнең тимер капкасын ачып, ишегалдына кердем. Йортта беркем дә юк. Шул вакыт якында гына, бакча ягыннан ягымлы бер көй ишетеп сискәнеп киттем.

Тавышы — нәкъ Сәет Зилаеровныкы! Җыр иясен бакчада эзләп таптым. Ул, әкрен генә көйләп-көйләп, алмагач төбе йомшарта. Мәһабәт гәүдәле, кара чәчле, кара мыеклы ир-егет төсе-кыяфәте белән дә Сәет агага тарткан иде. Мин, мөгаен, дөрес килгәнмендер. Җыр изге юлга озатты, җыр каршы ала...

— Исәнмесез?

— Исәнмесез! Сезгә кем кирәк?

— Мин Мөнирә Идрисованы эзлим.

— Сез кем буласыз соң?

— Язучы.

— Сезгә нигә кирәк ул?

— Мине аның язмышы кызыксындыра. Аның өе шушымы?

— Әйе.

— Сез аның улымы әллә?

— Әйе. Өмет Зилаеров.

— Әниегез өйдәме?

— Юк.

— Ул тиз кайтырмы?

— Кайтмас.

— Өмет, Сез мине аның янына алып бара алмассызмы? Миңа аны ничек тә күрергә иде.

— Әйдәгез. Алып барам.

Сабыр табигатьле, аз сүзле Өмет артыннан киттем. Икебез дә дәшмибез. Мин сабырсызланам, тынычсызланам, үзем генә сизәм: йөрәгем еш-еш тибәргә тотынды. Аның белән ничегрәк сөйләшергә, ниләр әйтергә, нindирәк сүзләр табарга? Сәет аганың исәнлеген белгәч, йөрәгенә авыр алмасмы? Өмет алдында әйтергәме, әллә үзенә генәме? Бәлки, ул башка берәүгә кияүгә чыккандыр, Сәет аганы бөтенләй оныткандыр?..

Тукта, син мине кая алып барасың, Өмет? Зиратка керәбез түгелме соң? Өмет белән бергә мин ал гөлләр уратып алган

(Сәет аганың өендә дә нәкъ шундый гөлләр иде) кабер алдында басып торам һәм ташка уеп язылган үзәк өзгеч сүзләрне укыйм:

Идрисова Мөнирә Сафа кызы

1923—1986
Сәет!
Кайтырсың, шушында табарсың.
Өзмимен өметне... мин көтәм.

Мәрмәр ташның икенче ягында рәсем: якты дөньяга елмаеп караучы Мөнирә...

шәүлә — күләгә
җую — югалту
мәһабәт — сокланырлык матур, күркәм

Сораулар һәм бирем

1. Таллыкүл авылының ташландык хәле, табигате турында сөйләгез. Бу күренеш сезгә ничек тәэсир итте?
2. Авторның җан әрнешен, борчылуларын сез каян аңлыйсыз? Ул табигать күренешен тасвирлаганда нинди сүзләр, чагыштырулар куллана?
3. Мөнирә малаена ни өчен Өмет дип исем куша? Аның бөтен тормышы нәрсә белән бәйле?
4. Мөнирәнең кабер ташына нинди сүзләр язылган? Ул гомере буе кемне көтеп яшәгән? Аңа нинди сыйфатлар хас?

6

Без, Өмет белән икебез, иске өй баскычында утырабыз.

— Әнкәй бу баскычта, уң кулын каш өстенә куеп, күзләрен юлларга текәп утырырга ярата иде. Менә әле дә аның тавышын ишетәм сыман: «Таллыкүлнең гүзәллеген күрергә теләп, әллә кайлардан, Казан, Уфалардан, ерак Себер якларыннан килгәннәр, туганнар Сабан туйларында җыелганнар. Беренче тапкыр аяк баскан һәрбер кеше, әкиятләрдә күрелмәгән манзарага таң калып, «аһ» иткән, тәүге күрүдә үк гашыйк булган. Сылу табигать кешеләр җанына да мәрхәмәт, шәфкать, нәфислек иңдергән. Шунлыктандыр инде, кызлары да бер күрүдә һуштан язарлык чибәр, егетләре Таллыкүлдәге

имән кебек күркәм, ыспай, чыдамлы, балалары — өлгергән алма кебек түгәрәк, таза булганнар». Әнкәй нәкъ менә шулай сөйли иде.

Таллыкүлне саклау урманына әйләндерү турында сүз йөргән. Сугыш башлангач аның кайгысымы? Аннан соңгы тарихын сөйлисе килми.

Минем өчен иң авыры шул: Таллыкүлне мәсхәрәләүдә катнашкан адәмнәрнең берсе — мин үзем! Янәсе, табигатьне яулап алу көрәшендә без җиңгәнбез! Янәсе, мин — новатор, заман кешесе, ул — борынгылыкка, артка тарта. Юк, кемнәрдер әйткәнчә, әнкәй кара алтынга дошманлык белән карамады, туган якларда нефть табылуга куанды гына. Ә без, рекорд артыннан рекорд куеп, табигатьнең иң нечкә, иң нәфис, иң илаһи җиренә бәреп кергәнбез. Нәтиҗәсе — күз алдында... Табигать шәрәләнеп калганнан соң, кешеләрнең җаны ярлыланган, тупасланган, үзара мәхәббәтләре сүрәнләнгән, туган җиреннән суынган. Авылдашларымның күбесе, тапкан байлыкларын нишләтергә белмичә, хәмер юлына әйләнделәр. Гашыйклар тавын оныттык: кая анда менеп вәгъдәләр биреп тору,— без инде аның серлелеген бетергән идек. Нигә сөйләп торырга, шул хәмер аркасында яраткан хатыным китте. Әлек-электән нәселе белән игенчеләр, кырларын ташлап, шәһәрдә күңелләре тартмаган теләсә нинди эшкә тотындылар. Борынгыдан мирас булып күчкән табигатьне, риваятьне, гасырлар буена сыналган гадәтләрне, ырымнарны, китапларны, мәчетләрне, дин белән бәйләп, барысын да: яманын да, асылын да машина астына салып таптаганбыз лабаса! Кыр үрдәге турындагы риваятьне чыгаручылар үзләре калдырган гүзәллекне рәнҗетсәң, нинди фаҗига киләсен алдан искәрткәннәр!

Әнә шулай Таллыкүлне таркаттык... Нигездә бер әнкәй торып калды. Вәгъдәсенә тугры булып, көтеп... Хәзер ул юк. Әткәйне мин көтәм. Кайтмасын да беләм, барыбер көтәм... Уң кулымны каш өстенә куеп... баскычка утырып...

Әнкәйне соңгы юлга озаткач кына аңга килдем, айныдым: нишләдек без, нишләттек үзебезнең туган җиребезне?

Күңелдәге басмага карасам: әнкәем һаман керләр чайкый кебек. Шул кыяфәттә төшләремә килеп керә... Авыр чакта ярдәм итә, күз яшьләремне сөртә. «Әнкәй, син, исән чакта, бер тапкыр да күзеңнән яшь чыгармадың». «Мин еламыйм

бит, балам, каты күңеллелектән дә түгел, безнең нәселнең гадәте: елаудан тыелабыз. Шуңадыр инде: елый башласак, туктый алмыйбыз». Төшемдә әнкәй яраткан шушы басмага керләр чайкарга төшкәнмен, имеш.

Өметнең төше

Т а в ы ш. Өмет, балам, бир, керләреңне үзем чайкап бирим...

Ө м е т. Әнкәй, кайттыңмыни?

Т а в ы ш. Мин әле кайтмадым, керләреңне чайкашырга бик азга гына килдем.

Ө м е т. Кайда соң син? Тавышың бар — үзең юк?

Т а в ы ш. Бәй, улым, танымыйсыңмыни, алдыңда торам ласа...

Ө м е т. Алдымда — үрдәк... , син — юк...

Т а в ы ш. Шул үрдәк мин булам инде, балам.

Ө м е т. Серле үрдәк... син?

Т а в ы ш. Нигә гаҗәпләндең? Керләреңне бир әле, балам, анда юма, пычратасың ич. Менә монда су чистарак...

Ө м е т. Рәхмәт, әнкәй... Якынрак кил, башыңнан бер сыйпап кына алыйм инде. Исән чакта бер генә дә иркәли алмадым.

Т а в ы ш. Юк, килмим. Мин адәмнәрдән куркам, балам...

Ө м е т. Нигә куркасың, әнкәй?

Т а в ы ш. Адәм балаларының борынгы риваятьтәге явыз аучыдан аермалары юк.

Ө м е т. Без сиңа тимибез. Серле үрдәк-әнкәм... Кайчан кайтырсың соң?

Т а в ы ш. Гашыйклар тавындагы күлне үз урынында күрмичә, Таллыкүл урманнары шауламыйча, кешеләрнең җанына шәфкать иңмичә, кайта алмыйбыз!

К а й т а в а з. Кайта алмыйбыз! Кайта алмыйбыз!

Яңа калада төшләр күрә-күрә, әнкәм белән сөйләшә-сөйләшә яттым-яттым да, Таллыкүлгә кире кайтып, әнкәй нигезендә йорт кордым. Таллыкүл әле үлмәгән, исән, хәлсезләнгән, авырган, картайган, сулыш өрергә, терелтергә генә кирәк. Әнкәй өен сүтәргә дә кул бармый, торсын әйдә рухын саклап...

Гашыйклар тавында җыр ишетәсезме? Бүген анда яшьләр җыела. Әкренләп кайталар... Шунда таңны каршылаячаклар. Барабызмы без дә? Киттек!

манзара — *монда:* табигать күренеше (пейзаж)
тәүге — иң беренче
иңдерү — *монда:* сеңдерү
ыспай — килешле, купшы
илаһи — *монда:* тылсымлы, серле

Сораулар һәм биремнәр

1. Таллыкүлнең элеккеге матурлыгы, Гашыйклар тавының серлелеге турында автор язганча тасвирлап сөйләгез.
2. Авылның таркалуына нәрсәләр сәбәп була?
3. Өмет үзен ни өчен гаепли? Ул нәрсәгә борчыла?
4. Егетнең борынгыдан килгән риваятьләр, гореф-гадәтләр турында әйткән фикерләре белән сез килешәсезме? Ни өчен?
5. Өмет хәзер нинди фикергә килгән? Ул нәрсәне аңлаган? Аның тоткан юлы дөресме?
6. Әсәрне тулысынча укыгыз, эчтәлеген сөйләгез.
7. «Гашыйклар тавы» спектаклен бергәләп карарга тырышыгыз һәм фикер алышу оештырыгыз.

Эдуард Касыймов
(1930—1986)

Күренекле язучы Эдуард Касыймов (Эдуард Салихҗан улы Касыймов) 1930 елның 9 ноябрендә Киров өлкәсенең Слобода районы Нократ авылында хезмәткәр гаиләсендә туа.

1948—1953 елларда Казан дәүләт университетында белем ала. Университетта уку елларында көндәлек матбугатта беренче әдәби иҗат тәҗрибәләре — очерклары, хикәяләре күренә башлый.

1957 елда Э. Касыймов Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты аспирантурасын тәмамлый, шул ук институтның татар фольклоры бүлегендә гыйльми хезмәткәр булып эшли.

1962 елда язучының «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында «Кояш көн дә чыга» исемле повесте басыла. Сәнгать кешеләре, галимнәр тормышыннан алып язылган һәм драматик вакыйгаларга шактый бай бу повестьны укучылар яратып каршы ала.

Ике елдан язучының «Гомер ике килми» исемле романы дөнья күрә. Автобиографик нигездә язылган һәм кеше язмышының гыйбрәтле якларын психологик алымнар белән сурәтләгән бу әсәрне дә укучылар яратып кабул итә.

1966 елда Эдуард Касыймов «Татар халык әкиятләрендә сатира һәм юмор» дигән темага диссертация яклый һәм филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. Шушы елларда язучының «Томан аша» романы, «Бир кулыңны, дустым!», «Көмеш язулы кылыч», «Сорбонна профессоры һәм без» повестьлары басылып чыга.

1971 елда «Томан аша» әсәренең дәвамы булган «Һаваларда тургай» романын тәмамлый. Бу ике роман-дилогия, русчага тәрҗемә ителеп, «Чулман — река внуков» исеме белән Мәскәүдә басылып чыга, ул вакыттагы СССР Язучылар берлеге һәм Профсоюз Үзәк Советы бүләгенә лаек була.

1972 елда язучы Чаллы шәһәренә күчә һәм автомобиль заводын төзүчеләргә багышланган кыска хикәяләр, мәкаләләр яза. 1979 елда Мәскәүдә «Язучы һәм заман» дигән сериядә нефтьчеләргә багышланган очерклар китабы дөнья күрә.

Э. Касыймов 1980 елда әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә.

Эдуард Касыймов 1986 елның 21 мартында Чаллы шәһәрендә вафат була.

ГОМЕР ИКЕ КИЛМИ

(романнан өзекләр)

Беренче төп

Синең белән бик күптәннән инде иркенләп сөйләшәсем килә, Назим...

Моңа кадәр күренмичә, карамыйча онытып йөргән икән бу, дип уйлама син. Элегрәк тә мин сиңа бик еш карый торган идем. Чыгып китсәм дә, кайтып керсәм дә, түр стенадан синең акыллы, җылы карашыңны һаман да үземдә тоя идем. Тик моңарчы дөнья артыннан куа-куа, синең белән күзгә-күз карашып сөйләшергә, серләшергә вакыт кына җитенкерәмәде. Ә хәзер вакытым бар минем: түшәктә мин. Авыруым бик яман, бик куркыныч... Юк, сине алдан ук борчып, куркытып куймыйм әле. Сиңа сөйләргә уйлаганым бөтенләй ул түгел бит...

Кичә синең бу рәсемеңне олы улыбыз Әнвәрдән шушында баш очыма элүен үтендем. Әнвәр бераз вакыт миңа сәерсенеп карап торды. Әмма бер сүз дә әйтмәде, теге як бүлмәдә минем үз портретымны ялгыз калдырып, сине монда, минем янга күчереп куйды. Күңелнең ни теләгәнен бер караштa аңлый торганнардан ул.

Кызык, син аны таныр идең микән? Мөгаен, танымас идең: хәзер ул ир уртасы булып килә — утыз икенче яшь... Теге дәһшәтле елны — ноябрьнең караңгы иртәсендә сине бездән

аерып алып киткән чакларда, аңа җиде тулып үткән генә иде әле. Хәзер алар өчесе дә — Әнвәр дә, киленебез Зөлфә дә, нәни оныгыбыз Рәшит тә — теге якта йоклап яталар. Юк, Әнвәр йокламыйдыр әле, унбиш-егерме минутлар элегрәк укол кадады ул миңа. Син аны врач-мазар булгандыр дип уйлама тагы. Башыңа төшсә, башмакчы буласың, диләр бит. Кирәк булгач, өйрәнде инде, киленне дә өйрәтте. Миңа көненә өч-дүрт кат кадамыйча булмый шул уколны. Аңа нинди медсестра чыдасын йөрергә...

Син бу бүлмәгә аптырап карыйсың бугай... Түгел, Кариле дә, Шөмбет тә түгел — Казан бу... Әйе, Казанның аулак кына, тыныч кына урамнарының берсендә торам мин хәзер. Бүлмәм кечтеки, бик кечтеки: койка белән этажерка, тумбочка белән бер-ике урындык куйгач, йөрер урын да калмады... Теге як бүлмә дә әллә ни иркен түгел, тыгыз, кысан — ул күбрәк китап складына охшый. Ә кухнялары шулкадәр бәләкәй, ике кеше керсә, өченчесенә баш тыгарга урын юк... Хәер, бәләкәй булуының уңай ягы да бар: газ плитәсен полный ходка җибәреп тиз генә җылыталар да бәбәйне шунда гына юындырып алалар...

Ләкин ни генә булмасын, квартирларын ошатам мин үзем. Бердән, тәрәзәләр шәһәр бакчасына карый. Шау-шу юк, тузан юк. Ачып җибәрсәң, бүлмәгә бакчадагы чәчәкләрнең хуш исе кереп тула, агачларында чыпчыклар чыр-чу килә. Кайсы көннәрдә, бигрәк тә кояшлы, тын иртәләрдә,ниндидер кошларның матур гына сайраган авазлары яңгырый.

Аннан соң үзәккә бик якын без. Театрына-мазарына, кибетенә-базарына хәзер барып җитәсең...

«Тагы бер-ике елдан яңа квартирлы булырбыз»,— ди Әнвәр. Чиратлары, әкрен булса да, якыная, имеш. Миңа калса, әллә кая, шәһәр читенә, җәһәннәм тишегенә китәргә бик ашкынып та тормыйм. Монда рәхәтрәк... Мондагыдай бакча анда булырмы?.. Тик шулай да улыбызга биреләчәк ул яңа квартирны бер күрсәң иде, ванныендагы краннарын борып, су агызып карасаң иде, балконына чыгып, әйләнә-тирәгә күз салсаң иде — бер дә генә начар булмас иде...

Моннан бик күп, бик күп еллар элек син дә Казан урамнарында йөргәнсең бит. Хәлемдә чакта: «Бу тирәләрдән ул да үтми калмагандыр»,— дип, үземне синең эзләреңә баскандай тоеп, кайлардан гына әйләнмәдем мин. Ә Болак буеннан: «Менә бу йортка укырга килә торган иде ул»,— дип, ничәмә-

ничә үткәнмендер... Чынлап торып уйласаң, ул чакның йортлары калган да, урамнары калган, ә синең баскан эзләрең әллә кайчан юылып, тузаннары әллә кайчан Идел суларына аккандыр...

Чү, Назим, тегендә Әнвәр кузгалды, ахры. Әйе, урыныннан торып бире килә... Ишекне ачып карады да китте. Тыныч кына йоклый дигәндер инде. Синең белән сөйләшкәнне белми ул, сизми. Хәзер, бер уянганчы, үзе дә йоклар инде. Йокласын, хәл җыйсын. Эше авыр да, җаваплы да. Юкса әйттем мин аларга: «Борчылмагыз, кирәк булсагыз, кашык белән дару шешәсенә шакып чакырырмын»,— дидем. Юк, барыбер үзләренекен итәләр. Кичен Әнвәр уяу, иртәнге якта Зөлфә...

Туктале, Назим, ни сөйлим соң мин? Һаман шул авыру турында... Югыйсә күңелемдә бөтенләй ул түгел ләбаса. Үзем канаты сынган кош хәлендә булсам да, күңелем канатлары сынмаган бит әле. Юк-юк, болары турында сөйләмим бүтән, онытам бөтенесен, онытам... Икәү бергә булган көннәрне искә төшерик без. Сиңа да, миңа да бик күп рәхәтләр, куанычлы тойгылар алып килер ул көннәр. Аннан соң мин сиңа бәйнәбәйнә син киткәч ниләр булганын сөйләрмен, яме.

...Бервакыт син:

— Кеше гомерендә була бер көн, ул аның язмышын бөтенләйгә үзе белән бөтереп алып китә,— дигән идең.

Үз гомереңдәге андый көн дип син партиягә кергән көнеңне саный идең. Чыны да шулай иде аның. Тау ташкынына ташланган егет идең бит син...

Ә мин үземнең гомеремдә андый көнем юктыр дип уйлый идем. Хәзер минә үтелгән юлны күңел түреннән кабат үткәргән чакларда, минем дә андый көнем бар икәнлегенә төшендем. Әйе, бар икән... Нинди көн ул дисәң, сезнең Карилегә китәргә карар ителгән көн ул, Назим...

Уйлап кара менә: әгәр мин Карилегә китмәгән булсам, сине очратыр идемме? Юк! Минем язмышым бөтенләй башка эздән китәр иде. Улларыбыз Әнвәр, Дамир, Айратлар да булмас иде. Мин дә, Казанга килеп, бакча фонареннан төшкән сыек яктыда синең — сөекле иремнең — җансыз сурәтен җанлы күреп, менә болай үзалдыма сөйләнеп ятмас идем, бәлкем...

Ул көннең ничек булганын беләсең килә инде синең — сизәм мин. Ярый, тыңла алайса, түкми-чәчми барын да сөйләп бирим инде. Үземә дә искә төшерүе кызык бит.

...Егерме бишенче елның җәй көннәре иде. Мин, үзебезнең Шөмбеттә техникум тәмамлап, укытучы булырга йөрим. Еракка җибәрмәделәр. Шөмбеттән ун-унике чакрымнарда утырган Чаналык дигән бер авылда укытырга тиешмен. Барып кайттым мин анда. Ярлы гына, бәләкәй генә авыл икән. Каралты-кура сирәк. Исеме Чаналык булса да, чана ясаучылары инде юк икән. Әүвәле, урман барында, булган. Иген игеп, хайван асрап көн күрәләр. Халкы, «эчендәгесе — тышында» дигәндәй, бик гади, мөлаем, эчкерсез, тик шул инде «фәкыйрьлекнең аръягыннан бирге якка» карап торалар. Авылда такта түбәле бер генә йорт иде, ахры — ул да булса мәчет. Аның каршында салам түбәле тәбәнәк кенә куш өй. Эченә керсәң, идәннәре шыгыр-шыгыр тирбәлә. Болай чиста гына үзе. Мәктәп дигәннәре шул. «Артык дан булмаса да, түзәрлек икән»,— дидем.

Миңа беренче белән өченче сыйныфларны укытырга иде. Күңелемне шул авылга беркетеп кайттым.

Уракка күп калмаган иде инде. Әти көне-төне бау ишүдә.

— Быел игеннәр начар түгел, бауга нужа зур булыр, сынатмыйк, кызлар,— ди.

Олы апам Мәрьям кияүгә киткән иде инде. Без уртанчы апам Мәмдүдә белән алмаш-тилмәш чыгыр әйләндерәбез. Әти үз эшендә — сыдырып-көйләп торуда.

Әти безне ярыштырып, котыртып эшләтә. Янәсе, кем көчлерәк, кем чыгырны җитезрәк әйләндерә. Кояш кыздыра, июль кояшы, тәннән шабыр тир ага. Минем өмет зур. Бау сатудан яхшы гына табыш чыкса, әти өстемә сатин күлмәк, аякка туфли алып бирмәсме дим. Техникумга йөргән чакта, студент кешегә ярамаганмыни дип, мин һаман апалардан калган иске-москыны өстерәдем. Ә хәзер бераз рәтлерәк күренәсе килә. Мин моны Мәмдүдә апага да әйттем. Ул этигә җиткезгән.

— Мөгаллимә кешене,— дигән әти бер дә ачуланмыйча,— бу килеш бала-чага каршына чыгарып бастырмабыз инде анысы, тик өметен зурдан тотмасын,— дигән.

Мондый сүзләрдән соң беләктә көч артмыймы? Кыздырган кояш та юк кебек, күлмәкнең манма су булганын да сизмисең.

Шулай үлле-мәлле бау ишеп яткан көннәрнең берсендә төш алдыннан күршедән бер кыз кереп, мине техникумга директор чакырганлыгын әйтеп китте.

Кызның сүзләрен әти дә ишеткән икән, ул, эшне туктатып, кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә, минем янга килде.

— Бар, кызым, Ногман абыең тикмәгә чакырмый торгандыр, кирәгең булгандыр, хәзер барыбер әбәткә кирәсе,— диде ул, түгәрәк сакалын сыпыргалап.

Юынып, өсне-башны алыштырдым да чыгып чаптым.

Техникум шәһәр уртасындагы буа ярында ике катлы бинада урнашкан иде. Әйләнә-тирәсендә наратлар шаулап утыра.

Техникум директоры Ногман абый, мине үзенең кабинетына алып кереп, өстәл янындагы йомшак кәнәфигә утыртты да, сүзне турыдан-туры башлаганчы:

— Соң ничек, Чаналыкны ошаттыңмы? — дип сорады.

— Ошатсаң да, ошатмасаң да, укытырга кирәк бит. Кая барсаң да, бер кояштыр инде,— дидем.

Ногман абый, башын кырын салып, мыек астыннан гына елмайды. Гадәте шул иде аның, күңеле булган чагында башы үзеннән-үзе кыңгыр салына торган иде. Әмма елмаеп утыруы озакка бармады. Йөзе җитдиләнеп:

— Сиңа, Мөнирә, ул авылда укытырга туры килмәс, мөгаен,— дип куйды.

Куркынып:

— Ник?— дидем.

— Синең Кариле дигән авылны ишеткәнең юкмы?

— Юк. Кайда соң ул?

— Губернаның төньягында, Усть-Омга өязендә. Менә шунда кеше сорыйлар. Губернаның мәгариф бүлегеннән ике тапкыр хат яздылар инде. Баштарак уйламаганнар. Хәзер менә җибәрергә кешебез дә юк, җибәрмичә дә булмый. Әллә китәсеңме? — диде ул турыдан-туры.

— Белмим шул... Соң, монда да кеше кирәк ич,—дидем мин.— Аннары өйдәгеләр ни әйтер бит тагы...

Тыр-тыр өйгә чаптым. Мин кайтып кергәндә, әти белән апа ашарга утырганнар иде инде. Әти кайнар шулпасына яшел суган салды да башын күтәреп миңа карады. Өстәл артында ул, әпититне бозасыз дип, нихәтле генә кызык хәбәрең булса да, сөйләштерми торган иде. Аның өчен аш арты бар — рәхим ит. Әмма ул көнне минем каушаган кыяфәтемне күреп, ахры, үзе үк сүз башлап:

— Я, ни йомышы төшкән? Ник чакырган? — диде.

Мин сөйләп бирдем.

— Риза булмагансыңдыр бит? — диде әти. Шул чакны тоттым да:

— Юк, риза булдым, әти,— дип куйдым. Әти кулындагы агач кашыкны өстәлгә атып бәрде, муенындагы кан тамырлары, бүртеп, кара-кучкыл төскә керде, түгәрәк кара сакалы дерелди башлады. Түзмәде, өстәл артыннан чыгып, ишекле-түрле йөри-йөри, мине әрләргә тотынды.

— Син, чүпрәк баш, Кариленең ни икәнен беләсеңме? Җыен сәүдәгәр, җыен разбойник шунда!.. Бервакытны шул Кариледән икәү, әллә нихәтле бау алып, кулыма фальшивый акча тоттырып киттеләр. Шулар аркасында участокка күпме йөрттеләр, күпме йөрәк маен суырдылар... Ә монда, Чаналыкта укытсаң, атна саен ат җигеп кенә алып кайтыр идем үзеңне,— диде.

сәерсенү — гаҗәпләнү
дәһшәтле — зур бәла-каза китерә торган, афәтле
бәйнә-бәйнә — җентекләп һәм аңлаешлы итеп
сурәт — рәсем (портрет)
каралты-кура — хуҗалык корылмалары
чыгыр — бау ишү җайланмасы
тикмәгә — сәбәпсезгә

Сораулар һәм биремнәр

1. Әнвәр белән Зөлфә авыру әниләрен ничек тәрбиялиләр? Бу кешеләргә сез нинди мөнәсәбәттә?
2. Мөнирәнең тормышы турында нәрсәләр беләсез? Шул турыда сөйләгез.
3. «Халкы, «эчендәгесе — тышында» дигәндәй, бик гади, мөлаем, эчкерсез, тик шул инде, «фәкыйрьлекнең аръягыннан бирге якка» карап торалар» дигән җөмләне сез ничек аңлыйсыз?
4. Бүлекнең эчтәлеген сөйләгез, исем куегыз.

Икенче төн

Туктале, Назим, сине беренче тапкыр ничек күрүемне дә сөйлим әле. Монысын да белмисең бит син.

Октябрь бәйрәме алдыннан бер иртәне Рәхилә бакчага авызы колагына җитеп килеп керде дә:

— Беләсеңме, Мөнирә апа, Валунскидан Назим абыйлар кайткан бит,— диде.

Мин коры гына итеп:

— Кайтса соң, кайтсын... Бәйрәмне авылда уздырасы килгәндер,— дидем.

— Юк, ул үзе генә түгел,— диде Рәхилә.— Фатих абый белән Сабир абый да кайткан. Өчәүләшеп. Бәйрәмгә спектакль куймакчылар, русчадан тәрҗемә, ди. Беренче репетицияләрен ясаганнар да инде,— диде.

— Пьесасы кызык микән соң? — дип сорадым.

— Әкәмәт күңелле нәрсә, ди. Аннан бик шәп уйныйлар бит алар. Карарга барабызмы, Мөнирә апа, ә? — диде Рәхилә, күзләрендә очкын уйнатып.

— Ярар, барсак барырбыз,— дип ризалаштым мин.

Иртәгә бәйрәм дигән кичне Рәхилә белән клубка киттек. Халык шыгрым. Кемнәрдер безгә урта рәтләрдән урын бирде. Озак көтәргә туры килмәде, бер-ике алкышлап сорагач, пәрдә ачылды. Кызылларның ак бандага каршы көрәшен карый башладык.

Син кызыл командир ролендә. Күкрәгеңдә аркылы-торкылы каеш, билеңдә наган. Галифе чалбар, күн итек...

Фатих Зәнчурин — комиссар. Ул да тырыша, тик гәүдәсе олы булгангамы, авыррак, салмаграк йөри.

Өченчесе, Сабир Дунәшев, ак офицер. Гәүдәгә бәләкәй генә, әмма тавышы чынлап тора. Борча күк җитез...

Ләкин спектакльдә оста уйнавы белән барыгызны да Төхфәт уздыргандыр. Ул — акларның атаманы. Кыяфәте белән суйган да каплаган бандит. Өстәвенә озын борыны астына зур гына мыек ябыштырып куйган. Бәбәкләрен агартып җикерене. Әллә нихәтле кешене аттырды...

Сезнең арада бер малай да буталып йөри иде. Кызылларның разведчигы иде, ахры. Пешмәгәнрәк нәрсә. Авызын ачса, сүзен әйтә алмый, тотлыгып кала. Юкса чәчрәп торырга кирәк иде ул малайга.

Әллә нинди спектакль иде ул. Туктаусыз атыш — шарт та шорт! Бигрәк тә икенче, өченче пәрдәләрдә. Колаклар томаланып бетте.

Әмма иң кызыгы соңгы дүртенче пәрдәдә булды. Кызыллар, акларны туздырып, башлыкларын әсир иттеләр. Штабта сорау алу бара. Төхфәт белән Сабир Дунәшев — ак бандитлар — эскәмиядә мыш-мыш утыралар. Ишек төбендә бер кызылармеец белән разведчик малай сакта тора. Фатих Зәнчурин белән син тегеләрдән сорау аласыз. Тегеләр дәшми, сез

ярсый башлыйсыз. Син хәтта өстәлгә наганың белән шакы-шокы сугарга да тотындың... Нәкъ менә шул чакны сәхнә янындагы тәрәзә ватылып, синең аяк астыңа бер кирпеч төшмәсенме! Ах иттек... Син тегендә карадың, монда карадың, аннары кисәк җилкенеп китеп, атылып бардың да тәрәзә рамын тибеп очырдың. Очыруың булды: «Ычкынмассың, контра!» — дип сикереп төшүең булды... Синең арттан куллары бәйле килеш избач Төхфәт тә сикермәкче иде, әмма аны Фатих җибәрмәде: «Утыр урыныңа, кымшанма!» — дип кычкырды. Телсез калдык... Спектакльдә шулай булырга тиештер дибез. Кызыл командирның берәр бандитны эләктереп керүен көтәбез... Озак көтәргә туры килмәде... Тәрәзәдән шыңшый-шыңшый бер малай үрмәләп керде, аның артыннан син. Малай ундүрт-унбиш яшьләрдә. Аягында чабата, өстендә иске чикмән. Билен киндерә белән буган, кызылармеец фуражкасы кулында. Әле дә күз алдымда ул малай... Син аны сәхнә уртасына чыгарып бастырдың да бик усал итеп:

— Я, телеңне йоттыңмы әллә? Әйт, ни өчен тәрәзәгә кирпеч ыргыттың? Ник дәшмисең? — дип сораша башладың.

Шунда гына без, тамашачылар, аңга килдек. Спектакль түгел икән, тормыш үзе икән бу... Үзебезнең беркатлылыгыбыздан үзебез көлеп куйдык. Ә теге малай һаман дәшми, борынын салындырып торуын гына белә. Ул дәшмәгәч, син үзең аңлатып бирдең:

— Беренче репетиция уздырган көнне бу малай актыгы бездән: «Кызыл разведчик малаегызны мин уйныйм әле»,— дип сораган иде, без бирмәгән идек. Хәзер менә шуның үчен алган,— диДең һәм халыктан: — Нишләтәбез инде моны? — дип сорадың.

И купты тавыш, и китте гөж. Берәүләр кычкыра:

— Ватканнар икән, куйсыннар тәрәзәне,— ди.

Икенчеләре акыра:

— Бүгенге спектакль акчасын тотарга да калырга,— ди. Шулай диюләренә, бер кырыйда муенын сузып утырган Төхфәт ялт кына сикереп торды. Калын тавыш белән бөтен клубны гөрселдәтте:

— Вәт сиңа, ә! Алар ватсын, ә син спектакль уйнап түлә, имеш! Юк-юк, бүгенге спектакль акчасы бөтенләе белән китап алуга китә, бер тиенен дә бирмим, валлаһи,— диде.

Шулай тавышланып ятканда, сәхнәгә агач аяклы бер абзый менде. Ләселдән икән, Абубәкер атлы. Бер кулын күтә-

реп халыкны тынычландырды да, сары мыегын бөтереп алгач, салмак кына сөйләп китте:

— Җәмәгать, алай кызарга ярамый,— диде.— Без яшьрәк чакта калай самавыр була торган ие, Бичерманда әле дә бар бугай ул,— диде.— Менә шул самавыр күбрәк күмер салсаң, дөбер-шатыр кайнарга ябыша, утырган төшендә сикерә-бии башлый. Әнә шулай бии-бии дә пырт итеп идәнгә егыла. Икмәктер газим менә, егылып төшә торган ие... Шул калай самавыр булмыйк без, кызмыйк, башыбызның ярылуы бар. Син, Төхфәт энекәш, бигрәк тә,— диде.— Соң, уйлап багыгыз... Ярый ла таш атучы шул малай булган. Ә чыннан да контра булса? Ул чакны без Назим иптәшкә маладис, егет икәнсең, тәрәзә-фәлән дип тормадың, карчыга күк ташландың дияр идекме, ә? Шулай да бу малай актыгын уйнатырга кирәк ие сезгә... Уйнаса, таш та атылмас ие, тавышланып та тормас иек... Гаеп атта да, тәртәдә дә... Әмма ләкин мин үзем болай дим: иртәгә үк тәрәзәне үзем куеп бирәм, пыяла гына тапсыннар... Икмәктер газим, бушлай куеп бирәм,— диде.

Халыкны шулай дип тынычландыргач, Абубәкер абзый, сәхнәдән төшеп, үз урынына килеп утырды. Малайны җибәрдегез, ул, аска төшеп, алгы рәт алдына посты. Спектакль дәвам итте.

Соңыннан ул малайны спектакльләргә катнаштыра башладылар, «тагын тәрәзә ватмагае» диптер инде. Ә ул оста гына, матур гына уйный торганнардан булып чыкты. Утызынчы елларда син аның, Казанга укырга китеп, театрда артист булып уйнап йөргәнлеген сөйләгән идең.

Шулай инде берәүләр, театрларга йөреп, китаплар укып артист була, икенчеләре кирпеч белән тәрәзә ватып сәхнәгә менә...

Спектакльдән көлешә-көлешә чыктык. Мине Гали Дәүләтьяров озатып куйды. Без инде ныклап торып танышкан идек. Мин аңа:

— Назимыгыз кызурак канлы икән,— дидем.

— Шулайрак,— диде ул миңа һәм синең турыда бик озак итеп әкәмәт кызык нәрсәләр сөйләде. Тыңла әле, Назим, аныңчарак итеп сөйлим әле үзеңә дә... Әй, юк, иртәгәгә калдырыйм... Тегеннән Зөлфә керде. Дару бирде.

— Әнкәй, син әле һаман йокламыйсың бугай... Тынычлап йокларга тырышып кара инде,— ди.

Булмаса, тырышып карыйм әле... Хәерле төн, Назим!

әкәмәт — *монда:* искиткеч
избач — уку өе мөдире
гөрселдәү — гөрелдәү
посу — яшеренү, качу

Сораулар

1. Спектакль барган вакытта нинди вакыйга була? Бу вакыйганы тамашачылар ничек кабул итә?
2. Абубәкер абзый халыкны ничек тынычландыра? Аның нинди сыйфатларын аерып әйтеп була?
3. Уйлап карагыз әле: малай урынында булсагыз, сез нишләр идегез?
4. Малай соңыннан нинди профессия кешесе булып китә?

Җиденче төн

Син ничек уйлыйсыңдыр, Назим, әмма миңа бөтенесе дә безнең йорт сатып алуыбыздан башланып китте кебек тоела...

Квартирабыз болай иркен генә, әйбәт кенә булса да, кышларын бик интегә торган идек. Аста сельпо склады — якмыйлар, бүрәнәләре таушалган -- тегеннән дә өрә, моннан да өрә... Үзебез ничек тә түзәр идек әле, ләкин балалар бар. Аларны кая куясың?

Менә шуңа күрә дә мин:

— Балаларың исән-сау үссен дисәң, бер-бер җаен табарга кирәк булыр... Тырышсак, бәлки, өй сатып ала алырбыз,— дип, өзлексез колагыңа тукый тордым.

Эзли торгач, таптык: берәүләр Карилстройга күчеп китәләр икән.

Икебез дә ошаттык ул йортны: алты почмаклы, ике бүлмәле, зур гына өйалды бар һәм иң әһәмиятлесе: ишегалды түрендә мунча утыра. Кешегә йөреп туеп беткән идек бит инде... Җәй өчен тагы бер уңай ягы бар икән: чормаларына мезонин сыман бер бүлмә ясап куелган. Җылы чакта тәрәзәләрен ачып йокларга да мөмкин...

Утырган җире дә матур гына: Биякның Юачка таба караган тау бите. Аста инеш, урамында яшел чирәм... Әмма иң матуры: урам яктан йортны өч миләш агачы каплап тора...

Җәйге ял акчалары кереп китте, аның өстенә зур гына әҗәт алдык, шулай да мин: «Ичмаса, кешечә йорт-җир белән яшәрбез»,— дип, чиксез куандым.

Өебезне байтак кеше карап китте. Килгән бере, авыз тутырып:

— Харап әйбәт булган!.. Тигезлек белән исән-имин яшәргә насыйп булсын инде үзегезгә! — дип, күңелне үстереп, мактап китә иде.

Беркөнне Мәхмүт Муллакаев белән Фатих Зәнчурин да сугылды. Син ул чакны Казанга җәйге сессиягә киткән идең инде. Нишләптер, син барында кереп чыгарга итмәгәннәр. Юкса Фатихы ул җәйне авылда атна саен диярлек күренгәләп китә торган иде.

Дәшми-нитми генә карап йөрделәр, хәтта ак мунчага да күз салдылар.

Ахырда бөтенесен карап чыккач, Фатих, күн фуражкасын калын кашлары өстенә үк төшереп:

— Назим җитешә ул барысына да... шаккатмалы! — дип куйды.

Ә Мәхмүт, янып, кызарып торган йөзен сыйпаштыргалап:

— Аның мәчесе дә куян тота шул, җизни... Аңламыйсың! — дип кеткелдәп алды.

Чәйгә кыстаган идем, утырмадылар.

— Эшебез тыгыз. Бер күз салып чыгыйк әле дип кенә кергән идек... Чәй түгел, мәен дә эчәрбез әле,— дип, капканы ачык калдырып, чыгып киттеләр.

Ләкин бу аларның безнең йортка беренче һәм соңгы тапкыр аяк басулары булды. Бәлкем, шул чакны ук инде агу йотып, тешләрен шыгырдатып чыгып киткәннәрдер?..

Казаннан син бик шатланып кайттың: сессияңне уңышлы тәмамлап, тиешле имтиханнарыңны бик әйбәт тапшыра алгансың икән.

— Инде дәүләт имтиханнары гына калды, озакламый абзаң аларыннан да котылыр,— дип, куанычыңны уртаклаштың.

Ул да җитмәсә, кайтышлый Валунскида облоно белән обкомда мәктәп эшләрен дә җайга салып чыккансың.

— Ниһаять, безнең үтенечкә риза булдылар... «Бу елны уздырыгыз инде, ә киләсе уку елына сигезенче класс ачып җибәрерсез. Тик көчегезне жәлләмәгез, сезнең мәктәп районда да, өлкәдә дә алдынгылардан булырга тиеш»,— диделәр... «Сынатмабыз, тырышырбыз»,— дидем. «Көч жәлли торган халыкмы соң без?» — дип аңлаттың миңа.

Кариледә урта мәктәп ачылачак!.. Озакламый урта белемне әллә кайларга китмичә, үз өеңдә яшәгән килеш кенә алырга мөмкин булачак. Авыл халкына нинди зур шатлык!

Укытучылар коллективын син бик дус, бик тату дип йөри идең. Эшкә муеннан чумып, тегендә-монда чабып йөргәнгә сизенмәгәнсең. Арада кайчан моның аягын чалып, абындырып булыр икән дип көтеп яткан черек җанлысы да булган...

Иң әүвәл безнең бер-беребез өчен җан атып, тигез, имин тормышта яшәвебез көнләштергән дип уйлыйм мин. Әйбәт кенә йорт сатып алуыбыз ул кара тойгыны тагын да көчәйтеп җибәргәндер... Аннан тагы дәрәҗә, абруй... Монысы кемгә күбрәк эләгә? — Мәктәп директорына... Хикмәт эшнең үзендә түгел, әлбәттә. Хикмәт әнә шул эш китергән данда... Баш буласы, данга күмеләсе килеп, бер мәртәте кызыккан бит шуңа...

Икеме-өчме кат аноним хатлар язып җибәргәннәр. Хатлары аноним булса да, игътибарсыз калдырмадылар. Башта комиссия белән, аннары ревизия ясап килделәр... Күпме нервыга тимәгәннәрдер, кешенең күпме вакытын алмаганнардыр, ә файдасы ни?..

— Хат дөреслекне чагылдырмый. Тимербулатов йортны үз акчасына сатып алган, мәктәпнекенә кагылучы булмаган... Язганнары яла ягу,— дигән нәтиҗә ясап китеп бардылар.

Уку-укыту эшендә кайбер кимчелекләрне, завхозның ниндидер җитешсезлекләрен күрсәткәннәр иде бугай күрсәтүен, әмма болары сиңа эшне тагын да яхшырту өчен файдага гына иде аның...

Башта белмәдек. Тырнак астыннан кер эзләүче кем икән ул дип, баш ваттык. Соңрак ачылды: Мәхмүт Муллакаев белән Нурислам Арсланов икән. Аның Мәхмүте билгеле инде. Басмачыларга каршы сугышта үзенең күргәннәрен адым саен сөйләп, мактанырга яратучы бу җанга йөгәнне үз кулына алырга кирәк. Дәрәҗәгә күмелеп, бүтәннәрне үз иркенә буйсындырып, команда биреп яту кирәк... Ә тегесенә, ана теле укытучысы Нурисламга ни калган?.. Хәер, бер ахмак янына икенчесе табылмыймыни?..

Бу хәлләр бер-ике елдан алдан яисә бер-ике ел соңрак башланган булса, бәлкем, алай катлауланып китмәс тә иде. Каһәр суккыры, елы туры килде. Дәһшәтле, буталыш елы...

Чүп өстенә чүмәлә өелә дә тора бит ул.

Октябрь азакларында яңгырлы, пычрак көннәрнең берсендә, кичкырын безгә синең совпартшколада бергә укыган иптәшең Сабир Дунаев килеп керде. Казаннан өч-дүрт көнгә туганнары белән күрешергә генә кайткан икән. Үзе суга төшкән тавык кыяфәтендә иде ул; иңбашлары салынган, бе-

тәшкән... Ул соңгы тапкыр колхоз төзелгән елларны кайтып киткән иде. Бәләкәй генә гәүдәле, борча күк җитез, шаян холыклы иптәшеңне мин ул чакны бик ошатып калган идем. Фатих Зәнчурин кебек эре кыланмый иде. Ә бу юлы гел шәүлә инде... Беренче караудан ук аның ниндидер авыр кайгы кичергәнлеген аңлавы кыен түгел иде... Яшермәде, әйтте: газетада эшләгән җиреннән куылып, партиядән чыгарылган икән. Ни өчен диде әле ул? Ие, армиядә хезмәт иткән энесе кулга алынган икән. Ул аны командир дигән иде шикелле. Шулай диде бит, Назим?.. Энесенең ни сәбәптән эләгүен әйтә дә алмады...

Тик зур ачыну, нәфрәт белән:

— Энекәшнең дошман ягына авасын белгән булсам, бәләкәй чагында ук бәреп үтергән булыр идем мин аны... Ихлас! — диде.

— Туганда беркем дә дошман булып тумый. Тора-бара дошманга әверелә ул кеше. Хәзер сыйнфый көрәшнең иң кызган чагы. Дошман үткен, хәйләкәр... Берәрсенең кармагына эләккән булуы бик ихтимал...— диден син кызмыйча-нитмичә.

Синең бу сүзләреңә каршы мин:

— Ярый ла шулай булган булса, ә булмаса?.. Бәлки, ул бөтенләй дошман да түгелдер,— дидем.

— Безгә, һичнәрсәгә карамый, ул кабахәт җаннардан арынырга кирәк. Ансыз алга барып булмый, шулай бит, Сабир? — дип, Дунәшевның күзләренә карадың.

— Бик шулай,— дип баш какты Сабир һәм шундук уфтанып: — Тик менә нишлим инде мин хәзер? Управдом булып эшләргә ярый диделәр, шунда кереп ятыйммы?.. Я, әйт син, әйт бер-бер киңәш! — дип үтенде.

— Синме? — Беравык ишекле-түрле йөрдең-йөрдең дә ашыкмыйча гына әйттең: — Сиңа, Сабир, ышанычны акларга кирәк... Управдом буласыңмы, шайтанмы — барыбер... Аклый алсаң, үз урының югалмас... Революция тарихында андый хәлләр булмады түгел, булды,— дидең.

Буш сүзләр түгел иде бу. Син акылыңда әллә кайчан өлгереп, ныгыган карашларыңны чыгарып салдың. Чын күңелдән, ышанып әйттең... Безнең тирәдә тын иде әле, дәһшәтле дулкыннар безнең өлкәгә дә, районга да килеп җитмәгән иде әле...

Үзеңә кагылмаганда, читтән торып акыл өйрәтүе кыен түгел ул. Үзеңә китереп бәрсәләр генә акыл чуала башлый...

Озакламады, дәһшәтле өермәнең беренче дулкыннары безгә дә бәреп керде. Сабир Дунәшев кире Казанына киткәч үк... Хәтта беренче дулкынны ул ияртеп алып кайткан шикелле булды...

Хәтерем саташтырмаса, ноябрьнең икесе иде. Иртән почтальон район газетасын кулыбызга тапшырмыйча ишек ярыгыннан гына ташлап китте. Алып карасак, миңгерәүләнеп каттык: синең хакта язылган нәрсә дә бар иде анда... «Кем ул?» дигән баш астында... Тукта, Назим, булган көчемне, сабырлыгымны җыеп, тынычрак сөйләргә тырышыйм әле...

...Мәкаләне укыгач, чәчләребез үрә торды... Коточкыч нәрсәләр... Иң элек синең морза нәселеннән икәнлегеңне әйткән... Аннан соң Назим Тимербулатов — үзенең нәсел-нәсәбеннән котыла алмаган бер бәндә, дигән, партия сафына үрмәләп, партия политикасына аяк чалып, аны эчтән какшатырга тырыша, дигән... Коллективлашу чорында колхоз атларын урлаган каракларны яклавы моны бик ачык дәлилли, дигән. Моның өстенә, дигән, аның соңгы вакытларга тикле яшертен эш алып барганлыгы да мәгълүм булды, дигән. Казанда партия сафыннан сөрелгән Сабир Дунәшев белән элемтәдә торганлыгын әле шушы арада гына күрсәтте, дигән... Кеше ышанмаслык пычрак... Язарга кулы ничек корышмагандыр бәдбәхетнең... Иң азактан «Кем ул?» дигән сорау куеп, үзе үк: «Аның халык дошманы булуында һичнинди шик булырга тиеш түгел»,— дип җавап та биргән. Астына «Ф. Крутояр» дип, авторы язылган... Псевдоним...

Бер селтәнүдә газета маңгаеңа ярлыкябыштырып куйды...

Мин хәлсезләнеп урындыкка утырдым, ә син бер агардың, бер кызардың, башыңа ябыштың, чәчләрең тузгыды. Аннары, җан ачуына чыдашмыйча, газетаны тураклап ташладың да, ыңгырашып, койкага егылдың...

Кич ятканда, коммунист идең, иртән торуыңа — халык дошманы...

Шуннан башланып китте.

Бирешергә теләмәдең. Нахак гаепләүне селтәп, туздырып ташламакчы булдың...

Редакциягә шылтыратып, мәкаләнең чын авторын белергә теләдең, ләкин тегендә:

— Без сезгә җавап бирүне тиешле санамыйбыз... Редакциянең үз сере ул,— дип, трубканы шундук элеп куялар.

Ә бит шул ук газета әле ярты ел, хәтта бер-ике ай элек кенә сине һәм син җитәкчелек иткән мәктәпне үтереп мактаган мәкаләләр бастырып чыгарган иде. Ун ел эчендә басылган хәтлесен әйтмим дә инде... Нинди тиз үзгәреш, нинди зур борылыш!

Райкомда сине яхшы беләләр иде, өметең шунда... Беренче секретарьга:

— Бу нинди хәл? Иң ышанычлы коммунистларыгызның берсенә дөньяда булмаган пычрак аталар... Тиз арада тикшерүегезне үтенәм,— дип шылтыратасың.

Березин җор гына, ипле генә кеше иде, мәрхүм. Үзе дә аптырашта калган булса кирәк, сине тынычландырырга тырышып:

— Борчылма, Тимербулатов... Бәйрәмне генә уздырыйк, ныклап тикшербез, белербез... Һәммәсе ачыкланыр,— дип җавап кайтара.

Эшне озакка сузуның файдасызлыгын төшенеп, син үзегезнең партоешмада кичекмәстән җыелыш җыюны таләп иттең. Әмма секретарегыз Мәхмүт Муллакаев:

— Анда әллә нинди мөгез чыгарып куюыгыз бар, үзебез тикшербез әле дип, райком кушмады... Шулай булгач, ярамый була,— дигән.

Һәммәсе алдан уйланган кук... «Газетага язучысы да шул ач күз Мәхмүттер» дип шикләндек...

Җитмәсә, тикшергәнче-белгәнче дип, вакытлыча эшеңнән азат итәргә, халык белән аралашмаска кушканнар... Мәктәптә йөгән Муллакаев кулына күчте... Теләгенә ирешкән кук булды.

Өйдә бикләнеп ятуга калдың. Тик кайчакны кичләрен генә урамга чыгып әйләнеп керә торган идең. Урамында да кеше күзенә күренерлек түгел: һәммәсе яндырып, бораулап карый сыман...

Авыр, газаплы көннәр... Әмма синең минем алда да, балалар алдында да сынатасың килми иде. Бернәрсәгә дә исең китмәгән кук көләргә-шаярырга тырыша идең. Әллә мин күкрәгеңнең өзлексез тырналып торганлыгын сизми идемме?..

Очар кошны читлеккә ябып асрама икән — очсын ул, бигрәк тә лачын-кош булса... Бик авыр, бик күңелсез икән аны күрүе ук...

Мин моны Октябрь бәйрәме көнне аерата нык тойдым...

Демонстрациягә Дилбәр генә китте. Ичмаса, ул классташларыннан калмасын, дидек. Мин үзем теләмәдем, сиңа ярамый. Югыйсә демонстрациягә баруны нәкъ ун ел элек син үзең башлап җибәргән идең ич. Ә хәзер йөзеңне күрсәтмә, тавышыңны чыгарма...

Ләкин, хәсрәткә калдык дип, бәйрәмне болай гына уздырмассың бит. Бәйрәмнең дә иң зурысы: Октябрьгә егерме ел... Мин пешеренергә керештем, ә син миңа булышырга тотындың.

Ризык мичкә кереп, бераз бушангач:

— Булмаса, бер карап төшим әле,— дип, Әнвәрне ияртеп, чормага менеп киттең. Чормадагы бүлмә тәрәзәсеннән демонстрацияне бик әйбәт күзәтергә мөмкин иде. Йөрәгең түзмәде синең...

Бераздан мин дә менәргә уйладым. Ләкин баскычтан күтәрелеп, бүлмә ишеген ачып җибәрсәм, баскан җиремдә катып калдым: син башыңны тәрәзә яңагына терәгән килеш сулкылдый-сулкылдый елый идең... Әнвәр исә, синең пиджак чабуыңны тарткалап:

— Әти, дим, кирәкми инде... Май бәйрәмендә без дә чыгарбыз әле. Әти, дим, елама инде,— ди, юата, үзенең дә бите буйлап борчак-борчак яшь тәгәри...

Син, аның башыннан сыйпый-сыйпый:

— Ах улым, аңламыйсың шул әле син, аңламыйсың...— дисең, үзең кулъяулыгыңны йөзеңә каплыйсың.

Мине күрмәдегез. Эндәшмәдем. Еласа, бераз бушаныр ичмаса дип, әкрен генә түбән төшеп киттем. Инде үземнең дә бугазыма тыгылган, тагын бераз торсам, ташып түгелә башлар идем...

Бүтән елларны демонстрациягә барганда-кайтканда укучылар безнең урамнан уза торганнар иде. Бу юлы алай итмәделәр: әйләнечрәк булса да, икенче урамнан үттеләр. Башлыклары Муллакаев кушмагандыр инде... Әмма демонстрация бетеп, таралышкан чакларында әкәмәт хәл булды...

Бер заман урамнан дәррәү кычкырган тавыш ишетәбез:

— Назим абый!.. Назим абый!..

Ни бар икән дип чыгып карасак, капка төбендә йөзләгән укучы. Авыз ачарга бирмәделәр, «ур-раа» кычкырып каршы алдылар.

— Ник безнең белән чыкмадыгыз? Сез булмагач, бик күңелсез үтте,— диләр.

Нишләптер, син бик нык каушадың. Ни әйтергә белмәдең. Ахырда, тотлыгып:

— Авырыйм әле мин, укучылар... Ярамый миңа,— дип ялганларга кирәк таптың. Гомереңдә беренче... Һәм соңгы тапкыр укучыларны алдавың...

Әмма алар синең ялганыңны бик тиз тотты.

— Ни өчен ярамаганын беләбез, Назим абый... Алар сүзенә карамагыз... Тизрәк кайтыгыз... Без көтәбез,—диләр.

мезонин — өй өстенә ясалган кечкенә корылма, чарлак
дәрәҗә — *монда:* абруй, авторитет
мөртәт — ачуланып әйтү сүзе
беравык — бераз вакыт
нахак — нигезсез, хаксыз, урынсыз

Сораулар һәм бирем

1. Өзектә Назим образы нинди кеше итеп сурәтләнә? Ул кем булып һәм кайда эшли?
2. Сабир Дунәшевны ни өчен эшеннән алалар? Назим аңа нинди киңәш бирә?
3. Газетада нинди мәкалә басыла? Бу мәкалә Назимга ничек тәэсир итә? Бу газаплы көннәрне ул ничек кичерә?
4. Демонстрациядән соң укучыларның Назимнарга килүе нәрсә аңлата? Укучылар алдында Назим үзен ничек тота?
5. Бүлекне өлешләргә бүлеп, аларның эчтәлеген сөйләгез.

Унберенче төн

Җаны барның — өмете бар, диләр...

Мәктәптә укулар тәмамлану белән үк, Әнвәр җил-җил кайтып төште ул җәйне. Энекәшләре: Айраты — Урта Азиягә, Дамиры Бөгелмә ягына практикага киткәннәр иде. Әнвәр, кайтып кергән көнендә үк:

— Әни, сузарга ярамас, әйдә язып җибәрик әле. Кузгатырга вакыт җитте безгә дә,— диде.

Сузаммы соң! Ничә еллар көт тә... Язып җибәрдек Мәскәүгә Верховный Совет Президиумы исеменә. Алай ук ашыкмаслар дип, күңелемдә купкан дулкыннарны басыбрак йөрергә тырыштым. Әмма, хәйран хәл, ун көн дигәндә, җаваплары килеп тә төште: «Хатыгызны Валунскига прокуратурага җибәрдек. Ирегезнең эшен тикшерү белән хәбәр итәрләр»,— дигәннәр... Аптырамаслык түгел, Назим, теге елларда ничәмә-ничә хат

язып та, ник берсенә җавап килсен! Гел суга агызып җибәргән кебек була торган иде. Ә бит, уйлап карасаң, власть шул ук...

Әнвәрнең холкын беләсең, бер-ике атна түзеп йөрде-йөрде дә:

— Валунскида берәр бюрократ кулына эләгүе бар. Ярты юлда тукталу ярамас, әни, әйдә тагын бер языйк әле, кузгатыйк әле үзләрен,— дип, мине котырта да башлады.

Ләкин безгә Валунскига хат язып, эшне кабат кузгатып маташырга туры килмәде. Үземне чакырттылар. Телеграмма да җибәрделәр, эшләгән җиремә телефоннан шылтыратып та әйттеләр. Җитмәсә, юлын да үзләре түлиселәр икән...

Самолетка утырып очып киттем. Таныш кала, таныш урамнар, йортлар... Йөрәгемне уч төбемә тотып барып кердем. Юк, тау башындагы соры йортка түгел. Өлкә суды президиумы белән прокуратура урнашкан ак йортка. Гостиницадан әллә ни ерак түгел...

Следователь булгандыр, ахры, ачык карашлы, хәтта артык игътибарлы, артык әдәпле бер ир уртасы кеше мине киң өстәл каршысына утыртып, озак кына хәл-әхвәл сорашты. Ничек яшибез, малайлар әйбәт укыймы, кәефләр ничек, фәлән дә төгән... Белмим, әллә үзен киң күңелле, яхшы кеше дип танытасы килде, әллә ипле-әдәпле сөйләшүе белән мине әкрен-әкрен коточкыч ударга әзерләве иде...

Хәзер уйлыйм менә: авыр, чиксез авыр вазифа йөкләнгән булган икән аңа... Ниһаять, ул, ипләп-җайлап кына төп мәсьәләгә күчеп:

— Сезнең көчле ихтыярлы, нык хатын икәнлегегез күренеп тора, шунлыктан сезгә һичнәрсәне шомартмый-нитми турыдан-туры әйтергә мөмкиндер дип уйлыйм мин,— диде.— Сез моны үзегез дә сизеп торасыз: ирегез хакында ул,— диде.

Тынымны кысып, йөрәгемнең атлыгып тибүен тоеп:

— Тыңлыйм сезне...— дидем.

— Җинаять составы булмау сәбәпле, тройканың карары юкка чыгарылып, ирегез акланды. Менә өлкә суды президиумының шул хактагы карары,— дип, кулыма ярты бит зурлыгындагы кәгазь тоттырды.

— Монысына рәхмәт... «На десять лет без права переписки» дигәннәр иде миңа... Үзе кайда соң ул? Исәнме? — дип инәлеп, күзләренә текәлдем.

— Алай дип, сезгә дөрес хәлне әйтмәгәннәр. Кызганычка каршы, ирегезнең гомере бик кыска булган.

«Ничек кыска? Әйтеп бетерегез инде, ник тукталдыгыз?» — дип кычкырмакчы идем, бугазыма төер кунды, телем әйләнмәде.

Ул, минем кулдан тотып, авыр сулап:

— Сезнең яннан китеп ике ай торуына, утыз сигезенче елның унсигезенче гыйнварында ук...— диде.

Бугазымнан авыр таш атылып чыккандай булды:

— Булмас! — дип кычкырып җибәрдем.

— Тынычланыгыз... Сез бит батыр хатын, Мөнирә Фәхриевна... Нишләмәк кирәк? Ул ачы дөреслекне яшерә алмыйбыз хәзер,— диде.

Ярый әле валерианка тоталар икән. Шуны тамызып, су эчерде, кулымда бөгәрләнеп беткән ярты бит кәгазьне ридикюлем эченә салып куйды...

Тетрәнүдән-ярсудан хәлемә килер-килмәс:

— Ә без аңа, тамагыбыздан соңгы ризыкны бүлеп, ике ел буена төрмәгә передача ташыдык... Исемлектә тоталар иде аны... Ризыкны күптән инде вафат булган кешегә ташыганбыз икән,— дип пышылдадым.

Монысына җавап таба алмады, иреннәрен генә тешләде.

Гостиницага мине машина белән озатып куйдылар. Секретаре, тагын да мөлаемрак хатын, озак кына янымда тынычландырырга тырышып утырды. Хәлемә тиз килә алмадым. Тормышта әллә ниләр кичереп кырысланган йөрәк бирешми икән ул... Нәрсә диде әле ул хатын? Әйе:

— Ирегез Жилиннар, Березиннар белән бер төнне атылган... Соңгы минутларында «Интернационал»ны җырлый башлаганнар алар... Сез горурлана аласыз ирегез белән,— диде.

Интернационал... Горурлану... Белеп әйтте микән ул хатын?

— Нинди гаеп ташлаганнар соң аңа? — дип сорадым.

— Гаеп түгел, пычрак... Җыен юк-бар... Ирегезнең эше буенча Кариледән чакыртылган кешеләр һәммәсен юкка чыгарып, ялган дип тапты. Ә берсе үзенең яла ягуын танып, чәчләрен йолка-йолка елап утырды,— диде.

— Кайсы икән ул? — дидем.

— Фамилиясен хәтерләмим... Исеме Зиля иде, ахры,— диде.

— Зөләйха?.. Ах, сволочь! — диюдән бүтән сүз әйтә дә алмадым.

Менә бит кабахәт җан!.. Юк, башыма сыймый... Белмәдем теге чакны: юрган астына кертеп, кундырып йөртүләр түгел, бугазын чәйнәп өзгән булыр идем мин аның!.. Шул Фатихы, шул еланы котырткандыр әле. Үзенең акылы җитмәс иде... Менә кем ашаган икән сезнең башларны, Назим! Соң булса да, белеп кал!

Кариледән синең артыңнан киткәннәр берсе-бер кайтмаган дисәм, дөрес үк булмас: Мәхмүт Муллакаев, ун ел утырып, исән-имин сакланып калган. Ләкин авылына кайтырга рөхсәт итмәгәннәр. Хәер, кайтса да, ни мәгънә? Хатыны күптән инде фамилиясен дә алмаштырган, ул да җитмәсә, сугыштан соң икенче иргә чыгып, яңабаштан семья корып җибәргән...

Самолетка утырып кире Шөмбеткә кайтып төштем мин. Әнвәр мин алып кайткан кәгазьгә бик озак карап уйланып торды. Аның да башына сыеп бетмәгәндер инде...

— Кара сакалдан котылдыгыз, улым... Ичмаса, шунысы ярый,— дидем.

Йөзе кырысланды, җитдиләнде.

— Ярты бит кәгазь...— дип пышылдады. Бүтән сүз әйтмәде.

җәбер-золым — изү, кыерсыту
хакыйкать — дөреслек, чынбарлык
хәйран — гаҗәп, искиткәрлек
аклану — гаепсез табылу

Сораулар һәм бирем

1. Назимның гаепсезлеген ачыклау өчен, гаиләсе нәрсәләр эшли? Монда Мөнирәнең нинди сыйфатлары күзгә ташлана?
2. Назимга нахак ялалар ягуда кемнәр катнашкан? Ни өчен дип уйлыйсыз?
3. «Кара сакалдан котылдыгыз, улым... Ичмаса, шунысы ярый» дигән җөмләне ничек аңлыйсыз?
4. Әсәрне тулысынча укып чыгыгыз.
5. Репрессияләр чоры турында язылган тагын нинди әсәрләр укыганыгыз бар?

Лотфулла Фәттахов
(1918—1981)

Рәссам Лотфулла Фәттахов (Лотфулла Әбделмән улы Фәттахов) 1918 елда Түбән Новгород өлкәсенең Сергач районы Анда авылында туа. Башлангыч белемне авылда ала, бик яшьли шигырьләр яза башлый, рәсем ясый. 1940 елда Казан сәнгать училищесын тәмамлый. Ләкин сугыш аны яраткан рәссамлык эшеннән аера: Лотфулла Фәттахов фронтка китә. Сугыш еллары, яралану, үлем лагере, аннан качу... Эльбада ул яңадан безнең гаскәрләр белән очраша һәм, сугыш беткәнче, азатлык өчен көрәшә.

Лотфулла Фәттахов — тематик картина жанрында аеруча зур уңышларга ирешкән рәссам. Аның әсәрләрендә халык тормышы киң яктыртыла.

«Туган ил турында җыр», «Яшьлек» (1955), «Игеннәр өлгерде» (1952), «Күчмә лабораториядә» (1954), «Әни күрмәгәндә», «Толя», «Сабантуй» һәм башка зур күләмле әсәрләре белән Лотфулла Фәттахов татар сәнгатен баетуга зур өлеш кертте.

Сәнгать өлкәсендәге уңышлары өчен Л. Фәттаховка 1951 елда СССРның Дәүләт премиясе бирелә, ә 1958 елда ул Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның халык рәссамы Лотфулла Фәттахов әсәрләренә сокланып, Гомәр Бәширов болай дип яза: «...бигрәк тә үзенчәлекле, шуның өстенә бик тә нечкә каләмле рәсемче. Ул хәзерге заман кешесенең рухи дөньясын тирәнтен хис итә, аның уй-тойгы-

ларының иң нечкә борылышларына кадәр тотып ала да аны сокланырлык дәрәҗәдә оста һәм истә калырлык итеп сурәтли белә».

Сорау һәм бирем

1. Сез Лотфулла Фәттаховның нинди картиналары белән таныш?
2. Лотфулла Фәттаховның «Игеннәр өлгерде» картинасы буенча план нигезендә сочинение языгыз.

План.

1. Картинада елның кайсы вакыты сурәтләнгән?
2. Иген басуына кемнәр килгән?
3. Алар нәрсә турында сөйләшәләр? (Диалогны үзегез төзеп карагыз.)
4. Бу кешеләрнең йөзләре нинди? Ни өчен аларга сокланып карыйсыз? Картина нинди хисләр уята?
5. Картинаның эчтәлеген ачуда буяуларның роле бармы?

Терәк сүзләр: *иң матур чак, күксел рәшә, зәңгәрсу урман, яссы таулар, алтын-сары төс, аяз күк, җәйге челлә, басу киңлеге, ягымлы йөз, мөлаем йөзле, хезмәт дәрте, зур уңышлар, икмәк байлыгы — ил байлыгы, хезмәт шатлыгы, кеше тудырган муллык, байлык, матурлык, каерылып уңган арыш, тәҗрибәле аксакал, агроном, бригадирлар.*

«Казанда яшәгән бөек кешеләр» дигән темага сөйләшү өчен сораулар

1. Казан шәһәре тарихыннан нәрсәләр беләсез?
2. Казан элек-электән фән, гыйлем үзәге булган. Н. И. Лобачевский, Н. Н. Зинин, А. М. Бутлеров кебек мәшһүр галимнәр турында нәрсәләр сөйли аласыз? Медицина өлкәсендә танылган галимнәрдән кемнәрне беләсез?
3. Татар халкының тарихын, тел белемен өйрәнүче галимнәрдән кемнәрне беләсез? Ни өчен Каюм Насыйри, Шиһабеддин Мәрҗаниләрне мәгърифәтче галимнәр дибез? Р. Фәхреддин кем ул?
4. Әдәбият-сәнгать өлкәсендә танылган шәхесләрдән кемнәрне беләсез? Казан шәһәре алар турында нинди истәлекләр саклый?
5. Мулланур Вахитов, Хөсәен Ямашев, Мирсәет Солтангалиев кебек тарихи шәхесләр турында нәрсәләр беләсез?

Фәнис Яруллин

(1938 елда туган)

Татарстан Республикасының халык шагыйре Фәнис Яруллин (Фәнис Гатаулла улы Яруллин) 1938 елның 9 февралендә Татарстанның Баулы районы Кызылъяр авылында туа. Җидееллык белемне туган авылында ала, сигезенче сыйныфны Баулыда тәмамлый. 1954 елда «Татнефть» берләшмәсенең Баулы элемтә оешмасында монтер булып эшли башлый. 1957 елда гаскәри хезмәткә алына. Анда һава укчы-радистлар мәктәбендә укый, спорт белән мавыга. Күнегүләрнең берсендә, турниктан егылып, умыртка сөяген имгәтә һәм гомергә йөри алмас хәлдә кала.

Озак еллар урын өстендә ятуына карамастан, Ф. Яруллин бөтен тырышлыгын, рухи көчен үзенең белем дәрәҗәсен күтәрүгә, әдәби иҗат эшенең серләрен үзләштерүгә юнәлтә: 1963 елда экстерн тәртибендә урта белем ала, 1970 елда читтән торып укып, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Уку һәм озакка сузылган дәвалану белән бергә, ул шигырьләр, проза һәм драма әсәрләре иҗат итә. Аның кешелеклелек, халыкчанлык, тормышчанлык белән сугарылган әсәрләре әдәбият сөючеләр арасында уңыш казана. «Мин тормышка гашыйк», «Җилкәннәр җилдә сынала», «Әнә килә автомобиль», «Һәркемнең үз сукмагы» һәм башка шигырь, проза, сәхнә әсәрләре әнә шундыйлар.

«Җилкәннәр җилдә сынала» — автобиографик повесть. Әсәрдә Фәниярның бөтен тормышы, эш-хәрәкәтләре, Илсөя белән гаилә корып җибәрүе ышандырырлык итеп тасвирлана. Билгеле, никадәр генә тырыш булмасын, Фәнияр-Фәнис бары-

бер кыенлыкларны ялгыз гына җиңеп чыга алмас иде. Тормыш юлында аңа яхшы күңелле кешеләр очрый.

Бу әсәрдән соң иҗат ителгән «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра», «Чәчәкләр моңы», «Кайту», «Яралы язмышлар» повестьлары, «Һәркемнең үз сукмагы», «Туган көн бүләге» җыентыкларына һәм башка томлыкларына кергән хикәяләре, юмор-сатира әсәрләре, очерклары белән Ф. Яруллин укучылар арасында иң популяр язучыларның берсе булып танылa.

1964—2000 елларда әдипнең барлыгы утыз өч исемдә проза һәм шигъри китабы басыла. Шулардан «Аерылмас дустым» (1975) һәм «Сулыш» (1978) шигъри җыентыклары өчен автор 1978 елда Татарстан яшьләр оешмасының Муса Җәлил исемендәге премиясенә, лирик шигырьләре һәм поэмалары тупланган «Җан авазы» (1994) исемле китабы өчен 1995 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

Әдипнең иҗат лирасында Татарстан һәм Башкортстан театрларында куелган дистәдән артык сәхнә әсәрләре дә бар.

Татар әдәбиятын үстерүдәге зур уңышлары өчен Фәнис Яруллинга Татарстан Президенты М. Шәймиевнең 2001 ел 13 февраль Указы белән «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән исем бирелде. Ул шулай ук 1985 елдан «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем йөртә, Халыклар дуслыгы ордены кавалеры (1985).

ҖИЛКӘННӘР ҖИЛДӘ СЫНАЛА

(повестьтан өзекләр)

10

Шигырьләре газетада басылып берничә көн үткәч, Фәниярга хатлар килә башлады. Хатларны күбрәк кызлар яза. Кызлар күңеле кылдан нечкә, кылычтан үткен шул: ни кирәген хәзер тоеп ала, юатырга ашыга.

Хатларның күбесендә егетнең батырлыгына соклану белдерелгән.

Батырлык! Нәрсә соң ул батырлык? Газинурлар, Матросовлар шикелле, күкрәгең белән дошман амбразурасын каплаумы, әллә үзең ач чакта соңгы сыныкикмәгең белән бүлешү-

ме? Кешеләр төрле-төрле булган кебек, батырлык та күп төрле шул.

Берәүләрне тормыш гомергә бер генә сыный. Кеше дөнья зилзиләләренә каршы үзенең кечкенәдән үк җыеп килгән гайрәтен, ана сөте белән кереп тамырларына таралган көчен куя. Куя да өстенә ябырылып килгән бөтен авырлыкларны бер селтәнүдә юкка чыгара. Шул мизгелдә каушап калмаганнарны батыр диләр.

Икенчеләрне тормыш көн саен, сәгать саен сыный. Алар күкрәкләре белән дошманның ялкын чәчеп торган дзотларын япмыйлар, галәм биеклекләренә күтәрелеп, дөньядагы барлык кешеләрнең карашларын үзләренә юнәлтмиләр. Туктаусыз тамып торган тамчыдай, сиздерми генә, шау-шуларсыз гына эшлиләр. Беренче тамган тамчыны һичкем игътибарга алмый. Тама-тама ташны тишеп чыккач кына тамчыга сокланалар. Ә ташны тишеп чыкканчы, ай-яй озак тамасы бар!.. Ничә язлар көтәсе бар, ничә кышлар үтәсе бар...

Фәнияр әле ташны тишә алдымы соң? Моны батырлык дип атап буламыни? Язылган хатларның эшләнмәгән эшкә әйтелгән рәхмәт кенә икәнен яхшы белә ул. Әле бу күкрәгең белән дулкыннар ярып диңгездә йөзү түгел, яр читендәге талларга тотынып аяк чапылдату гына. Хәзер эшкә чын-чынлап тотынырга, аңа ышаныч белән карауччыларның ихтирамын казанырга кирәк. Аның көченә ышанучыларның йөзен кызартмас өчен генә дә тырышырга кирәк.

Ул элек тә төрле мәзәкләр, кызык әкиятләр уйлап чыгарырга оста иде. Беренче шигыре басылып чыккач, фантазиясе бигрәк уйнап китте. Берничә атна эчендә әллә ничә шигырь язып ташлады. Шигырьләрнең күпчелеге балалар өчен язылган иде. Үзенә ошаган байтак әсәрен аерым дәфтәргә туплап, «Яшь ленинчы» газетасына җибәрде. Фәнияр газетадан җавап болай тиз килер дип уйламаган иде. Хатны Илдус Гаделшин дигән кеше язган. Бу кешенең шигырьләрен Фәниярнның газета-журналларда укыганы бар иде. Республика газеталарының берсендә эшләүче, шигырьләрен калын журналларда бастыручы шагыйрьнең хатын тыныч кына укый алмады Фәнияр.

«Әллә ничә мәртәбә укыгач кына, шигырьләреңнең берничәсен ошаттык, бер-ике атналардан басылып чыгар, газеталарны караштырып бар» дигән сүзләрне укый алды Фәнияр. Илдус Гаделшин хатның ахырында Фәниярның кем булуы, укучы булса, ничәнче класста укуы турында сорашкан.

Фәнияр аңа үзенең авыру кеше икәнен, шигырьләр язарга бик яратуын, әмма шигырьләренең бер дә шәп чыкмавын язды. Илдус Гаделшин Фәнияр язмышына битараф калырга теләмәде. Гомерендә бер тапкыр да күрмәгән, ләкин берничә хаты аша шактый якын булып өлгергән Фәнияр йоклаганда да аның уеннан чыкмады.

Ниндирәк кеше икән? Акыл утырткан кешеме, әллә тормышның беренче ялкыннарына канаты өтелгән яшь җилкенчәкме? Шигырьләрендә дөнья күргән кешеләрнең генә башына килердәй фикерләр белән сабыйларча беркатлылык янәшә тора. Янына барырга, күрергә кирәк!

Илдус Гаделшин редакциядән өч көнлек командировка алып Фәнияр яшәгән якка юл тотты. Фәниярның туган авылы Кызыл Кыяга килү кыен булмады. Бөгелмәгә хәтле самолет, аннары тип-тигез асфальт юлдан йөрүче автобус өч-дүрт сәгать эчендә китереп тә җиткерде...

Илдус килеп кергәндә, Фәнияр укып ята иде. Ят кешене күргәч, китабын караватына куйды. Ике таныш түгел кеше бик кыска гына вакыт эчендә бер-берләренең күзләренә карашып алдылар. Фәниярның күзләре искиткеч тереләр, әйтерсең бөтен хәрәкәте күзләренә күчкән. Ябык кулларын күрмәсәң, ял итәргә генә яткандыр дип уйларга мөмкин. Фәнияр, үзе янына Казан тикле җирдән шагыйрь килүенә ышанып җитмәгәндәй, күзләрен Илдус Гаделшиннан алмады. Яшькә Фәниярдан биш яшькә генә зур икән. Шулай булса да чәчләре шактый сирәкләнгән, чалара башлаган урыннары да күренгәли. Күрәсең, шигырь язу бик җиңел түгелдер. Чәчләренә чал керсә дә, ачык чырайлы булгангамы — йөзе яшь.

Алар, бер-берләрен күптән белгән кешеләр кебек, «син» дип сөйләштеләр. Илдусның кулында шома папка. Сөйләшеп, хәл-әхвәл сорашулар беткәч, шул папкасындагы кәгазьләр арасыннан «Яшь ленинчы» газетасы табып алды.

— Көткән кешегә озак тоелгандыр, бер-ике атнадан шигырьләреңне басарбыз дигән идек. Менә ташка басылгач ничегрәк булган, укып кара,— дип, газетаны Фәниярга бирде.— Мин элегрәк тә килергә уйлаган идем, шигырьләрең басылсын инде дидем. Коры кул белән барасы килмәде.

— Ә мин, Илдус абый, син безгә килерсең дип башыма да кертеп карамадым. Язучы кешеләрне бөтенләй башка төслеләрдер дип уйлый идем.

Илдус аның сүзләренә каршы:

— Язучылар да безнең кебек үк кешеләр анысы, ләкин мин үземне хәзергә язучы дип саный алмыйм әле. Ул бик зур исем, туганкай.

— Ну, Илдус абый,— диде Фәнияр,— синең шигырьләрең өлкә газета-журналларында еш басыла бит. Китабың да бардыр инде.

— Анысы чыгып җитмәде шул әле. Шушы көннәрдә чыгып җитәр дип өметләнеп йөрим.

Фәнияр китапларның, газета-журналларның ничек басылуларын сорашты. Илдус бер дә иренмичә белгәннәрен сөйләде. Фәнияр Гаделшинның сүзләрен, әкият тыңлаган баладай, кызыксынып тыңлады. Барлык язучыларны күреп белгән, шулар белән бергәләп очрашулар үткәргән Гаделшинга кызыгып һәм сокланып карады ул.

Илдусның Казан каласыннан үзенең улы янына килгән олы кунак икәнен белгәч, Гөлсәйдә дә бик куанды. Кабаланып, өстәл әзерләргә кереште.

Ашап-эчеп алгач, Илдус Фәниярның шигырь дәфтәрләрен сорап алды. Илдус бик туры сүзле кеше икән, начар язылган шигырьләрне күрсә, дәфтәрендә ята бирсеннәр, аларны кешеләр укымаганнан һични югалтмаслар дип, ул битләрне тизрәк актарып үтәргә тырышты. Ә инде матур әйтелгән ике генә юл очратса да, түш кесәсендәге бармак буе карандашын чыгарып, шул юлларның астына калын итеп сызды. «Менә монысы шәп ичмасам, Фәниярча әйтелгән»,— дип, ул сүзләрне үзе уйлап тапканнан ким куанмады.

Күңеленә ошаган шигырьләрне Илдус күчереп ала барды. «Кайткач, өлкәнрәк агайларга күрсәтеп карармын, әлегә бернинди дә вәгъдә бирә алмыйм,— диде ул.— Син бик өметләнеп ятма, Казаннан корреспондент килде дә, хәзер ни язсам, шул басылыр дип. Зур эшкә тотынгансың икән, барысына да түзәргә кирәк. Мин сиңа турысын әйтәм: яза аласың, сәләтең бары күренеп тора. Әмма шигырь язар өчен ул гына җитми: тырышлык, белем, туктаусыз эшләү, кимчелекләреңне күрә белү һәм тагын әллә нәрсәләр. Яза-яза үзең дә төшенерсең әле. Ә хәзергә сиңа иң кирәге — системалы белем. Шунсыз син ерак китә алмаячаксың. Яшьлегең турында, сөйгән ярларың турында берничә дистә бер-берләренә охшаш әйберләр язарсың да туктарсың. Аннары учагыңда күмер сүнәр».

Илдус Гаделшин шагыйрь булуның бик җаваплы эш икәнлеге турында сөйләде. Ул Фәниярга үгет-нәсыйхәт тә

укымады, менә болайрак яз, тегеләйрәк эшлә дип күрсәтмәләр дә бирмәде. Язарына темалар да сайлашмады. Аның сөйләгән сүзләре бер Фәнияр өчен генә түгел, үзе өчен дә иде. «Без хәзер бер тәртәгә җигелгән атлар»,— дип, Фәниярны үзе белән тиңләштерде. Антын яңартучы солдат кебек тойды ул үзен яшь шагыйрь янында.

11

Илдус Гаделшин, килдем-киттем, эшем бетте, ди торган кеше булып чыкмады. «Мәктәптә минем бераз йомышым бар иде»,— дип чыгып китте. Анда ул дирекция һәм укытучылар белән егетне шефка алу хакында сөйләште. Фәниярны укыту турында сүз кузгаткан иде, әмма Кызыл Кыя авылында урта мәктәп киләсе елларда гына ачылырга тиешлеген әйттеләр. Илдус, укытучылар белән сөйләшкәннән соң:

— Әгәр мөмкин булса, мин укучыларга берничә сүз әйтер идем,— диде.

— Бик әйбәт,— диде директор.— Озын тәнәфес вакытында җыярбыз үзләрен.

Тәнәфестә укучыларны коридорга җыйдылар. Директор, сүз алып:

— Менә Казаннан килгән корреспондент иптәш, сезгә сүзем бар,— ди. Шауламыйча гына тыңлагыз,— дип, балаларны кисәтеп куйды. Илдус, теге папкасыннан газетаны чыгарып:

— Бу газетаны беләсездер инде, кайсыларыгыз ала? — диде. Мин алам, мин язылдым, дигән берничә тавыш ишетелде.

— Бүгенге санда сезнең авыл шагыйре Фәнияр Гатауллинның шигырьләре басылган. Бу газета сезгә килеп җитмәгәндер әле. Мин ул шигырьләрне сезгә укып күрсәтәм.

Балалар шым булдылар. Илдус ашыкмыйча гына укыды. Шигырьләр кызыклы иде, көлешкән тавышлар ишетелә башлады. Укып туктагач, Илдус, балаларга карап:

— Авылыгызда шагыйрь барын белә идегезме? — дип сорады.

Беркем дә җавап бирмәде. Кайберәүләр аның шигырьләрен район газетасыннан укыган булсалар да, газетадан килгән кеше алдында батырланасылары килмәде. Әллә нинди сорау биреп, төп башына утыртып куяр я. Дәшмәүдән шәбе юк. Илдус, иелгән башларга карап:

— Ә бит аның турында район газетасында «Районыбызның Островские» дип язып чыкканнар. Берничә тапкыр

шигырьләре басылган. Ә сез авылыгызда шундый кеше яшәвен белмисез. Әйбәт түгел, дуслар.

Укучыларның башлары тагын да түбәнрәк иелде. Гаделшин Фәнияр турында озак сөйләде. Каләмне бик авырлык белән тотуы, уйланылган әсәрләрен кәгазьгә күчерү өчен әллә ничаклы көч түгүен әйтте.

— Без аның янына барып йөрербез, абый,— диештеләр балалар чын күңелдән.— Шигырьләрен дә күчереп язарбыз...

Шулай итеп, кайбер кузгалырга исәбе юкларны үзенең «каләм очына» алып, кабат Фәнияр янына кайтты Илдус. Ә Казанга киткәндә янә бер кат:

— Син, Фәнияр туган, газетада эшләгәч, бу бөтенесен булдырыр дип уйлама,— диде.— Бернигә карамыйча яз, каләмеңне шомарта тор. Уңышсызлыклар, кыенлыклар очраган саен йокы дарулары җыя башлама. Безнең эштә зур түземлелек кирәк. Ә синең өчен бу икеләтә шулай.

Зур вәгъдәләр биреп китмәгәч, Фәнияр, бу абый китәр дә онытыр, дип уйлаган иде. Әмма атна-ун көн уздымы-юкмы, яшьләр газетасында да, балалар газетасында да Гаделшинның мәкаләләре басылып чыкты. Ул мәкаләләр Фәниярның язмышы, киләчәге өчен чын-чынлап борчылып һәм кешеләрне үз тирәсендәге ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә карата игътибарлырак булырга чакырып язылган иде. Шунда ук Фәниярның фотосын һәм шигырьләрен биргәннәр.

Фәнияр өчен бөтенләй яңа, шау-шулы тормыш башланды. Язгы ташу вакытында елганы күзәткәләгән кеше беләдер: бозлар бер тирәгә җыелалар да агып китә алмый торалар. Елга буыла, сулар күтәрелә, тик бозлар кузгала алмый. Шул вакыт әллә ни зур булмаган бер боз агып килә дә тыгылып торган бозларга китереп бәрә. Тегеләре, шуны гына көткәндәй, шарт-шорт киләләр, сыналар, ватылалар һәм кузгалып китәләр. Бер юл алгач инде башкалары тоткарлыксыз ага.

Моңарчы Фәниярга бары авыру дип кенә караучылар, Казаннан килгән корреспондентның сүзләреннән соң, Фәнияр янына агыла башладылар. Ялгызлыктан иза чигеп, иркенләп сөйләшергә сусаган, язган шигырьләрен кемгә укып күрсәтергә белмичә йөдәгән егет бер генә сәгатькә дә кешесез калмады. Фәнияр озак вакытлар караңгыда торып, кинәт яктыга чыккан кешедәй хис итте үзен. Карады, тирә-юнендәге кешеләрне аермады, сөйләште. Язган бер шигырен иң элек өйдәге ала мәчегә укып күрсәтә торган иде, Фәнияр тирәсендә ят

кешеләр кайнаша башлагач, ала мәче мич башынарак күчендә һәм, «ярар, мин дә кирәк булырмын әле» дигәндәй, ерактан гына күзләрен елтыратып ята башлады.

Фәниярның бу уңышлардан бераз башы да әйләнеп алды. Ул язган әйберләренә карата таләпчәнлеген югалтты. Төрле редакцияләргә чиле-пешле шигырьләр җибәреп, басылып чыгуларын көтте. Редакциядән әсәрләренең кимчелеген күрсәткән хатлар килсә — турсайды. Ачуы килде. Газета-журналлардан йомшаграк шигырьләр укыса, болар да минекеннән артык түгел, аларныкын басканнар, дип үпкәләп ятты. Үзе йөри алып, әсәрләрен үз куллары белән илтеп бирсә, һичшиксез, басарлар шикелле тоелды. Кайчак кешегә бераз ташламалар да ясап була бит инде дип уйлады.

Бу чир, бәлки, озаккарак та сузылган булыр иде, Илдус Гаделшин каты гына итеп Фәниярга хат язып җибәрде. Әдәбиятта беркемгә дә ташлама ясалмавын, яшьме яки картмы, тазамы яки чирлеме — анысы укучы өчен әһәмиятле түгеллеген әйткән һәм укучыларның язган әсәрләргә карап фикер йөртүен, үзең чирле булсаң да, «сәламәт» әсәрләр язарга кирәклеген төшендергән. Башкаларга тиз хәтере калса да, Илдуска үпкәләмәде Фәнияр. Фәниярның һәр уңышлы сүзе өчен чын-чынлап шатланучы бу эчкерсез абыйга ничек ышанмаска кирәк? Әнә бит һаман да Фәнияр турында кайгыртудан туктамый. Сине Казан больницаларының берсенә алдыру турында Язучылар берлегендәге өлкән агайлар белән сөйләшеп, исләренә тагын бер кат төшердем, дигән. Бәлки, шушы көннәрдә синең белән Казанда очрашырбыз, дигән.

Казан больницаларының берсендә дәвалану, зуррак профессорларга күренеп карау — Фәниярның күптәнге хыялы. Районда ятканда, әллә ничә мәртәбә әйтеп карады Фәнияр Талип Таһировичка. Тыңларга да теләмәде тегесе: «Бездә бөтен больницаларда да бер үк метод белән дәвалыйлар», — диде. Ә инде үзе турындагы шигырьләрне укыгач, бу турыда авыз ачып карарга да мөмкин булмады. Ләкин Фәниярның өмете киселеп бетмәгән иде әле. Өмет дигәнең җиргә күмелгән орлык шикелле бит ул: уңайлы вакытны көтеп кенә ята. Кайчак орлыкны да бит инде тишелеп чыкмастыр, корып һәлак булгандыр дисең. Ә ул бер җылы яңгыр явып үттеме, катып беткән җирне нәп-нәзек борыны белән тишә дә чыга. Ә бер төртеп чыккач, кояш нурларына тотынып үсә, ныгый, шәбәя.

Фәнияр да, өч ел ятуга карамастан, терелүдән өметен өзгәне юк. Бик белдекле, оста врач кулына гына эләгергә кирәк. Кабат операциясен дә ясар, тиешле даруларын да табар. Нәпнәзек нервларны ялгау нәрсә тора. Заманасы нинди бит, заманасы! Өметләнмәслекмени? Космоска очалар, тавыш тизлегеннән зур тизлекле самолетлар уйлап табалар, әлек еллар буе бораулап та төшеп җитә алмаган девон катламнарына ун көндә труба сузалар. Гектарыннан тартып-сузып сигез-тугыз центнер арыш алган басулардан егермешәр-утызар центнер уңыш каералар. Кичә әкият итеп сөйләнелгән нәрсәләр бүген чынга әйләнә, кичә булмаган дарулар бүген уйлап табыла. Шундый заманда ничек инде өметеңне өзәсең?!

Ә көннәрдән бер көнне Фәниярга телеграмма китереп тоттырдылар. Анда, шушы араларда Фәниярны Казан больницасына алып китәр өчен самолет җибәрәчәкләрен әйтеп, әзер булып торырга кушылган иде. Фәнияр бу хәбәргә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Ничек инде бер кеше өчен самолет тикле самолет җибәрсеннәр?!

Әзерләнергә кушылгач берни эшләр хәлең юк, ышанмасаң да, юл капчыгыңны төйнәп куярга туры килә. Гөлсәйдә аналарга гына хас өлгерлек белән юлга җыена башлады. Чемоданга әллә никадәр әйберләр тутырганын күргәч, Фәнияр аңа:

— Мин бит, әнкәй, кунакка җыенмыйм, больниска барам, нигә шулхәтле тутырасың? — диде.— Күчтәнәчләп бармасам да, кире бормаслар.

— Син генә түгел, мин дә барам,— диде ана.

— Син анда кайда тормакчы буласың? Әллә үзеңне бик көтеп торалардыр дип беләсеңме?

— Көткән җиргә кем дә бара,— диде ана.— Бер башыма кайда да урын табармын. Синең караватың янына урындыклар куеп булса да йоклармын. Җан биргәнгә, җүн бирер дигәннәр бит.

Фәнияр әнисен берничек тә калырга күндерә алмады.

Ике көннән авыл башына самолет килеп төште. Анда очучыдан башка бер сестра да бар иде. Әлек председательне йөрткән, ләкин идарәгә җиңел машина бирелгәч, эшсез калган кара айгырны җигеп, Фәниярны алырга килделәр. Арбага салам түшәп, өстенә матрац салдылар.

Карт-корылар да, бала-чагалар да этә-ега Фәнияр янынарак үтәргә тырыштылар. Һәркем бер үк сүзне кабатлады:

терелеп, үз аякларың белән кайт! Фәниярның мондый хөрмәткә күңеле нечкәреп китте. Кешеләргә сиздермәскә тырышып, күзләрен кул аркасы белән сыпырып алды. Ләкин шатлык яшьләрен сөртеп кенә бетерерлек түгел иде. Сестра һәм очучы, җыелган халыкны читкәрәк куалап, самолеттан носилка алып төштеләр. Нәкъ шулвакыт, озак йөгерүдән сулуы кабып, Нәсимә килеп җитте. Әллә аның артык кабалануын, әллә ак халатын күреп, халык юл бирде. Нәсимә, саубуллашып, Фәниярның кулын кысты. Гөлсәйдәнең дә улы белән китүен белгәч:

— Гөлсәйдә апа, алайса, мин сиңа бер адрес язып бирим әле, Казанда безнең җизниләр бар,— дип, кесәләрен кармаштыра башлады. Ләкин кесәсендә кәгазь-каләм табылмады. Шулвакыт кешеләр төркеме арасыннан берәү каләм, икенчесе кәгазь сузды. Кыз, ашыга-ашыга адрес язып, Гөлсәйдәнең кесәсенә салды:

— Алар Савинка поселогында үз йортлары белән торалар. Нәсимә җибәрде дисәң, кертерләр,— диде.

Озак сөйләшеп торырга вакыт булмады. Самолетка Фәнияр белән Гөлсәйдәне утырттылар да очып та киттеләр. Самолет, авыл өстен бер ураганнан соң, Казанга юл алды.

битараф — гамьсез
үгет-нәсыйхәт — киңәш
йөдәгән — аптыраган
чиле-пешле — өлгермәгән
турсаю — үпкәләү

Сораулар

1. Нәрсә ул батырлык? Сез аны ничек аңлыйсыз?
2. Фәнияр кемнән хат ала? Хат аңа ничек тәэсир итә?
3. Илдус Гаделшин кем ул? Сез аңа нинди бәя бирерсез?
4. Илдус Фәниярга ничек ярдәм итә? Аның яхшылык итүен сез ничек бәялисез?
5. Сезнең ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә ярдәм иткәнегез бармы?

16

Фәнияр Казан больницасында ярты ел ята инде. Сәламәтлегендә әллә ни үзгәреш булмаса да, бирегә килү зыян итмәде. Күп кенә язучылар белән танышты. Ә иң әһәмиятлесе, шушы ярты ел эчендә тугызынчы класс программасын тула-

ем үзләштерде. Укытучылар: «Хәзер иркенләп ял ит, әкилә-се елда без тагын килербез. Урта мәктәпне тәмамларсың»,— дигәннәр иде, ләкин Фәнияр вакытны әрәм үткәрергә теләмәде.

— Көч җитсә, унынчыны да быел бетермәкче идем мин,— диде ул.

— Авырга килер бит,— диделәр укытучылар.

— Бернәрсә дә җиңел генә бирелми инде, һәркөн саен минем янга килеп йөрү сезгә дә җиңел түгелдер,— диде Фәнияр.

Үзенә ун-унбиш көнлек каникул ясап алганнан соң, Фәнияр тагын укырга кереште. Аңарга шул ук укытучылар дәрес бирделәр. Берсе дә авырсынмады. Барыннан да бигрәк Марина Викторовна якын итте. Палатага килеп керүгә, башта шаярып ала:

— Җитәр инде, ялкауланып күп яттың, аягыңа басарга вакыт.

Озаграк күрешми торырга туры килсә, Фәниярның маңгаеннан үбеп исәнләшә. «Мине укучыларым басып каршы алалар, син кайчан басып каршылыйсың инде?» — дип көрсенеп куя.

Марина Викторовна һәрвакыт диярлек үзе белән диафильмнар алып килә. Больницада врачлар юграк чакка туры килсә, палата саен кереп, урыннарыннан тора алмаган авыруларга шул диафильмнарын күрсәтеп йөри. Аңарга тыңлаучы гына булсын: сөйләргә вакытын кызганмый.

Илсөя дә больницага еш килеп йөри хәзер. Үзе дә унынчы класста укыганлыктан, күп вакыт дәресләрен Фәнияр белән бергә әзерлиләр. Фәниярга аның белән рәхәт. Ничектер егет күңеленә тиз кереп урнашты Илсөя. Була бит шулай: хәтта гомереңдә бер тапкыр күрмәгән кешене дә хыялыңда тудырасың. Төсен-битен, холкын-фигылен, сөйләшүен-көлүен күз алдыңа китерәсең. Хыял тарафыннан тудырылган бу кешенең кайчан да булса очраячагына ышана башлыйсың. Сиңа очраган, бигрәк тә авыр чакта дуслык кулы сузган кешеләрдән хыялың тудырган кешенең билгеләрен эзлисең.

Ә Илсөянең күңеле сизгер. Егетнең үзен көтеп алганлыгын аңлый. Ярдәм итәргә, ничек тә бер яхшылык эшләргә тели. Ул, беркөнне Фәниярның врачы Галина Измайловна янына кереп:

— Миңа Фәнияр турында сөйләгез әле,— диде.— Аңарга нинди ярдәм кирәк?

— Сезнең килеп йөрүегез аның өчен зур ярдәм инде,— диде Галина Измайловна.— Ул, бирегә килгәндә, ничектер кешеләргә ышанмыйчарак карый иде. Баштарак мин аның белән рәтләп сөйләшә дә алмадым. Ә хәзер бөтенләй башка, шундый хирыслык белән укып ята. Киләчәккә өмете уянган. Менә шуны сүндермәскә кирәк безгә.

— Аңарга кан җибәреп булмыймы? — дип сорады Илсөя.— Мин аңа үземнең канымны бирер идем. Бәлки, файдасы тияр...

Ачынып-ачынып кеше язмышын кайгыртып йөрүче бу кызга җылылык һәм ярату белән карады врач. Фәниярга ярдәмгә килергә теләүчеләр көннән-көн арта, димәк, аның сәләтенә, көченә ышаналар. Кан җибәреп кенә аякка бастырып булса, врач үз канын да жәлләмәс иде. Шулай да Илсөянең күңелен төшерәсе килмәде аның.

— Аңарга язучылар курортка путевка юллап йөри бугай. Бәлки, файдасы тияр әле,— диде.

Илсөя, барасы курортны көтеп торырга теләмичә:

— Хәзер бит космоска кеше очыралар, йөрәкләрне күчереп утырталар, нервларны да күчереп булмыймы соң? — диде.— Мин бер газетада ул турыда укыган идем. Ниндидер бер профессор этләргә тимер нерв куйган, ди. Бәлки, хәзер кешеләргә дә куя башлаганнардыр. Тимерне куймасалар, мин үземнекеләрен дә бирер идем.

— Әйе, фән бер урында тормый, берзаман кешеләргә дә тимер нервлар куя башларлар. Ничә гасырлар буе атомны бүленми торган кисәкчә дип санаганнар, ә безнең гасыр кешесе аның эченә үтеп керде бит,— диде Галина Измайловна, кызны юатырга теләгәндәй.

Әмма Илсөянең егеткә үзеннән нәрсә дә булса бирәсе килә. Кеше гомере гасырлар белән исәпләнми, һәр көн кадерле. Тизрәк Фәниярны аякка бастырырга иде. Моны ничек эшләргә? Шул сорауга җавап бирсен иде врач.

— Бәлки, аны Мәскәү, Ленинград кебек зур шәһәрләргә алып барып күрсәтергә кирәктер?

— Бик теләгән очракта Мәскәүгә алып барырга да мөмкин, әлбәттә. Тик...

Илсөя аның тел төбен яхшы аңлады. Артык сорашып маташу файдасыз иде. Күңелсезләнеп врач яныннан чыгып китте. Фәниярга ул Галина Измайловна белән сөйләшүен әйтеп тормады. Палатага һәрвакыттагыча ачык чырай белән

керде. Фәнияр бүген бик озак эзләнүләрдән соң ачыш ясаган кешедәй шатланган.

— Янымарак утыр әле, Илсөя,— диде ул түземсезләнеп.— Ә хәзер кулыңны бир, язмышыңны укып карыйм.

Илсөя кыяр-кыймас кына аңа кулын бирде. Егет, кулдагы сызыкларга караган булып, сөйләп китте:

— Исемең Илсөя инде, ансын кулыңа язылмаса да беләм. Эшең бик югарыда икән, шуңа күрә егетләргә бераз өстәнрәк карарга өйрәнгәнсең...

— Мин чынлап сөйли дип торам тагын,— диде Илсөя.

— Шаярып сөйләмим, мин сине күптәннән беләм икән, Илсөя. Кайда күргәнем бар икән бу кызны дип әллә ничә көн баш ваттым. Тәки искә төште бит. Мин сине армиягә киткәнче күргәнмен.— Һәм Фәнияр Татвоенкомат ишегалдыннан ничек итеп кранга утырып чыкканын кызга сөйләде. Илсөя дә ул вакыйганы онытмаган икән, чөнки шул шуклыгы өчен беренче мәртәбә эшендә шелтә алган. Беренче шелтә, беренче мәхәббәт шикелле, тиз генә истән чыкмый. Кранына бер төркем кеше утыртып койма аша чыгарганын хәтерләсә дә, Фәниярны таный алмады Илсөя. Ә бит еш кына исенә алгалый иде ул егетне.

Илсөянең шул вакытта очраткан кыз икәнен белгәч, ни өчендер Фәнияр бик шатланды. Кыз аңа тагын да якынаебрак китте. Больницага Илсөя килмәгән көннәрне ничек үткәрергә белмәде. Егет йөрәгендә мәхәббәт кабынып килә иде.

Мәхәббәт үтеп керә алмаган бернинди стеналар юк. Төрмәләрнең тимер ишекләре дә, больницаларның таш стеналары да, юлларны бүлеп торган биек кыялар да, ургып-ургып аккан елгалар да киртә була алмыйлар аңа. Кешеләр, диңгезләр кичеп, карурманнар гизеп, бер-берләрен табышалар.

Мәхәббәт бер яклы гына икән, сүндерергә дә мөмкин әле. Бер йөрәк ут, икенчесе су булганда, ялкын бар дөньяны чолгап ала алмый. Ләкин Илсөянең дә күңеле тыныч түгел. Мендәргә башын төртүгә йоклап китә иде, хәзер сәгать икеләргә кадәр урыны өстендә әйләнә. Күзләрдән йокы, күңелдән тынычлык качты. Йокласаң, төшкә керә, күзләрне йомсаң, күз алдына килә, эштән туктасаң, уйларны биләп ала Фәнияр. Нәрсәгә шулай якын соң ул? Чибәр-чибәр егетләр артыннан өерләре белән йөргәндә дә, сөйләшеп тормыйча кереп китә иде бит Илсөя. Ә Фәнияр...

Аның дулкынланып торган кара чәчләрен сыйпыйсы, хәрәкәтчән коңгырт күзләренә туйганчы карыйсы килә. Ул күзләр Илсөя килеп керү белән шулкадәр җанланалар, ялкынланалар, әйтерсең әйбәтләп эшкәртелгән алмаз бөртегенә төрле яктан яктылык юнәлдерәләр. Илсөя, гадәттә, кичләрен килә Фәнияр янына. Шуңа күрә шаярып Фәнияр беркөн болай диде:

— Минем хәзер ике кояшым бар, Илсөя. Берсе аның иртәнге алтыларда тәрәзәдән төшә, икенчесе кичке алтыларда ишектән керә.

— Ишектән кергән кояшны күргәнем юк әле минем,— диде Илсөя.— Хәзер кичке алты бит инде, кая соң ул кояшың?

— Менә ич, кырыемда утыра,— диде егет, Илсөянең кулларын үзенең бите буйлап йөртеп.

Фәниярның сүзләреннән Илсөя кызарды. Битендәге ялкын чәчләренә кабар төсле тоелды.

— Алай әйтмә, Фәнияр,— диде ул.— Мин нинди кояш булыйм? Төзелештә эшләүче бер кранчы кисәге генә бит мин. Әле дә инде иптәш кызлар үртәп туймыйлар, сиңа шагыйрь ошап китте, больницадан кайтып та кермисең, диләр. Җитмәсә, химия китабына шигырь язып җибәргәнсең. Аны үземә чаклы иптәш кызларым күреп алганнар. «Химия китабы дигән идек, әдәбият икән бу, әнә шигырьләр язылган»,— диләр. Ачып карасам исләрем китте.

Әйе, Фәнияр ул шигырьне яхшы хәтерли:

Чокырлы ияккәем,
Сөйкемле сөяккәем.
Сине бер көн күрми торсам,
Өзелә үзәккәем,—

диелгән иде анда.

Нишлисең бит, яхшымы, яманмы — Фәнияр шагыйрь кисәге. Күңелендәген дә шигырьләр белән аңлатырга тырыша. Тазамы син, авырумы — яшьлек үзенекен итә. Үбешү тәмен татып карамаган иреннәр назга сусаган. Кызлар кулы сарылмаган иңнәр шул кулларның йомшаклыгын тоярга тели. Татлы мәхәббәт сүзләре ишетмәгән колаклар шул сихри сүзләрне ишетергә ашыга.

тулаем — тулысынча, ботенләе белән
авырсынмады — читенсенмәде
хирыслык — көчле теләк
тел төбе — сүзнең эчке мәгънәсе

Сораулар һәм бирем

1. Фәниярның белем алуга омтылышы нәрсәләрдә күренә?
2. Мария Викторовна аның тормышында нинди роль уйный?
3. Илсөя кем ул? Аның Фәнияр турында кайгыртуын ничек бәялисез?
4. Илсөягә характеристика бирегез.

19

Фәниярның курорттан китәр көннәре дә якынлашып килә. Ләкин кая барырга? Казанда торыр урыны юк. Ел буе ятып, тәмам туйдырган больницаны исенә төшерсә дә калтырана башлый. Авылга китсә — ботенесе юкка чыга. Ә бит аның хыяллары зур: югары мәктәп тәмамлап, кешеләр алдында кызармаслык әсәрләр иҗат итү. Авылда институтлар да, язучылар да юк.

Ул, Казан больницасына килү белән, шәһәрдән үзенә бирәр бүлмә бирүләрен сорап гариза язган иде. Аннан соң бер ел вакыт үтте. Ә бүлмә һаман булырга ошамый. Нишләргә? Кемнән киңәш сорарга? Илдус Гаделшинны да туйдырып бетергәндер инде. Алар үзләре дә бер бүлмәдә дүртәү яшиләр. Гомер буе шәһәрдә торган кешеләр дә шундый кысан фатирларда яшәгәч, авылдан килгән исемсез-эшсез малайга кем квартира тоттырсын?

Күп уйлый торгач, «кая кайтыйм» дип, Язучылар берлегенә телеграмма суктырды. Аңа бер-ике айдан квартира вәгъдә итүләрен, әлегә больницада ятарга туры киләчәген әйтеп җавап бирделәр. Бүлмә дигән нәрсәнең чынлап булачагына ышанып җитмәсә дә, тагын больницага кайтты ул. Хәзер аны дәваламадылар.

Фәнияр Илсөягә хәбәр җибәрде. Ә кыз килгәч:

— Илсөя, миңа китаплар кирәк. Университетка әзерләнә башларга иде исәп,— диде.— Шушы бер ай эчендә әзерләнмәсәм, бер елым юкка чыгачак.

— Сиңа ял итәргә иде,— диде Илсөя.

Кыз Фәниярны курорттан терелеп кайтыр дип көткән иде, өмете акланмады. Тормыш кайчакларда рәхимсез шул. Эш сорап куллары кычыткан, яңа юллар ярыр өчен йөрәге атлыгып торган кешеләрне шәфкатьсез рәвештә ега да ташлый. Ә эшкә кулларын тыгарга чирканып, җиңел кәсеп эзләүчеләр сәламәт йөриләр. Яшеннәр сукса агачларның биеген суга шул.

Һәр җил искән саен бөгелеп, яшенле яңгырлар вакытында зур агачлар ышыгына яшеренгән сыек үсентеләргә берни тими. Ә Фәнияр, авыруына үч иткәндәй, бернигә карамыйча алдына куйган максатына баруын дәвам итә. Тормышка теше-тырнагы белән ябышкан. Кешеләр ярдәменнән башка әйләнеп тә ята алмаган килеш университетта уку турында хыяллана. Булдыра алырмы? Хәлсезләнеп, түземе җитмичә кире бөкләнмәсме?

Университетка керү имтиханнарын больницада тапшырырга туры килер дип ята иде Фәнияр. Көтмәгәндә Илдус Гаделшин аңа шатлыклы хәбәр китерде.

— Давай, Фәнияр туган, миңа паспортыңны бир, ышаныч кәгазе яз, бүлмәңә ордер алырга барам,— диде ул.

Фәнияр шатлыгыннан сикереп торырдай булды. Ләкин иртәрәк сөенгән икән. Үзенең паспорты юклыгы исенә төште.

— Ә минем паспорт юк, Илдус абый. Армиягә киткәндә, военкоматта алып калганнар иде.

— Паспортыңны тапшырганда, берәр справка биргәннәрдер бит?

— Биргәннәр иде. Югалмаган булса авылдадыр.

— Алайса, хәзер үк авылга телеграмма сугарга кирәк. Бөтен документларыңны җыеп, әниең килсен. Квартирада син ялгызың гына яши алмыйсың бит инде.

Шул ук көнне, хәлне аңлатып, авылга телеграмма җибәрделәр. «Улым кайда — урыным шунда» дип өйрәнгән Гөлсәйдә ике көннән килеп тә җитте. Ләкин көтелгән документлар гына булмады. Справка каядыр юкка чыккан. Гомер буе авылда көн күргән Гөлсәйдәнең шулай ук бернинди документы юк иде. Улы белән икесенә Фәниярның метрикасыннан башка һичнинди язу-фәлән тапмадылар. Илдус, ни булса булыр дип, Фәниярдан ышаныч кәгазе яздырып алып больницада раслатты да, паспортын тотып, шәһәр башкарма комитетына китте. Анда артык төпченмәделәр тагын, ордерны биреп җибәрделәр. Кулына ордер һәм квартира ачкычы бирелгәч, Фәниярның бер генә көн дә больницада ятасы килмәде.

— Әйдә, алып кайтыгыз мине,— диде ул әнисенә.

— Анда берни дә юк бит әле, балам,— диде Гөлсәйдә.

— Миңа бернәрсә дә кирәкми, бер карават, бер мендәр булса — җитә.

— Кухнясына газ кермәгән, ванна куелмаган. Анда кайтып нишләмәкче буласың? — диде Илсөя дә, ананы яклап.— Юасы, җыештырасы бар.

— Яңа йортның нәрсәсен юасың, нәрсәсен җыештырасың аның? — диде Фәнияр.

Фәниярны тагын берничә көн түзәргә күндерделәр. Илсөя үзенең ике иптәш кызы белән яңа квартираны җыештырырга килде. Алар төзелештә эшләп һәммәсен өйрәнеп беткәннәр. Гөлсәйдәнең кулына чүпрәк тә тоттырмадылар. Кырдылар. Юдылар. Агарттылар.

Илсөя Гөлсәйдәне үзләренә кунарга алып китте. Гөлсәйдә, идәндә дә йокларлмын, бармам инде, дип маташкан иде, әмма Илсөя аның ай-ваена карамады:

— Синең идәндә йоклар чагың үткән инде,— диде.

Фәниярга кайбер нәрсәләр алырга Язучылар берлегеннән йөз сум акча бирделәр. Гөлсәйдә белән Гаделшин йорт җиһазлары сатыла торган кибеттән ул акчага бер өстәл, ике тимер карават һәм берничә урындык сатып алдылар. Гөлсәйдәнең үзенең дә әзрәк байлыгы бар икән: аңарга түшәк-ястык, бераз савыт-саба юнәттеләр. Шуннан соң Фәниярны больницадан алып кайттылар. Кысан больница палаталарында ятарга күнеккәнлектән, унсигез квадрат метрлы бүлмә Фәниярга искиткеч зур булып тоелды.

— Ниһаять, әнкәй, безнең дә үз куышыбыз булды.

— Яңа йортта яңа бәхетләр насыйп булсын, балам.

...Университетка имтиханнар тотар вакыт та җитте. Фәнияр шундый зур уку йортына керә алырмын дип уйламаган иде. Тырышкан тапкан, ташка кадак каккан, диләр бит. Әзерләнде, тырышты егет. Ә кабул итү имтиханнарын алырга аның өенә килделәр. Барысы да әйбәт барды. Тик чит телдән генә бераз сынатты ул.

Университетта уку Фәниярга ялгызлыктан котылуга да әйбәт чара булды. Курсташ студентлар аның янына килделәр, үзләре язып барган лекцияләрне калдырдылар, китапханәләрдән кирәкле китаплар ташыдылар. Тормыш кызыкланып китте. Кеше өчен зур җәза — ялгыз калу белән эшсезлек бит. Дуслары Фәниярга ялгыз калырга да, эшсез ятарга да ирек бирмәделәр. Таләп иттеләр, ялкаулана башласа, тиргәп ташладылар.

өмете акланмады — ышанычы тормышка ашмады
юнәттеләр — булдырдылар, таптылар
чара — эш

Сораулар һәм биремнәр

1. Курортта дәваланып кайтканнан соң, Фәнияр тормышында нинди үзгәрешләр була?
2. *Яшен сукса, агачларның биеген суга шул.* Автор бу юлларга нинди фикер салган?
3. Фәниярга нинди сыйфатлар хас? Кайсыларын сез үзегездә дә булдырыр идегез? Ни өчен?
4. *Тырышкан тапкан, ташка кадак каккан* дигән мәкальнең мәгънәсен аңлатыгыз.
5. *Кысан, имтихан, сөенеч* сүзләренең синонимнарын әйтегез.
6. Фәнияр белән Гөлсәйдә апа яңа шартларга ничек җайлашалар?
7. Язучы Илдус Гаделшин Фәнияр тормышында нинди роль уйный дип уйлыйсыз?
8. Повестьны тулысынча укыгыз.

АНА

(баллада)

Авыру ана ята түшәктә,
Йөзе сулган, тәне ябыккан.
Өмет итми шифа-дарулар
Тормыш дигән олы табибтан.
Үтәсе юл инде үтелгән,
Күрәселәр бар да күрелгән.
Кузгаталмас кебек ананы
Һичнәрсә дә яткан җиреннән.
Очып килә шулчак диңгездән
Бер акчарлак тәрәз каршына:
— Әй ана,— ди,— очыйк диңгезгә,
Бу җирләрдә һава тар сиңа.
Авыруларың суга салырсың,
Давыллардан гайрәт алырсың.
Канатыма минем атланып,
Юлларга чык әйдә, шатланып.
Безнең якта сулар шифалы,
Авыру белмәс тәнең һичкайчан.
Бик аз калган шушы гомереңне
Үзең өчен яшә, ичмасам.
Акчарлакка ана эндәшә:
— Матурдыр да диңгез илләре,
Ерак юлга ләкин чыгарга
Калмады бит тәннең егәре.

Кузгатмас мине урыннан,
Ялынса да килеп фәрештәм.
Якынайды инде әҗәлем,
Аяк тавышын аның ишетәм.
Диңгезләргә очкач акчарлак,
Тәрәзәгә килә сандугач:
— Барыйк,— ди ул,— гөлләр иленә,
Юлга чыгыйк, ана, таң тугач.
Саф чишмәләр күп,— ди,— илемдә,
Матур җырлар — кошлар телендә.
Синең өчен булыр барсы да,
Ашык әйдә бәхетең каршына.
Сандугачка ана эндәшә:
— Әйбәттер дә чәчәк илләре,
Ерак юлга ләкин чыгарга
Калмады шул тәннең егәре.
Тора алмам яткан җиремнән,
Чакырса да килеп фәрештәм.
Якынайды инде әҗәлем,
Аяк тавышын аның ишетәм.
Үз иленә очкач сандугач,
Тәрәзәне ачып җил керә.
Карт анага улы турында
Ул бик авыр хәбәр китерә.
Ишеткәчтен яман хәбәрне,
Торып баса ана шул ара,
Баласына килгән җил-давыл
Түшәгеннән аны кубара.

шифалы — файдалы
егәр — көч
фәрештә — ангел
яман — начар
кубара — торгыза, күтәрә

Сораулар һәм бирем

1. Балладада нинди образлар белән таныштыгыз?
2. Акчарлак һәм сандугачка ана нәрсә дип җавап бирә? Улы турындагы хәбәрне ул ничек кабул итә?
3. Ни өчен бу әсәр баллада дип атала?
4. Балладаны ятлагыз.

Баллада

Баллада итальян телендә *бию* дигән мәгънәне белдерә. Ул — лиро-эпик шигъриятнең бер жанры. Балладаларга җанлы яки җансыз табигатьне һәм җәмгыять күренешләрен персонажлаштырып, әйберләрне җанландырып, геройларның батырлыгын һәм фаҗигале үлемен югары күтәреп тасвирлау хас. Ягъни алар — нигездә, романтик рухлы әсәрләр.

Татар әдәбиятында балладалар иҗат итү 1941—1945 елларда активлашты. М. Җәлил «Ана бәйрәме», «Сандугач һәм чишмә», Ф. Кәрим «Үлем уены», «Тимер һәм тимерче», Ә. Фәйзи «Кара таш ник дәшми?» кебек балладалар иҗат иттеләр. Сугыштан соңгы һәм хәзерге чор әдәбиятына күз салсак, Ә. Давыдовның «Малайлар турында баллада», Ә. Маликовның «Таңбатыр», Р. Вәлиеваның «Бала мәхәббәте турында баллада», Зөлфәтнең «Вәгъдә» әсәрләре дә — балладаның матур үрнәкләре.

ИҢ ГҮЗӘЛ КЕШЕ ИКӘНСЕЗ

Килгән чакта башка авырлык,
Җитми калса көч я сабырлык.
Сиздермичә ярдәм иткәнсез —
Сез иң күркәм кеше икәнсез.

Балаларның теле — кыңгырау.
Гел чыңгылдый — ява мең сорау.
Барысына да җавап биргәнсез —
Сез иң гүзәл кеше икәнсез.

Укып чыгып, дөнья тануны,
Бәхетебезне эзләп табуны
Зур ышаныч белән көткәнсез —
Сез иң сабыр кеше икәнсез.

Мактагансыз тиеш урында,
Яклагансыз тиеш урында.
Безнең өчен сез тир түккәнсез
Сез иң гүзәл кеше икәнсез.

Сораулар

1. Бу шигырь кемнәргә багышланган?
2. Ни өчен шагыйрь укытучыларны иң күркәм, гүзәл, сабыр кешеләр дип атый?
3. Укытучылар Фәниягә ничек ярдәм итәләр? Аеруча кемнәрнең ярдәмен билгеләр идегез?



Миргазиян Юныс
(1927 елда туган)

Күренекле язучы Миргазиян Юныс (Миргазиян Закир улы Юнысов) 1927 елның 25 маенда Татарстанның Баулы районы Исергәп авылында крестьян гаиләсендә туа. 1944 елда армиягә алына, хәрби авиация мәктәбендә укый. Аннан соң авиация училищесын тәмамлый, эскадрильядә хезмәт итә. Хәрби хезмәттән кайткач, 1955 елда Мәскәү университетының филология факультетына читтән торып укырга керә. Шул ук вакытта Кара диңгез пароходчылыгында эшли, чит илләргә йөри торган сәүдә корабләндә капитан ярдәмчесе вазифаларын башкара. 1968—1977 елларда диңгез транспорты фәнни-тикшеренү институтында гыйльми хезмәткәр, «Наука и религия» журналында бүлек мөдире булып эшли. Диңгезгә булган мәхәббәте 1977 елда аны тагын элекке һөнәренә алып кайта, ул сәүдә корабында йөзә башлый. 1988 елдан башлап фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Миргазиян Юныс әдәбиятка зур тормыш тәҗрибәсе туплап килә. Сәүдә флотларында эшләп, ул бөтен дөньяны диярлек әйләнеп чыга, төрле милләт халыкларының тормышы белән таныша, төрле гыйбрәтле хәлләргә тап була. Тора-бара бу истәлекләр аны кулына каләм алырга мәҗбүр итә. «Безнең өй өянке астында иде...», «Энже эзләүчеләр», «Кочегар», «Йәмәнгә сәяхәт», «Диңгезче Хәнифә», «Янар таулар», «Тимер фил», «Занзибар зәңгәр болытлар артында», «Тозлы җил», «Таңда Босфор аша» һ. б. әсәрләре — чын мәгънәсендә дөнья гизеп язылган әсәрләр. Язучының «Табу һәм югалту»,

«Шәмдәлләрдә генә утлар яна», «Юлда уйланулар» кебек әсәрләре — очучы, диңгезче хезмәте турында язылган әсәрләр.

Язучының әсәрләре ифрат кызыклы, киң мәгълүматлы, тирән эчтәлекле. Ул, нәрсә турында гына язса да, милли яңарыш максатларын күз уңында тотып һәм шул ук вакытта милләтләр арасында тигез хокуклылык принципларын, гаделлекне яклап яза, ялганны, җәбер-золымны фаш итә.

Соңгы елларда Миргазиян Юныс бигрәк тә публицистика, әдәби тәнкыйть, эссеистика жанрларында актив эшли.

ШӘМДӘЛЛӘРДӘ ГЕНӘ УТЛАР ЯНА

(повестьтан өзекләр)

Өченче бүлек

1

Заданиенең уңышлы тәмамлануына тулысынча ышанса да, Сәләховның күңеле бөтенләй үк тыныч түгел иде. Нәрсәдер әкрен генә аның йөрәгенә шом сала, күңелендә астыртын шик пыскый иде. Биеклеккә күтәрелгәч, шик югалачак, ачык тәвәккәллек барлыкка киләчәк. Сәләховның шушы халәтне ничә тапкыр сынаганы булды. Ул һәр сугышчан заданиене гадел үтәргә өйрәнде, ләкин заданиене башкарып чыгу турында алдан ук борчылмаска үзен өйрәтә алмады.

Сәйрин ашханә бинасын тагын бер кат урап чыкты. Тәрәзә яныннан узганда, туктап, бертын ашханә залына карап торды. Ашханә эчен чиста итеп җыештырганнар. Түшәмгә аскан хрусталь люстрадан яктылык коела. Шул яктылыкка күмелеп, ашханәдә ике кеше ашап утыра. Сәләховның йөрәгенә сөенечле рәхәт бер җылылык йөгерде. Шундый якын, шундый газиз иде аңа бу ике кеше. Аларның бер табында утыруларында борынгыдан калган чын якынлык һәм көчле бердәмлек бар иде. «Хәзер кузгалачаклар»,— дип уйлады ул экипаж турында. Дусларының ашханәдән чыгуын Сәләхов түземсезлек белән көтә башлады.

Тәрәзә каршында ялгыз юкә агачы үсә иде. Сәйрин шул агач янына туктады. Авылда, аларның баскычлары төбендә, нәкъ шуның буйлы тирәк үсә. Тирәк исенә төшкәч, Сәләхов-

ның күңелендә юкә агачына карата кардәшлек тойгысы уянды. «Чит ил. Германия җире. Кешеләре — ят, телләре аңлашылмый. Ә агачлары гел безнеке шикелле,— дип уйлады Сәйрин.— Табигать нинди бөек! Ул үзенең бәрәкәтен һәр илгә, һәр халыкка тигезләп өләшкән. Беркемне кимсетмәгән, беркемгә дә артыгын бирмәгән. Ә шушы хакыйкатьне аңламау — адәм баласының комсызлыгы — җирне күбрәк эләктерер өчен күрше өлешенә керергә, аның җирен яулап алырга мәҗбүр иткән. Сугышны комсызлык тудыра. Сәбәпсез үлемнәр, кан коюлар — бар да шуннан. Җитмәгәнмени фашистларга үз җирләре?»

Балачак та шушы тирәкләр кебек садә, саф, гөнаһсыз бит. Күкрәк тутырып, саф һава сулыйсың, йөгерәсең, уйныйсың. Көне буе иректә, табигать кочагында. Кояш баеганда, әти-әниең эштән кайта. Малларны карап абзарга япкач, Сәләховлар гаиләсе тирәк төбенә кичке чәйгә җыела иде. Табын янында очрашу шундый рәхәт. Тирәк ботаклары аша кичке йолдызлар җемелдәгәне күренә. Сәйриннең әнисе аклы яулыгын чөеп бәйләгән. Янып-пешеп чәй ясый. Башта агач кашык белән чынаякларга каймак сала, аннан соң чәйнектән чәй агыза. Чәй агызганда, борынга хуш ис килеп бәрелә.

Әтисе табын янында һәйкәлдәй мәгърур утыра белә иде. Әйтерсең аны патша итеп куйганнар. Аңа карау белән, «әтиебез исән чакта, дөньяда бернинди афәт, гаделсезлек һәм кимсетү булмаячак» дип ышана идең. Чыннан да, ул исән чакта гаиләгә җил-яңгыр тимәде. Күп иде авылда Сәйриннең әтисе ише кешеләр. Ышанычлы, нык, чыдам нигезгә корылган бәхетле гаиләләр дә күп иде.

Өстенлек итү — тынгысыз тойгы. Өстенлеккә омтылу ифрат мәшәкатьле. Әтисенең гаилә белән идарә итүе өстенлеккә көйләнмәгән иде. Аның һәр сүзенә, кылган эш-гамәленә Аллага ышанган шикелле ихлас күңелдән ышаналар иде. «Әтиегез болай эшләгәнне ярата...», «Әтиегез!» — иң катлаулы мәсьәләне әнә шул сүз хәл итә иде.

Әнисенең төп бурычы — гаилә эчендәге дустанә мөнәсәбәтләрне, туганлык, татулык хисен саклау иде. Бу вазифасын Сәйриннең әнисе сокланырлык итеп үтәп килде. Шунлыктанмы, Сәләховлар гаиләсендә яшәү тыныч һәм рәхәт иде. Шундый уңайлы иде гаилә куенында көн күрү.

«Барлык илләрнең җитәкчеләрен бергә җыеп, безнең баскыч янындагы тирәк төбенә утыртасы һәм әни ясаган чәйне

эчереп карыйсы иде,— дип, Сәйрин юләрләрчә хыялланып куйды.— Шуннан соң да җир йөзендә гаугалар калыр идеме икән?»

Агач янында басып торганда, Сәйрингә тынычлык иңде, аның уй-хисләре, кыйбла табып, бердәм ага башладылар.

Юкә агачыннан бал исе аңкый иде. Сәйрин, якынрак килеп, кәүсәгә сөялде: «Без җаваплы заданиегә очабыз,— диде ул эченнән генә.— Син, яз җиткәч, яфрак ярасың, көзен, аларны җиргә коеп, кышка әзерләнәсең. Син — зирәк һәм мәрхәмәтле агач. Гомереңдә бер генә бөҗәккә дә зыян китергәнең юк. Без, адәм балалары, кайчан синеңчә дөрес һәм матур яши башларбыз икән? — Егет бертын тыңлап торды.— Ярый, мин китәм. Безгә исәнлек телә. Безнең кайтканны көтеп тор. Кайткач, тагын яныңа килермен. Хуш...»

Сәләхов ашханәдән чыгып килгән иптәшләренә кушылды.

2

Җилкәләренә парашют салып, караңгылыкны ерып баручы өч егет яланда адашып калган өч моңсу торнаны хәтерләтә иде. Хисләндерә, күкрәк эченә моң тула иде төнге очуга барганда.

Без туганнан бирле шушы җирне таптап йөрибез. Бер карaганда гап-гади җир, бары туфрак кына. Очарга җыена башлагач, ул кинәт шундый газиз, шундый кадерле тоелып китә. Җиргә моңа кадәр тиешле ихтирам күрсәтә алмавыңа хәтта сабыйларча үкенә башлыйсың.

Самолет тирәсендә, гадәттә, очыш алдыннан була торган ыгы-зыгы башланган иде инде. Әледән-әле электромоторлар гөжелдәп ала. Кесә фонарьларының уты кабынып-сүнеп киткәли. Авиатехникларның саран гына фикер алышулары ишетелеп куя иде.

Менә самолетның моторын да кабыздылар. Мотор берничә мәртәбә ютәлләп алды да дырылдап әйләнергә тотынды. Әйләнү һаман тизәя, тигезләнә бара иде. Озакламый мотор тавышы тоташ үкерүгә әйләнде. «Тизлеккә чыдый алмыйча, металл елый,— дип уйлады тавышны дикъкать белән тыңлап килүче укчы-радист.— Безнең экипаж очасы машинаның моторы. Әйлән, тизрәк җылын».

Аэродромдагылар, самолетка юл биреп, читкә тайпылдылар. Сәләхов уң як моторга көчле газ бирде. Самолет зәһәр

итеп үкерде дә теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгалды. Очкыч, борылып, старт ягына таба йөгерергә тотынды.

«Башланды»,— дип уйлады штурман Майнагашев.

«Тәңрем, бу гамәлемне сиңа багышладым»,— дип, ярым җитди, ярым шаярта төшеп дога кылды Ялчинский.

Ә бу вакытта экипаж командиры: «Болытлар гына таралмаса ярар иде»,— дип уйлый иде.

Җирдән аерылган мизгелдә очкыч беренче адымын атлаучы сабый баланы хәтерләтә. Беренче тапкыр оясыннан чыккан кош баласы да шундый була. Әле канатлар ныгымаган, көч чамалы, тәҗрибә тупланмаган. Биеклектә шундый җитез, шундый кыю самолет җирдән күтәрелә башлаганда кинәт югалып кала. Хәрәкәтләре шундый сүлпән, шундый кыюсыз тоела: аның күтәрелеп китә алуына шикләнеп куясың.

Сәйриннең оча башлаганына өченче ел тулып килә иде. Тәҗрибә җитәрлек. Ул Пе-2 нең бар нечкәлекләрен үзләштерде диярлек. Ә җирдән күтәрелеп киткәндә, аңа самолет таралып төшәр шикелле тоелып китә иде. Курку йөрәкне чеметеп ала. Җир ерагая башлагач кына, тынычланып китәсең.

Сәләхов, ашыгып, шассиларны җыйды. Тизлек кинәт артып китте. Самолетның очуына ышаныч керде. Яшәү дә шулайрак бит: максатыңа барганда, өмет ышанычлырак була. Өмет канатлары, тормыш вак-төяге өстеннән күтәреп, сине югарыдан алып бара.

Моторлар гөжләве, очкыч тәненең тигез дерелдәве җанга тынычлык бирә иде. Хәзер Сәләхов мөстәкыйль һәм азат иде. Һавага күтәрелгән кешегә беркем ярдәм дә итә, комачаулый да алмый. Син — мөстәкыйль. Очкыч белән язмыш аша тоташкан. Өстә чиксез зәңгәр күк. Ышанычың — сәләтең. Җир кануннары аста, еракта калдылар. Алар инде сине буйсындыра алмыйлар.

Пе-2, ерактан урап, аэродром өстенә чыкты һәм астан карап торучылар алдында маршрутка ятты.

Кинәт тирә-якны караңгылык чорнады. «Болыт эченә кердек,— дип уйлады Сәләхов.— Калынлыгы күпме икән?» Тәрәзәләрнең тышкы ягыннан, нечкә җепкә эверелеп, су тамчылары йөгерә иде. Тылсымлы төнге күк күренде. Таңга каршы тоныклана башлаган йолдызлар яна. Курстан уңдарак Сәләховның төнге йокысын алган тулы ай эленеп тора. Очкыч иксез-чиксез бушлык сахрасында ялгызы йөзеп бара.

Аның эчендә — сугышчан задание үтәргә баручы өч егет. Бөрешеп утырганнар. Сәләхов моторларның эшләвен, приборларның күрсәтүен тикшереп бара. Кулы штурвалга яткан, аяклары борылу руленең педалендә. Майнагашев, навигация линейкасының верьерын шуыштырып, маршрутның икенче этабына күчү вакытын хисаплый иде.

Корыч винтлар һаваны бораулыйлар, корыч пропеллерлар миллион еллар тупланган төнге тынлыкны җимерергә тырышалар. Тынлык бирешми. Аны берьюлы җимереп ташларга очкычның көче җитми. Җирдә яшәү дәвам итә. Кешеләр изрәп йоклыйлар, ял итәләр. Сугыш вакытлыча каядыр поскан, яшеренгән. Ул кешеләрнең уянганын сагалый. Сугышчылар хәл җыялар. Фашистлар да ял итә. Аларга да ял кирәк. Машиналар кузгалганчы гына саклана торган табигый тынлык бу.

Сәйрин сугышка кадәр тынлыкның нәрсә икәнлеген аңламый иде әле. Ул чакта машина тавышы тансык тоела иде. Ул икенчедә укыганда, тынлыкны чатнатып, авыл урамына көпчәкле трактор килеп керде. Тракторны кул чабып каршы алдылар. Картлар гына нигәдер шомлана төште. «Җирне ат белән сөреп тә тамак туйдыра ала идек әле. Нигә китергәннәр бу шайтан арбасын? Коръәндәге яәҗүҗ-мәәҗүҗ шушыдыр инде? Безне дөмектерергә килә, күрерсез»,— дип сукранды күрше карчыгы. Ә хәзер шундый кечкенә тракторлардан туган танклар Җир шарын сытып, канга батырып йөри. Чалгы чүкегәндә, урамнан кыңгыраулы ат үткәндә генә ватыла торган тынлыкны тураклап, күктә самолетлар оча. Сәйрин сизә, сугыш кораллары елдан-ел туктаусыз дәһшәтләнә барачак. Хәзер аның кулында гына да егерме мең ат көче. Сугышның көче, җимерү мөмкинлеге туктаусыз үсә. Ә кеше һаман шул килеш. Аны бит таяк белән сугып та үтереп була.

Бомбалюкларда алтышар йөз килограммлы дүрт бомба ята. Бомба эчендәге тротилларда балачакта Сәйрин ишеткән әкиятләрдәге барлык җен-пәриләр гайрәте бардыр. Коралларның көче, гайрәте һаман арта бара. Бу омтылышның ахыры булырмы икән? Бомбалюктагы дүрт бомбаны штурман фашистлар өстенә ташларга тиеш. Бомба ыргытырга барганда, алда сине нәрсә көткәнен беркем әйтә алмый.

Алар өчәү. Өчесе дә яшь. Аларның әле берсе дә өйләнмәгән, берсенең дә башлаган эшен дәвам итәрлек балалары юк. Алда — фронт сызыгы. Сызыкның теге ягында — бомба

ташлыйсы объект. Шул сызык аша узганда, аларны ни каршылар? Сугыш ул — ялкын белән ут сүндерү. Исән калу турында өметләнеп үлемгә бару. Сәйрин сугышның нәрсә икәнлеген аңларга тырышып карады. Хәер, сугышны берничек тә аңлатып булмый, аны үз күзең белән күрергә кирәк. «Юк, бүтән күрергә язмасын инде»,— дип уйлады Сәләхов һәм тирә-якны күзәтергә кереште.

4

Күк йөзе әле тыныч иде. Болытлар сизелер-сизелмәс кенә кызара башладылар. Көнчыгыш күзгә күренеп алсулана бара. Шундый саф, сабыйлар сулышыдай нәзберек таң беленеп килә иде. Алсулана башлаган күккә озак карап торсаң, фәрештәләр очканы күренер кебек.

«Мондый күккә озак карарга ярамый —Алла барлыгына ышана башларсың»,— дип, Сәйрин көлемсерәп куйды.

— Фронт сызыгын үтәбез,— диде штурман Майнагашев.

Очучылар дикъкать белән тирә-якны күзәтәләр. Тәнгә киеренкелек таралган. Нәрсәдер көтәсең, йөрәкне билгесезлек чорнаган.

Болыт арасыннан яктылык бәреп чыкты һәм шундук сүнеп тә куйды.

— Ракета аттылар шикелле,— диде укчы-радист.

— Сизми калдым. Сул яктарак күренде шикелле,— диде штурман.

— Нишләп болай иртә башладылар? — диде Сәләхов.— Объект шактый ерак бит әле.

— Ун минут калды,— диде Майнагашев.

Күк йөзе һаман тыныч иде. Болыт арасыннан ара-тирә ачыклыклар күренеп китә. Ачык урында җирнең артка таба салмак кына шуышканы күзгә ташлана.

«Болытлар таралмаса гына ярар иде!» — дип, кабат тынгысызланып алды Сәләхов.

— Ракета аттылар. Монысын ап-ачык күрдем,— диде укчы-радист.

«Башланды,— дип уйлады Майнагашев,— урынны ачыклап өлгерергә кирәк». Җир күзгә чалыну белән, штурман ориентир эзләргә кереште.

Самолетның урынын төгәл ачыклавы кыен иде. Җир болыт арасындагы ачыклыктан күренеп ала да шундук күздән

югала. Хисаплап тапкан нокта белән канәгатьләнергә туры килә.

Беренче снаряд самолеттан уңдарак ярылды. Чаткы кабынып сүнде, һәм һавада ак мамыктан ясалган гигант бүреккә охшаш төтен эленеп калды. Шартлау дулкыны соңгарак калып килде. Ул килеп бәрелгәч, очкыч кинәт сискәнеп куйды.

«Мессер»лар кинәт борылдылар. Икенче мизгелдә алар күздән югалды.

— Командир, качалар фашистлар! — диде Майнагашев.

— Бензиннары бетте,— диде Сәләхов.— Шуңа күрә борылдылар. Хәзер зениткалар ата башлаячак.

Аның сүзен раслагандай, алда берьюлы өч снаряд ярылды. Өч гигант мамык бүрек һавага эленеп калды.

Көн яктырган иде инде. Күк йөзе чалт аяз. Зениткаларга шундый уңай.

— Аскарак төшәргә кирәк, командир,— диде Майнагашев.

— Булмый, җиргә болай да бик якынбыз,— диде Сәләхов.— Сул як мотор эшләми. Өскә күтәрелергә иде. Снаряд тисә, парашют белән сикерер идек. Ярамый аска төшәргә. Әз генә биеклек калсын.

Сәләхов очкычны өскә күтәрергә ниятләде. «Их, мотор көчлерәк булса иде! — дип офтанып куйды ул.— Авыр тарта... Көче җитми».

Самолет янында тагын снаряд ярылды. Очкыч янтаеп китте. Уң як мотордан ниндидер чит тавыш килә иде. Винт әйләнүдән туктады.

— Марсель, ишетәсеңме? Җавап бир! Марсель,— дип ялварып сорады Сәләхов.

«Әллә арадагы кабель өзелдеме икән?» — дип уйлады ул.

Каны азайган саен, Марсельнең тәненә хәлсезлек өстәлә иде. Һава җитми. Үпкәдә кан. Сулый башлау белән, үпкәдә голт-голт кан айкала. Сулыш аласы килә. Бер генә рәхәт сулыш. Сулыш — яшәү. Яшисе килә... Бер генә минутка булса да сузасы, яшәүне дәвам итәсе килә иде.

«...Әллә музыка уйныйлар инде? Аның әнисе түгелме икән? Күзне дә ачып булмый бит ичмасам! Хәл юк. Сулыш юк. Һәр җиргә кан тулган».

«Әтием, әнием, алма кебек ике сеңлем әз тоелды, күрәсең. Мине дә үтерделәр...» — Марсель Ялчинскийның соңгы фикере һәм соңгы сулышы шушы иде. Соңгы мәртәбә кан йот-

И. М. Воробьев рәсеме

канда, ул зәңгәр күктә, илаһи биеклектә иде. Егетнең гомере күктә өзелде...

Кабина ут кебек кызган иде. Ялкын битне ялый, күзне көйдерә. Сәләхов, кабинадан үрмәләп чыгып, бушлыкка чумды. Колакка бәрелеп, җил сызгыра. Җир тарта. Гәүдә һавада бөтерелеп аска оча. Тизлек тоелмый. Тирә-якта бушлык. Күзләр йомык. Куллар, тотынырга теләп, һаваны айкыйлар. Тотынасы, туктыйсы килә. Сәйриннең гәүдәсе, ана карынындагы бала рәвешендә бөгәрләнеп, бөрешкән иде.

«Парашютны ачарга кирәк!» Шушы фикер аның миен айкап узды. Куллар түштәге кызыл боҗрага үрелделәр. Сәйрин җан көче белән боҗраны тартып чыгарды. Парашютның ефәк тукымасы ранецтан агып чыгып өскә ыргылды. «Нигә ачылмый парашют?!»

Туракланып беткән ак ефәк бәгырьләрне ачыттырып баш өстендә җилферди иде. «Снаряд ярчыгы ерткан...» Куллар запас парашютка үрелделәр. Юк... Запас парашютны сикерергә өйрәнгәндә генә бирәләр... Тирә-юньдә бушлык иде.

Өч секунд калды.

Сәләхов талпынды, галәмне кочып алырлык итеп кулларын канат итеп җәеп җибәрде. Мәңгегә җитәрлек итеп, комсызлык белән һава йотты. Сулыш — яшәү. Зәңгәр күк, кояш... утка пешкән битнең авыртуы, күкрәктәге кайнар тойгылар — барысы да яшәү. Аста җир. Кешеләр. Тормыш. Җир котылгысыз тизлек белән якынлаша.

Бер... Ике... Өч...

Дүртенче мизгелдә Сәйрин Сәләхов җирдә иде. Урман буе. Яшел хәтфә чирәмлек. Тирә-якта зәңгәр чәчәкләр. Шундый матур, рәхимле яшел болын Сәйриннең гәүдәсен сытты. Җир биеккә күтәрелүне өнәми. Сөяк ярчыклары егетнең итек үкчәсен үтәли тишеп чыккан иде.

Елганың икенче ярына сырышып үскән зирек төбендә Максим Майнагашев ята. Аның баш өстендә өзелеп сандугач сайрый. Барон утарында бикләнеп калган көчекнең керсез сабый йөрәге дә афәтне сизеп алгандыр. Эт баласы чыелдап еларга керешкәндер.

Дулкынланып торган бодай кырына бер учлам кайнар көл сибелде. Язгы җил утлы көлне бодай тамырлары өстенә таратып ташлады. Марсель Ялчинскийның самолетта калып янган гәүдәсе иде бу. Янына бер йомарлам эрегән металл төшкәндә, тартай кош кычкырудан туктаган иде. Бераздан ул да зарын яңадан башлады. Кошлар тавышына ияреп, яшәү дә дәвам итте.

Адәм җирдән яралган, диләр. Җир шары — адәм балаларының төп йорты, аларның мәңгелек торагы. Җиргә кушылучылар бер гаилә булып тату яшиләр. Бу җирдә борынгы кабиләләр — готтлар, һуннар, кыпчаклар, немецлар һәм тагын әллә нинди халыкларның сугыш һәм сәясәт алып киткән вәкилләре ята иде. Шулар янына тагын өч төрле халык вәкиле өстәлде.

кәүсә — агач яки куакның төп сабагы
офтану — уфтану, борчылу

Сораулар һәм биремнәр

1. Җирдән аерылу, биеклеккә күтәрелү алдыннан Сәләхов нинди хисләр кичерә?
2. Татар гаиләсендәге гореф-гадәтләр турында сөйләгез. Гаиләдәге тынычлык нәрсәләргә бәйле?

3. Сәләхов ни өчен сугышучы илләрнең генә түгел, ә барлык илләрнең җитәкчеләрен җыярга иде дип хыяллана?
4. Әсәрдә нинди милләт вәкилләре катнаша? Аларның бер-берсенә мөнәсәбәтләре турында сөйләгез.
5. Һөҗүм ничек башлана?
6. Егетләрнең тормышлары ничек өзелә?
7. Беренче, икенче, өченче бүлекләргә исемнәр куегыз.
8. *Йөрәгемә шом сала, астыртын шик пыскый* фразеологик әйтелмәләрен мәгънәдәш башка сүзләр белән алыштырып әйтегез.
9. *Дикъкать, хакыйкать* сүзләренә синонимнар табып, сүзлек дәфтәрләренә языгыз.

Энҗе Мөэминова

(1924 елда туган)

Язучы Энҗе Мөэминова (Энҗе Һилалетдин кызы Мөэминова) Татарстанның Әлмәт районы Яңа Кәшер авылында туа. Хезмәт юлын мәктәптә балалар укытудан башлый. Читтән торып педагогия институтын тәмамлый.

Энҗе Мөэминова гомере буе укытучы булып эшли. Аның иҗатында балалар дөньясы, ана, бала, гаилә бәхете, яшь буынны тәрбияләү мәсьәләләре төп тема булып тора.

Ул 1957 елда яза башлый. Беренче шигырьләре көндәлек матбугат битләрендә басылып чыга. Аннан соң «Шигырьләр», «Чәчәкләр китердем», «Исемдә», «Әйтер сүзем бар» исемле шигырь җыентыклары да дөнья күрә.

Энҗе Мөэминова үзе турында болай дип яза: «Мин — авыл кызы. Авылда тудым. Авылда үстем. Бөтен гомерем буе авылда яшәп иҗат итәм. Кайчан да шигырьләр язармын да, дөньяга шигырь китапларым чыгар дигән уй башыма килгәне булмады.

Врач булыр кызым, диде әткәй.
Бу сүз булды һәрчак исемдә.
Ак халаттан итеп күрә идем
Мин үземне хәтта төшемдә.
Кулга аттестатым алган көнне,
20 июнь көнендә,
Ак халатлы матур хыялларым
Шау бөредә иде, бөредә.
Ике көннән, тагын ике көннән
Ут уйнады ерак офыкта.
Ак халатлы матур хыялымның
Канатлары янды шул утта...

Сугыш минем язмышымны да бөтенләй көтелмәгән юнәлешкә борып җибәрде — фронтка киткән укытучыларымның урыннарын алмаштырып, авыл мәктәбендә математика укытучысы булып эшли башладым.

Өлкән классларда укыган елларымда ук, көндәлек дәфтәремдә иң яшерен хисләремне шигъри юлларга салып, күңелемә рәхәтлек таба идем.

Бервакыт (1957 елның көзге бер көнендә), Әлмәттән авылыбызга кайтып килгәндә, минем тел очымда:

Ишеттем мин тормыш шау-шуында
Әткәм чүкеченең тавышын,—

дигән юллар кабатлана башлады. Һәм мин, өйгә кайтып керү белән, кулыма каләм алдым. Бер сулыштан язылган «Әткәм чүкеченең тавышы» дигән бу әсәрем мине яңа дөньяга — шигърият дөньясына алып кереп китте.

Минемчә, математика һәм шигърият бер-берсен тулыландырып торалар. Шуңа күрәдер мин беркайчан да үземдә күңел бушлыгы сизмәдем.

«Шагыйрь күңелендә кыш булмый да, кар яумый»,— дигән бит безнең сөекле шагыйребез Габдулла Тукай. Дөрестән дә шулай. Гомернең нәкъ шул мизгелендә генә әйтелә торган хисләр, уй-теләкләр була. Үзең ана булмыйча, ана хисләрен аңлап бетермәгән кебек, әби булмыйча торып, оныкларның нәрсә икәнен аңлау да читен эш: нәниләр дөньясы — кабатланмый торган гүзәллек ул. Менә шул дөньяда яшәп тә, алар турында язмыйча мөмкинме соң? «Әниләргә һәм нәниләргә», «Үрдәгем үпкәләде», «Әйдәгез, танышыйк» дигән рәсемле китапларым янына тагын башкалары өстәләчәк икәнен күңелем белән тоям әле мин».

Татар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен 1994 елда Энҗе Мөэминовага Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә.

ТУГАН ИЛЕМ МИНЕМ

Кулым тисә,
туфрак алтын була.
Тирем тамса,
шыта гөл булып.
Күкрәгемдә туган җылы хисләр
Яңгырыйлар матур җыр булып.
Җиргә бассам,
арта егәрлегем,
Күккә баксам,
иркен тын алам.
Туган илем минем—
газиз җирем,
Мин бәхетле синең бер балаң.

Сораулар һәм бирем

1. Сез моңа кадәр Э. Мөэминова шигырьләре белән таныш идегезме?
2. *Туган илем* сүзтезмәсен нинди сүз белән алмаштырып була?
3. «Ватан кайдан башлана?» дигән темага сөйләшү оештырыгыз.

ИКМӘК

Яшәү чыганагы — Кояш нурын,
Җир җылысын саклап үзендә,
Күкрәкләргә терәп кисәр икмәк
Һәр табынның тора түрендә.

Икмәк — игенченең җан җылысы,
Җир-анага кадер-хөрмәте.
Яшәү тамыры ул һәр йөрәкнең,
Шуңа кадерлибез икмәкне.

Әти-әни, Ватан һәм дә икмәк!
Бу сүзләрдә — тормыш мәгънәсе.
Бәхет, хезмәт, ирек, яшәү яме —
Шул сүзләргә бәйле һәммәсе.

Сорау һәм биремнәр

1. Ни өчен шагыйрь икмәкне «яшәү тамыры» дип атый?
2. *Җан җылысы, яшәү тамыры, тормыш мәгънәсе* сүзтезмәләренең мәгънәләрен аңлатыгыз.
3. Шигырьне ятлагыз.

«Икмәк — ил тоткасы» дигән темага сөйләшү өчен сораулар

1. Иген кырларыннан мул уңыш җыеп алу өчен көрәш ел буе бара. Ел фасылына карап, игенче нинди эшләр башкара?
2. Авыл хуҗалыгында эшләү өчен, нинди һөнәрләргә ия булырга кирәк?
3. Сезнең кыр эшләрендә катнашканыгыз бармы? Ул хезмәткә мөнәсәбәтегез нинди?
4. Икмәк — яшәү чыганагы. Сез моны ничек аңлыйсыз?
5. Ни өчен олы кешеләр икмәккә аеруча зур ихтирам белән карыйлар?
6. Игенче хезмәте турында нинди әсәрләр укыганыгыз бар?

ТУГАНДАШ ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН

Нәҗәр Нәҗми

(1918—1999)

Башкортстанның халык шагыйре, шул ук республиканың Салават Юлаев, Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый премияләре лауреаты Нәҗәр Нәҗми — татар укучыларының яраткан язучысы.

Нәҗәр Нәҗми 1918 елда Башкортстан Республикасының Дүртөйле районындагы Миңешле авылында туа. 1938 елда Уфа металлургия рабфагын тәмамлагач, Башкорт педагогия институтында укый. Ватан сугышында катнаша. Матбугатта 1937 елда күренә башлый. 1950 елда «Тамчылар» исемле беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Ул драматургия һәм әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә уңышлы эшли. Аның әсәрләре татар, рус, украин һәм башка халыклар телләрендә дә басылып чыга.

Нәҗәр Нәҗминең шигырьләре үткен гражданлык хисләре белән сугарылган. Татар теленә зур хөрмәт белән язган «Татар теле» шигыре татарлар яши торган бөтен төбәкләрне әйләнеп чыкты, укучыларда туган тел белән горурлану хисе уятты.

ТАТАР ТЕЛЕ

Туган җирең — Идел буе.
Һәр телнең бар туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Ак алъяпкыч бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йөзле татар теле.

Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син көне-төне.
Ир-егетләреңдәй дәртле,
Гайрәтле син, татар теле.

Фәннән сине аерса да
Гасырларның афәт җиле,
Аксакалларыңдай олпат,
Акыллы син, татар теле.

Ассалар да, киссәләр дә,
Үлмәдең син, калдың тере.
Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле.

Яндың да син, тундың да син,
Нишләтмәде язмыш сине?!
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй мөкатдәс Тукай теле!

Төрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән бергә сине.
Төрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.

Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире.
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син, батыр татар теле!

Кабатланмас үткәннәрең —
Гасырларның яман чире.
Кабатлар сине гасырлар,
Татар теле, дуслык теле.

афәт — һәлакәт, бәла-каза
олпат — дәрәҗәле, бөек

Сораулар һәм биремнәр

1. Шагыйрь татар теленең матурлыгын кайсы юлларда чагылдыра? Шул урыннарны табып укыгыз. Ул телне кем белән чагыштыра?
2. Шигырьдә татар теленең язмышы ничек тасвирланган? Халык язмышы белән тел язмышын аерып карап буламы?
3. Ни өчен шагыйрь татар телен дуслык теле дип атый?
4. Шигырьне ятлагыз.

КОРБАН БӘЙРӘМЕ

Татар халкының борын-борыннан безнең чорларга кадәр килеп җиткән бик күп милли бәйрәмнәре бар. Ислам дине белән бәйле бәйрәмнәрнең берсен — Корбан гаетен — халкыбыз аеруча олылап үткәрә.

Корбан бәйрәме Мәккәгә хаж кылу тәмамланган көнне башлана һәм 3 көн дәвам итә. Бәйрәмнең беренче көнендә хаж кылучылар корбан чалалар. Корбан чалуның да үз тарихы булган. Риваятьләргә караганда, Ибраһим пәйгамбәр, Аллаһы Тәгаләгә чиксез бирелгәнлек билгесе итеп, улы Исмәгыйльне корбан итеп чалмакчы була. Әмма Аллаһы Тәгалә, Ибраһимны кызганып, аңа сарык бәрәне җибәрә һәм аның улын коткарып кала. Шуннан соң һәр мөселман кешесе шушы вакыйга истәлегенә корбан чала башлый. Корбанга берәр йорт терлеген (кагыйдә буларак, бәрән яисә дөя) чалалар. Итнең өчтән ике өлешен фәкыйрьләргә өләшәләр. Хуҗа бәйрәм табыны әзерли. Анда дин әһелләре һәм башка кунаклар чакырыла. Коръән укыла, изгелеккә өндәп, вәгазьләр сөйләнә.

Гает көннәрендә барча мөселманнар мәчеткә намаз укырга баралар, бер-берсенең хәлен белешәләр, вафат булган ата-аналары, әби-бабалары, туган-тумачалары рухына багышлап, дога кылалар, хәер бирәләр.

КАЗАН МӘЧЕТЛӘРЕ

922 елда Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителгән. Шуның белән бәйләнешле рәвештә, Казан ханлыгында бик күп мәчетләр салынган. Әмма Явыз Иван, 1552 елда Казанны яулап алгач, татар халкын рус дәүләтенә буйсындыру белән генә чикләнмичә, аны руслаштыру, чукындыруны төп максат итеп куйган. Бөтен мәчет-мәдрәсәләр җимерелгән. Мәсәлән, 1744 елда Казанда һәм Казан өязендәге 536 мәчетнең 418 е юкка чыгарылган.

XVIII гасыр мәчетләренең кайберләре, безнең көннәргә кадәр сакланса да, җимерелүдән соң торгызылган вакытта зур үзгәрешләр кичергәннәр. Ул чорда төзелгән мәчетләр — татарларның милли үзаңы, мәдәнияте үсешен чагылдыручы архитектура истәлекләре. Казан мәчетләре татар халкының дини һәм әхлакый тәрбия үзәге булганнар. Диненә, рухына тугрылыклы халкыбыз мәчетләрнең искеләрен торгызырга, яңаларын төзергә омтыла. Соңгы елларда төзелгән яңа мәчетләр әнә шул хакта сөйли.

Иске олы таш мәчет исеме белән билгеле беренче мәчет 1768—1770 елларда салынган. Бу мәчетне салырга рус дәүләте җитәкчелеге рөхсәт бирергә мәҗбүр булган, чөнки ул елларда халыкның хакимият белән ризасызлыгы нык үсә (1773 елда Е. Пугачев җитәкчелегендәге баш күтәрүчеләрне искә төшерегез). Казанның Иске татар бистәсендә Кабан күле ярының биек бер җирендә (К. Насыйри урамы, 17 нче йорт) салынган бу мәһабәт мәчет гүзәллеге, камиллеге белән сокландыра. Ул XVIII гасырда Россиядә ярыйсы ук популяр булган Көнбатыш Европаның барокко архитектура стилендә салынган. Архитекторы татар булмаса да, мәчетнең төп төзелеш принциплары XVIII гасырда Казан татарларында кабул ителгән төзелеш кануннарына туры китереп эшләнгән. Бинаның

тышкы һәм бигрәк тә эчке бизәкләү формалары татар халык иҗаты үрнәкләренә, аның орнаментларына нигезләнгән.

Монда татар чигүләренә хас бизәкләр дә, чәчәкләр дә күрергә мөмкин. Мәчет тирә-яктан калын таш койма белән әйләндереп алынган. Болар барысы да, камил архитектура үрнәге булып, урамга милли колорит төсмере биреп тора.

Каюм Насыйри язып калдырганча, бу мәчетне башта **Әфәнде мәчете** дип, соңрак аны төзүгә акча биргән **Юныс бай мәчете** дип атап йөрткәннәр. Соңыннан ул **Мәрҗани мәчете** буларак танылган, чөнки 1849 елдан алып 40 ел буена күренекле татар галиме, тарихчы һәм мәгърифәтче Шиһабеддин Мәрҗани бу мәчетнең имамы булып торган. Илебездә бөтен мәчетләр ябылган чорда да Мәрҗани мәчете Казанда эшли торган бердәнбер мәчет булды.

Барокко стилендә салынган тагын бер мәчет бар: ул — **Апанаев мәчете.** «Байлар мәчете», «Галиев мәчете» дигән исемнәр белән тарихка кергән бу мәчет 1872 елда төзелә башлаган. Ул Иске татар бистәсендә Мәрҗани мәчетеннән ерак түгел, байлар яши торган мәхәлләдә мәшһүр байлар — Апанаевлар — акчасына салынган һәм алар исеме белән аталган. Тышкы кыяфәте, матурлыгы, бигрәк тә купшылыгы белән бөтен Иске татар бистәсен бизәп торган. Әмма XX гасырның

Борнай мәчете

утызынчы елларында аны балалар бакчасы итеп үзгәртәләр, манарасын сүтәләр. Хәзер мәчет яңадан торгызылды.

Борнай мәчете дә XIX гасыр архитектура истәлекләреннән. Хәзерге Г. Тукай урамына аркылы урнашкан кечкенә генә урамда 1769 елдан бирле агач мәчет эшләп килгән. Тик ул 1871 елда янган. Аның урынына Борнаев Садыйк исемле бай таштан яңа мәчет салдырган. Менә шул таш мәчет, яки Борнаев мәчете (Әхтәмов урамы, 7 нче йорт), хөкүмәт тарафыннан Татар бистәсенең иң күркәм мәчетләреннән берсе һәм архитектура һәйкәле дип игълан ителгән. Архитектор галимнәр әйтүенчә, мәчетнең манарасы Каһирәдәге Мөхәммәтгали мәчетенекенә бик охшаган икән.

Кабан арты, Печән базары һәм **Әҗем мәчетләре, Зәңгәр мәчет, Солтан, Касыйм мәчетләре** дә — тарихи истәлекләр.

барокко стиле — Европада XVI гасыр ахыры — XVIII гасыр урталарында киң таралган архитектура юнәлеше; бу стильдә төзелгән биналар декоратив купшылыклары, бәйрәмчә бизәлгән булулары белән аерылып торалар

имам — өлкән мулла

мәхәллә — квартал

Сораулар һәм бирем

1. Мәчетләр тарихыннан тагын нәрсәләр беләсез? Тарихны белү ни өчен кирәк?
2. Н. Халитовның «Мәчетләр архитектурасы» (рус телендә), Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китапларын укыгыз.
3. Соңгы елларда сез яшәгән төбәкләрдә нинди мәчетләр төзелде?

ЭЧТӘЛЕК

ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ 4

Риваятьләр һәм легендалар 4

Шәриф Камал 8
Буранда 9
Хикәя 17

Хөснул Вәлиуллин 18
Акчарлаклар. *Рәшит Әхмәтҗанов шигыре* 20

Гаяз Исхакый 21
Җан Баевич 21

Һади Такташ 35
Мокамай 37

Хәсән Туфан 42
Туган тел турында җырлар 44
Кайсыгызның кулы җылы? 45
Кемнәр сез? 46

Мирсәй Әмир 48
Агыйдел 50

Фәхри Насретдинов 64

Шамил Усманов 66
Әптери агай хикәясе 67

Таҗи Гыйззәт 73
Изге әманәт 75

Фатыйма Ильская 88

Гөлсем Камская 90

Шәриф Еникеев 92
Солтангәрәйнең язмышы 93

Самат Шакир 117
Үлемнән көчлерәк 118
Очерк 128

Аяз Гыйләҗев 129
Җомга көн, кич белән... 130
Илдар Юзеев 145
Таныш моңнар 146
Поэма 155
Гашыйклар тавы 156
Эдуард Касыймов 174
Гомер ике килми 175
Лотфулла Фәттахов 195
Фәнис Яруллин 197
Җилкәннәр җилдә сынала 198
Ана 214
Баллада 216
Иң гүзәл кеше икәнсез 216
Миргазиян Юныс 217
Шәмдәлләрдә генә утлар яна 218
Энҗе Мөэминова 228
Туган илем минем 230
Икмәк 230
ТУГАНДАШ ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН 232
Нажар Нәҗми 232
Татар теле 232
МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘР 234
Корбан бәйрәме 234
МӘЧЕТЛӘР ТАРИХЫННАН 235
Казан мәчетләре 235

Учебное издание

Хабибуллина Закира Нуриевна
Фардиева Халида Газизовна
Хузиахметов Анвар Нуриахметович

ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА

Учебник для 9 класса
средней общеобразовательной школы
с русским языком обучения
(для учащихся-татар)

Издание третье, пересмотренное

Казань. Издательство «Магариф». 2005

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Хәбибуллина Закирә Нуриевна
Фәрдиева Халидә Газизовна
Хуҗиәхмәтов Әнвәр Нуриәхмәтович

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рус телендә урта гомуми белем бирүче
мәктәпнең 9 нчы сыйныфы
өчен дәреслек
(татар балалары өчен)

Редакторы *Т. Р. Шакирова*
Тышлык рәссамы һәм бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучысы *Р. Ф. Мөбарәкҗанова*
Корректоры *Т. Н. Сәгъдуллина*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*
Тышлыкта *Бакый Урманче* рәсеме файдаланылды.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.06.05. Форматы $60 \times 90\ ^1/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Басма табагы 15,0 + форз. 0,25. Нәшер-хисап табагы 12,0 + форз. 0,39.
Тиражы 16 000 д. Заказ К 5/146.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел. /факс (8432) 92-57-48.
httr: //magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19

Л. Фәттахов. Игеннәр өлгерде